Күп кенә укытучылар әле дә ике төшенчәне бутыйлар: интеграция һәм предметара бәйләнеш. Алар охшаш, ләкин бу төшенчәләр арасында аерма да кечкенә түгел. Җавапны сүзлекләрнең электрон фондыннан табарбыз: «Нәрсәнең дә булса өлешләрен, кисәкләрен бер бөтенгә җыю» [https://suzlek.antat.ru]. Шулай итеп, интеграция барлык өлешләрне дә бербөтен итеп берләштерүне күздә тота. Предметларны бер-берсенә бәйләп укыту предметара бәйләнешне барлыкка китерә.

Әдәбиятны өйрәнүдә катнаш сәнгать төрләрен җәлеп итү мәсьәләсе укыту методикасы өчен традицион. 30 нчы еллардан башлап һәм 80 нче елларга кадәр безнең ил мәктәпләрендә билгеле бер уку фәннәре дәрәҗәсендәге интегратив процесслар предметлар арасындагы бәйләнешләр системасы аша башкарыла. 70-80 елларда аларга зур әһәмият бирелә башлый, хәтта уку программаларында да «Предметара бәйләнешләр» дип аталган махсус бүлек барлыкка килә. Анда терәк төшенчәләр, фактлар аерып бирелә, әлеге фәннең еш кына үзе белән якын торган уку дисциплиналары материалы белән предметлар арасындагы бәйләнешен күздә тоткан темалар күрсәтелә. Әлеге тәҗрибә соңгы вакытта еш кулланыла башлады. 90 нчы еллар башыннан педагогикада яңа сыйфат

дәрәҗәсендәге эчтәлекле һәм дидактик интеграцияне отышлы күренеш буларак тәкъдим итә башладылар.

Интеграциянең барлыкка килүе уңай элемтә булдыруны күздә тоткан предметлар арасындагы бәйләнешләрне тормышка ашыруның югары дәрәҗәсе нәтиҗәсе булып тора, чөнки ул берничә фән өчен гомуми булган фәнни идеяләргә, концепцияләргә нигезләнә, алар кешелек, дөнья, мәдәният турында бербөтен күзаллау бирә. Димәк, әдәбият дәресләрен предметара бәйләнешләр принцибына нигезләнеп укыту бары тик уңай яктан гына бәяләнә ала.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф. Заһидуллина, М.И. Ибраһимов, В.Р. Әминева. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 б.
2. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы: Метод. кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. – 335 б.
3. Камаева Р.Б. Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм / Р.Б. Камаева, А.Х. Мөхәммәтҗанова. – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 69 б.



**Р.Е. БАЙЛАУОВ,**

*студент*

*Западно-Казахстанский медицинский университет имени Марата Оспанова*

**М.М. КНИСАРИНА,**

*доктор философии PhD, доцент кафедры психологии*

*Западно-Казахстанский медицинский университет имени Марата Оспанова*


## ФЕНОМЕН «БЛАГОПОЛУЧИЯ» ГЛАЗАМИ ОБУЧАЮЩЕГОСЯ


**Аннотация.** Рассматривается вопрос понимания благополучия со стороны обучающейся молодежи. Важно определить общее представление обучающихся о составляющих благополучия, таких как психическое здоровье, физическая активность, финансовая независимость. Отрадно то, что большинство наших респондентов оценивают свое благополучие относительно хорошим, выделяя опору на спорт, на хобби, на отличные взаимоотношения с семьей, друзьями. Имеются стремления сохранять высокий уровень своего благополучия, уделяя внимание всем аспектам своей жизни и регулярно отдыхая и занимаясь любимыми делами.



**Ключевые слова:** обучающаяся молодежь, благополучие, факторы благополучия, повышение социальной ответственности личности



**Abstract.** The issue of understanding well-being on the part of the studying youth is considered. It is important to determine the general idea of students about the components of well-being,

such as mental health, physical activity, financial independence. It is gratifying that the majority of our respondents rate their well-being relatively good, highlighting the reliance on sports, hobbies, excellent relationships with family and friends. There are aspirations to maintain a high level of their well-being, paying attention to all aspects of their lives and regularly resting and doing their favorite things.

**Keywords:** learning youth, well-being, factors of well-being, increasing social responsibility of the individual

В настоящее время важным стало улучшать качество жизнедеятельности человека, поскольку в быстроизменяющемся мире есть вероятность потерять человеческий мир в его обычном для нас понимании. Современный человек и его благополучие намного важнее всего, всех технологических революций, инноваций и реформ. Для начала определимся в самом понятии «благополучие»? Благополучие, как принято определять, – это «совокупность факторов, обеспечивающих потребности личности относительно ее представлений об устройстве быта, отношениях и других аспектов, создающих ощущения удовлетворенности, душевного спокойствия и уверенности в завтрашнем дне» [1]. По нашему мнению, у каждого человека свое понимание смысла данного понятия, которое напрямую зависит от ежедневных потребностей и желаний личности, его самосознания.

Целью нашего исследования является выявление понимания обучающимися понятия «благополучие» посредством интервью. Для нас научный интерес представляют мнения респондентов, их образ мышления в сфере общечеловеческих ценностей, смысла своей жизни.

В опросе приняло участие 54 обучающихся разных курсов и специальностей обучения, разного возраста. Опрос проводился в онлайн режиме, в удобном формате для респондентов методом рассылки через бесплатный и общедоступный сервис обмена мгновенными сообщениями и голосовой связи по IP – WhatsApp. В данной публикации мы представили анализ всех полученных ответов с приведением в пример некоторых интересных на наш взгляд ответов.

В процессе опроса производился сбор личных данных респондентов, и задавались 3 открытых вопроса *(Рисунок 1)*.




Рис. 1. Диагностическая карта опроса

Многие обучающиеся воспринимают благополучие с разных его аспектов:

а) душевное / моральное / ментальное благополучие, как уверенность в себе, позитивный взгляд на любую ужасную ситуацию, как «бегунок после провала на выставке работ или экзамене», общительность, несмотря на замкнутость из-за огромного количества работы, эмоциональная стабильность;

б) физическое благополучие – чтобы не засиживаться, не сгибать спину, горбатиться, не пропускать приёмы пищи и сна;

в) материальное / финансовое – это полное благополучие с финансами. Представляем некоторые ответы респондентов в виде таблицы 1 с описанием их личности.

*Таблица 1*

Полученные ответы опроса обучающихся

| Первый вопрос | Второй вопрос | Третий вопрос |
|---|---|---|
| К., 18 лет, женский пол, 2 курс, «Дизайн», г. Анапа | | |
| «Для меня «благополучие» это спокойствие в душе. Когда ты ни о чем не думаешь и плывёшь по течении своих мыслей. Когда физически ничего не ощущаешь (разные боли и дискомфорт)». | «социальные факторы – не знаю входит ли это, но контакт с людьми, сверстниками. Здоровье опять же немаловажно. Материальное – стабильность доходов и вообще нахождение работы (подработки) для получения | В настоящее время мой уровень благополучия от 1 до 10 занимает 6 место. На это влияет – образование, эмоциональная нестабильность, стресс, малый доход. В целом не всё так плохо, главное не теряться, спокойно и постепенно |

| | | |
|---|---|---|
| | доходов, а после приобретения материалов. | разбирать тяжкий груз. |
| М., 17 лет, женский, 1 курс, Дизайн и мода, Атырау | | |
| «Для меня «благополучие» это спокойствие в душе. Когда ты ни о чем не думаешь и плывёшь по течении своих мыслей. Когда физически ничего не ощущаешь (разные боли и дискомфорт)». | На меня влияют такие факторы как: тишина, атмосфера, окружение. Чтобы меня никто не трогал и я была одна – сама с собой. | В настоящее время у меня не очень хорошее благополучие. Я не могу насладиться своим временем из-за учебы. Слишком много дел и не получается расслабиться. |
| А., 17 лет, мужской, Стоматология, Актобе | | |
| Благополучие для меня - это жить в полном достатке как физически так и в духовном плане. | На благополучие влияет мое окружение как оно себя ведёт какие привычки у них есть. Также мой статус в жизни, мой капитал, чем лучше эти пункты тем лучше мое благополучие. | Все в моей жизни хорошо, на это влияет мое окружение состоящие из добрых уравновешенных людей, и мое финансовое состояние. |
| С., 17 лет, мужской, 1 курс, Морское нефтегазовое сооружения, Санкт-Петербург | | |
| Для меня благополучие – это спокойствие, счастливая жизнь в довольстве | Никакие, я сомневаюсь, что что-то способно его изменить. | Я оцениваю его очень высоко, и влияет на него спорт. Это то что поддерживает меня и разжигает чувства. |
| И, 17 лет, женский, стоматологии, Актобе | | |
| Для меня понятие «благополучие» означает, что я чувствую себя счастливой, здоровой и удовлетворенной своей жизнью. | Прежде всего влияет семейное воспитание, а потом уже друзья и университет. Важно иметь хорошие отношения с семьей и друзьями, чтобы чувствовать поддержку и любовь. | На данный момент я оцениваю свой уровень благополучия как неплохой, но, конечно же, есть некоторые аспекты, которые могли бы быть лучше. |
| Е., 16 лет, мужской, 1 курс, стоматология, Актобе | | |
| Это ощущение удовлетворенности и комфорта в различных сферах жизни, включая физическое и эмоциональное здоровье, социальные отношения, | Факторы, влияющие на мое благополучие физическое и эмоциональное здоровье, социальные отношения, финансовую стабильность. | Эмоционально я тоже не в лучшей форме из-за стресса, вызванного учебой и повседневными заботами. |

| | | |
|---|---|---|
| финансы. | | |
| К., 18 лет, мужской, 1 курс, Физика-математика, Атырау | | |
| Это чувство уверенности в завтрашнем дне, возможность уделять время учебе и личному развитию, не ощущая при этом постоянного стресса или давления. Это когда я чувствую себя удовлетворенным своими достижениями и окружающим миром, несмотря на отсутствие работы. | На мое благополучие влияют: успехи в учебе, поддержка семьи и друзей, моя физическая активность и социальная интеграция. Также важно чувство, что после окончания университета меня ждут новые возможности и перспективы. | Сейчас я оцениваю свой уровень благополучия как средний. Будучи студентом, я сталкиваюсь с определенными сложностями и неуверенностью в будущем из-за отсутствия работы. Однако благодаря поддержке близких и вере в себя, я стараюсь сохранять позитивное отношение. |
| Д., 17 лет, мужской, 1 курс, Общая медицина, Актобе | | |
| Благополучие это счастливая жизнь при материальных благах и психическом спокойствии. | По-моему, на благополучие влияют финансовое и психические аспекты. | У меня высокий уровень благополучия, так как я психический здоров и финансово стабилен. |
| Г., 17 лет, Женский, 1 курс, Стоматология, Актобе | | |
| Благополучие это когда, в жизни присутствует белая полоса, когда у тебя и у твоих родных всё хорошо. | удача, счастье, цель, поддержка. | мой уровень на данный момент 7/10, близкие рядом и этого достаточно для повлияния на благополучие. |
| Б., 18 лет, женский, 1 курс, Информационные технологии, Тараз | | |
| Благополучие – для меня это материальное благополучие. Когда ты полностью обеспечен, и можно не переживать за завтрашний день, ну конечно и благополучие моей семьи думаю это тоже самое главное. | Твое здоровье, самочувствие. И конечно ситуация в мире . То есть благополучие, я считаю понятие растяжимое, и каждый ощущает его по разному, и в разных ситуациях. | На данный момент я счастливый человек, с благополучной жизнь. Молодость, одно из лучших времен, это и влияет |

В большинстве для наших респондентов обозначение «благополучия» означает стабильность, счастье, здоровье и достаток. Для достижения так называемого «благополучия» им крайне важно добиться комфортных условий, которые позволят им не беспокоиться о стрессе, проблемах, делах, учебе и т.д. Среда, где они могут спокойно ожидать завтрашнего дня. Их «благополучие» означает, что они буду в состоянии добиваться поставленных себе целей, будь

то материальные, моральные, психические цели. Они просто хотят быть в комфортном окружении, в окружении своих друзей или семьи. Для многих из них «благополучие» также означает иметь стабильность в жизни, которая будет приносить достаточных доход для обеспечения самого себя, в том числе некоторые из них стремятся к финансовой независимости и уверенности в будущем. Некоторые также видят благополучие как социальный статус и признание со стороны семьи, друзей, да и в целом от общества.

Но важно понимать, что «благополучие» для каждого человека может иметь свой уникальный смысл. Например, для одного человека это может быть стремление к повышению своего финансового положения, для другого – тишина и спокойствие, а для третьего – комфортное окружение. Кроме того, благополучие не является постоянным состоянием, оно может меняться в зависимости от жизненных обстоятельств и приоритетов человека. Важно научиться находить баланс и стремиться к достижению своего определенного понимания благополучия, не забывая о важности здоровья, семьи, друзей и личного развития. Исследовательскую работу планируем продолжить, поскольку перед нами раскрываются новые аспекты рассмотрения данной проблемы.

**Данное исследование финансируется Комитетом науки Министерства науки и высшего образования Республики Казахстан (Грант № AP09058126)**

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Панюкова Ю.Г. Проблемы и перспективы исследования феномена благополучия в Российской психологии / Ю.Г. Панюкова, Е.Н. Панина, Б.Г. Болаева // Общество: социология, психология, педагогика, – 2017. – № 12. – С. 58-62.

**А.Р. БОЛГАРОВА,**

*магистрант*

*Казанский федеральный университет*

# ЭФФЕКТИВНОСТЬ ПРИМЕНЕНИЯ МУЛЬТИМЕДИЙНЫХ ТЕХНОЛОГИЙ В СОВРЕМЕННОМ ОБРАЗОВАНИИ

**Аннотация.** Общая стратегия обучения иностранному языку выдвигает требование развития иноязычной коммуникативной компетентности. Она предполагает практическое овладение навыками и умениями речи на уровне, достаточном для осуществления иноязычного общения в типичных ситуациях повседневной деятельности. Внедрение мультимедийных средств обучения в процесс обучения приводит на практике к эффективным результатам, следовательно, использование интерактивных форм обучения при обучении грамматике английского языка в средней школе способствует успешному решению основных образовательных задач.

**Ключевые слова:** мультимедийные технологии, средняя школа, английский язык.

**Abstract.** The general strategy of teaching a foreign language requires the development of foreign language communicative competence. It involves practical mastery of the skills and abilities of speech at a level sufficient for the implementation of foreign language communication in typical situations of daily activities. The introduction of multimedia teaching tools into the learning process leads to effective results in practice, therefore, the use of interactive forms of learning when teaching English grammar in secondary school contributes to the successful solution of the main educational tasks.

**Keywords:** multimedia technologies, high school, English.

На основе анализа научных трудов, выяснено, что образование в России приобретает новые черты: компьютеризация учебного процесса побуждает к пересмотру традиционных форм и методов преподавания иностранного языка, возникновению новых форм проведения уроков. В отличие от традиционных методик, когда учитель привык предоставлять определенные знания и требовать их усвоения, при использовании интерактивных форм обучения учащийся сам становится главной фигурой и сам открывает путь к усвоению знаний. Учитель выступает в данной ситуации активным ассистентом, и его главной функцией является организация и стимулирование учебного процесса. Учителям приходится обучать новое поколение детей, которые с рождения окружены разной современной техникой, любят и умеют пользоваться ею, поэтому им легче нырнуть в процесс обучения, если учитель говорит с ними «на их языке», давая возможность показать учащимся свои знания не только в предмете, но и показать себя во владении техническими средствами, а также проявить художественное дарование.

В.А. Личман указывает, что на уроках английского языка с помощью компьютера можно решать целый ряд дидактических задач, а именно [1: 206]:

– совершенствовать знания по грамматике посредством выполнения тестов в режиме online;

– формировать навыки и умение чтения, используя непосредственно материалы интернет-сети разной степени сложности;

– усовершенствовать умение аудирования на основе аутентичных звуковых текстов, песен, кино-эпизодов;

– совершенствовать умение письменной речи, пополнять свой словарный запас (как активный, так и пассивный) лексикой современного иностранного языка, отражающей определенный этап развития культуры народа, социальное и политическое устройство общества;

– обогащать школьников культурологическими знаниями, включающими в себя речевой этикет, особенности поведения разных народов в условиях общения, особенностей культуры и традиций страны, язык которой изучается;

– формировать устойчивую мотивацию познавательной деятельности учащихся на уроках;

– формировать навыки глобального мышления

– прививать потребность в использовании английского языка в целях подлинного общения.

На уроках для осуществления наглядной поддержки процесса обучения в основном применяют образовательный потенциал мультимедийных презентаций. Они отличаются по видам речевой деятельности (обучение чтению, письму, аудировке), по аспектам языка (лексика, грамматика, фонетика), а также по видам опор (содержательная, смысловая, вербальная, иллюстративная) [1: 55]. Мультимедийные презентации используются при введении и закреплении лексического, грамматического, страноведческого материала, в качестве опор при обучении монологической и диалогической речи. Использование презентаций способствует лучшему усвоению учебного материала, благодаря использованию анимации появляются возможности выделения наиболее значимых элементов.

Следовательно, использование мультимедийных средств при обучении грамматике английского языка в средней школе способствует успешному решению основных образовательных задач, в т.ч.: развитию грамматических навыков на разных этапах обучения; повышению объема выполненной на уроке грамматической работы; усовершенствованию навыков владения грамматикой английского языка; повышение мотивации и интереса к изучению грамматики английского языка; возможность реализации индивидуализации обучения грамматике английского языка; экономия расходования материалов и времени учителем и повышение авторитета учителя; повышение уровня владения английским языком учащихся; обогащение школьников культурологическими знаниями, включающими в себя речевой этикет, особенности поведения разных народов в условиях общения, особенностей культуры и традиций страны.

Обстоятельная подготовка учащихся средствами мультимедийных технологий помогает преодолевать ряд противоречий, возникших между существующим традиционным уровнем обучения иностранному языку и современными потребностями современного информационного общества. Следовательно, в отличие от обычных средств обучения школьников иностран-

ному языку именно мультимедийные позволяют не только обеспечить школьника большим количеством готовых, тщательно подобранных и организованных обучающих алгоритмов, но и реализовывать многовариантные задачи, развивая интеллектуальные, творческие способности, умение самостоятельно приобретать новые знания, работать с разнообразными источниками информации, формировать социокультурные компетенции.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Личман В. А. Мультимедийные средства обучения по английскому языку в начальной школе // Преподаватель года 2020: Сборник статей Международного научно-методического конкурса. В 2-х частях, Петрозаводск, 03 мая 2020 года. – Петрозаводск: Международный центр научного партнерства «Новая Наука», 2020. – С. 206-210.

2. Бурмистрова Е. Д. Виды мультимедийных средств при обучении иностранному языку // Исследования молодых ученых: материалы XVII Международной научной конференции, Казань, 20–23 февраля 2021 года. – Казань: ООО «Издательство Молодой ученый», 2021. – С. 55-57.

**А.И. ВАСИКОВА,**

*магистрант*
*«Адымнар – Казан» күптелле мәктәбенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**Р.К. СӘГЪДИЕВА,**

*филология фәннәре кандидаты, доцент*
*Казан федераль университеты*

# КҮРСӘТМӘЛЕЛЕК ЯРДӘМЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ СӨЙЛӘМ КҮНЕКМӘЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУ

**Аннотация.** При преподавании татарского языка особенно значимо использование наглядных средств обучения. В статье анализируются современные подходы к использованию средств наглядности. Рассматривается наглядность при развитии устной речи учащихся.

**Ключевые слова:** татарский язык, наглядность, навыки, платформа.

**Abstract.** When teaching the Tatar language, the use of visual learning tools is especially important. The article analyzes modern approaches to the use of visual aids. The visibility in the development of oral speech of students is considered.

**Keywords:** Tatar language, visibility, skills, platform.

Сөйләү – продуктив сөйләм эшчәнлеге төре, эчке сөйләмнең әйтелә торган сөйләмгә күчермәсе. Кеше уйларының сигналларга күчүе бер-берсенә

нәрсәдер әйтергә теләгәндә барлыкка килә. Сөйләшү аралашу вазифасын үти. Методик яктан караганда, сөйләшергә өйрәтүнең эчтәлеге ишетү, күрү, вербаль һәм вербаль булмаган чараларны куллануны да күздә тота [2, б. 236].

Чит тел сөйләменә өйрәнү, иң беренче чиратта, укучының әлеге тел белән кызыксынуына бәйле. Укучының кызыксынуын уяту һәм мотивация булдыру өчен, укытучыга дәрестә кулланырга дөрес материал сайлап алырга кирәк. Иң мөһиме ул укучының үсешен туктатмасын, ә бәлки аңа  үсеш бирсен. Күп кенә галимнәр  укытучының телдән сөйләмгә өйрәтүендә күрсәтмә материаллар куллануны югары бәяли. Алар фикеренчә, күрсәтмәлелек укучыга чит тел сөйләмен өйрәнү өчен нигез ролен үти [1, с. 78]. Бу очракта, күрсәтмәлелек телне үзләштерү процессын тоткарламас өчен, кирәкле вакытта кулланыла торган ярдәмче чара буларак файдаланыла һәм иң мөһиме ул белем бирү процессына зыян салмаска тиеш.

Күрсәтмә материалларның балаларның яшь үзенчәлекләренә, тормыш тәҗрибәләренә туры килүе бик мөһим. Бу телдән сөйләм үсешенә зур йогынты ясый. Татар телен өйрәнгәндә, укучының тәкъдим ителгән күрсәтмә чаралардан файдалану сәләтенә аеруча игътибар итү кирәк, ә соңрак укучы болар белән генә чикләнеп калмыйча, шуның үрнәгендә үзләренекен дә булдыра ала. Башлангыч сыйныфларда бу өйдән алып килгән предметлар, уенчыклар, рәсемнәр, югарырак сыйныфларда презентация, плакат һәм башкалар булырга мөмкин. Моның өчен укытучыга дәрестә чынбарлыкка мөмкин кадәр якынрак булган ситуацияләр белән эшләү кирәк. Мәсәлән, башлангыч һәм урта сыйныфларда «Минем гаилә» темасын өйрәткәндә, балалар туганнарының фотосурәтләрен бик теләп алып киләләр, алар ярдәмендә коллажлар төзи, рәсемнәр ясыйлар.

Элеккеге  дәреслекләрдә һәм уку әсбапларында озак вакытлар дәвамында күрсәтмәлелек бары тик текстка иллюстрация буларак кына кулланылып килде. Хәзерге дәреслекләрдә исә күрсәтмәлелеккә бәйле функцияләрнең күптөрлелеген әйтеп үтәргә кирәк. Методистлар тарафыннан күрсәтмәлелекне сайлап алуның гомуми критерийлары булдырылды: мәгълүмат байлыгы, укучыларның мәнфәгатьләрен һәм омтылышларын исәпкә алу, тел һәм сөйләм компетенцияләре дәрәҗәсен исәпкә алу һәм башкалар.

Күрсәтмә материаллар шулай ук милләтне, Ватанны өйрәнү функцияләрен дә башкара, аларга хас актуальлек, социаль-мәдәни белемнәр, мәдәнияткә карашны үз эченә ала. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: теләсә кайсы уку программасын төзегәндә, Федераль дәүләт белем бирү стандартларының заманча таләпләре буенча милли-мәдәни компонентны да

исәпкә алырга кирәк, белем бирү социаль-мәдәни компетенцияләрне дә формалаштыруга юнәлдерелергә тиеш. Телдән сөйләмгә өйрәтүдә күрсәтмәлелек кулланылмый икән, ул белем бирү процессына шактый зур зыян сала. Чөнки күрсәтмәлелеккә бәйле рәвештә, укучы үзенең күзаллаганнарын язма рәвештә чынга ашыра ала. Шуңа күрә укытучы өстәмә күрсәтмә материал сайларга тиеш. Иҗтимагый-мәдәни компетенцияләрне һәм чит телдә аралашуны үстерү максатында күрсәтмә материаллар кулланып, түбәндәге биремнәрне формалаштырырга мөмкин:

– укылган текстка яки диалогка туры килгән рәсем яки картиналарны сайлап алыгыз;

– тема буенча комикс яки репликалар белән коллаж ясагыз (гаилә, мәктәп, Россиянең танылган шәһәрләре, туган авыл, бистәсе турында хикәя һ. б.);

– дәреслектәге иллюстрацияне укытучы тәкъдим иткән иллюстрация белән чагыштырыгыз һ.б.

Телдән сөйләмгә өйрәткәндә, моңа бәйле күнекмәләр формалаштыруда күрсәтмәлелек куллануга нигезләнгән биремнәр шактый. Мәсәлән, «Визит карточкасы» уены. Укытучы һәр баладан визит карточкасы ясауны сорый: фамилиясен, исемен, яшен, адресын, телефонын, яраткан шөгылен язуны таләп итә, болар барысы да татар телендә башкарыла. Алга таба укучы кем белән танышырга тели, шуның янына бара һәм башта үзе белән таныштыра һәм укучылар карточкалар белән алмаша. Шуннан соң укытучы укучыга үзенең иптәше турында сөйләргә, аның белән таныштырырга дигән биремне йөкли һәм җөмләнең түбәндәгечә башлануын таләп итә: «Мин сезгә үземнең дустым турында сөйләргә телим».

«Рәссам» дип аталган уен да укучыларга кызык. Әлеге уен командаларга бүленеп уйнала. Һәр командадан иң оста рәсем ясаучы укучы сайлап алына, һәм ул такта янына чыга. Команда әгъзалары әлеге укучыга нәрсә ясарга кирәклеген аңлатырга тиеш: ул нинди төстә, нинди формада һ.б. Әмма предметның исеме турыдан-туры аталмый. Сөйләм бары тик татар телендә генә бара.

Шулай ук телдән сөйләм күнекмәләрен камилләштерүдә татар халык мәкальләренә дә нигезләнергә була. Мисал өчен, мәкальләрне түбәндәгечә рәсемнәр ярдәмендә тәкъдим итеп, укучыга моның нинди мәкаль икәнлеген танырга һәм аны үз сүзләрең белән аңлатырга, тормыштан мисаллар китерергә дигән бирем йөкләргә була.




(Җиде кат үлчә, бер кат кис.)



(Алма агачыннан ерак төшми.)

Югарыда тәкъдим ителгән биремнәр, күнегүләр һәм дидактик уеннар барысы да күрсәтмәлелеккә нигезләнгән һәм алар укучыда дөрес сөйләм күнекмәләре формалаштыруга юнәлтелә. Телдән сөйләм күнекмәләрен үстерүдә күрсәтмәлелекнең роле шактый зур. Укучы күрсәтмә материалларны күреп кабул итә һәм шулар ярдәмендә үз сөйләмен формалаштыра. Телдән сөйләмгә өйрәткәндә, укучы белем дә ала, кешеләр белән аралашырга да, дөньяны танып белергә дә өйрәнә. Ә бу процесста күрсәмә материаллар зур терәк ролен үти.

### ӘДӘБИЯТ

1. Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Ф.С. Сафиуллина. – Казан: Хәтер нәшрияты, 2001. – 432 б.

2. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Ф.Ф. Харисов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 302 б.

**Г.Ш. ГАББАСОВА,**

*учитель начальных классов*

*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Гимназия № 184 им. М.И. Махмутова» Советского района г. Казани.*

**Л.Ш. РАХИМЗЯНОВА**

*учитель начальных классов*

*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Гимназия № 184 им. М.И. Махмутова» Советского района г. Казани.*

## БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФЛАРНЫҢ РУС ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПРОЕКТЛАР МЕТОДЫН КУЛЛАНУ

**Аннотация.** Использование метода проектов на уроках татарского языка и литературы является стимулом для устрашения творческих способностей учащихся. По мере овладения опытом творческой деятельности растет и качество знаний учащихся.

**Ключевые слова:** учащиеся, наука, метод проектов, татарский язык и литература.

**Abstract.** The use of the project method in the lessons of the Tatar language and literature is an incentive to intimidate the creative abilities of students. As students master the experience of creative activity, the quality of students' knowledge also increases.

**Keywords:** students, science, project method, Tatar language and literature.

Укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану – яңа метод һәм алымнарны үстерергә, яңача эшләргә ярдәм итә. Без, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, дәрестә өйрәнгән теманы җиңел юл белән үзләштерә торган, белем сыйфатын күтәрүгә файдалы булган проектлар технологиясен һәм эзләнү-тикшеренү методын куллану уңай күренеш дип саныйбыз.

Проект методы эшчәнлегенең эпиграфы итеп түбәндәге юлларны кулланыр идек: «Сөйлә миңа – мин онытырмын, күрсәт – истә калдырырмын, кызыксындыр – өйрәнермен».

Проект эшен башкарганда укучылар өстәмә чыганаклар эзләргә, табылган мәгълүматларны кулланырга өйрәнәләр, аралашу күнекмәләрен үстерәләр, фәнни-тикшеренү күнекмәләрен камилләштерәләр, төркемнәрдә эшләргә өйрәнәләр, аларда җаваплылык хисе, үз-үзенә ышаныч формалаша [1, б.19].

Проект эшчәнлегенең нигезе – эзләнү-тикшеренү эше. Эшнең уңышлы килеп чыгуы аның дөрес планлаштырылуына бәйле. Монда укытучы, укучы һәм ата-ана хезмәттәшлеге бик әһәмиятле. Ул яхшы әзерләгән, сыйныфның һәм иҗади төркемнәрнең үзара килешеп эшләүләрен таләп итә. Проект турында сөйләшүдә катнашып, укытучы да тигез хокуклы фикердәшкә, ярдәмчегә әйләнә. Проектны гамәлгә ашыру барышында укучылар әйләнә-тирәдәгеләр белән уртак тел табып эшләргә, фикерләрен дәлилләргә өйрәнә.

Укыту процессы белән бәйле рәвештә дә мөстәкыйль фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә дә кулланыла.

Проект сүзе өч мәгънәне аңлата:

1) нинди дә булса механизмның яки корылманың әзер планы;

2) нинди дә булса документның алдан әзерләнгән тексты;

3) теләгеңне тормышка ашыру планы.

Элек проект сүзе техника өлкәсендә генә кулланылган булса, хәзер музыка, театр, әдәбият, бизнес өлкәләрендә дә теләгеңне тормышка ашыру планы буларак кулланыла [2, б.50].

Татар теле һәм әдәбиятын өйрәнгәндә, түбәндәге төрдәге проектларны кулланып була:

– тикшеренү (хезмәтнең актуальлеген нигезләү, тикшеренүнең максаты әйтү, бурычлар кую, аларны чишү юлларын күрсәтү);

– иҗади (кичә яки бәйрәм үткәрү өчен сценарий төзү, мәкалә язу һ.б.);

– гамәли юнәлешле (һәр укучының, төркемнең бөтен эшчәнлеген яхшы нәтиҗәләргә ирешү максатыннан чыгып планлаштыру);

– мәгълүмати (темага караган мәгълүматларны җыю, аларны катнашучыларга тәкъдим итү, фикер алышу, йомгаклау);

– предметара (берничә предметка нигезләнү) [3, б. 22 ].

Рус телле балаларны татар телен өйрәнүгә этәргеч ясаучы, активлык һәм иҗадилыкны, танып белү мөмкинлекләрен, акыл эшчәнлеге мөстәкыйльлеген үстерүдә проектлаштыру методы зур урын алып тора. Лексика һәм грамматикага өйрәнү аралашуга нигезләнә. Проект укытучы тарафыннан махсус оештырыла, укучылар исә мөстәкыйль рәвештә эшлиләр һәм ахырда бер гамәли нәтиҗә ясала. Бу метод укытучы һәм укучыларның яхшылап әзерләнүләрен, сыйныфның һәм иҗади төркемнәрнең үзара килешеп эшләүләрен таләп итә. Проект турында фикер алышуда катнашып, укытучы да тигез хокуклы яшьтәш, ярдәмчегә әйләнә. Проектларны гамәлгә ашыру укучыларга әйләнә – тирәдәге кешеләр белән бергә эшләргә һәм тормышта үз урыннарын табарга ярдәм итә.

Проект дәресләр өчен кызыклы булган бик күп темалар тәкъдим итәргә була:

**Проект: «Минем гаиләм».**

Проектның максаты: гаилә кешеләре, аларның профессияләре белән таныштыру.

Бурычлары:

– гаилә турында белешмәне киңәйтү;

– үз тормышыңда гаиләнең әһәмитлелеген бәяләү.

– якын кешеләреңә карата кайгыртучанлыкны, ярдәм итү теләге тәрбияләү.

Проектны уздыру вакыты: кыска вакытлы.

Бу тема астында балалар ата-аналары һәм туганнары белән төшкән фото рәсемнәр алып киләләр. Бу проект балалар өчен бик мөһим эш булып санала. Укучылар үз гаиләләре турында кечкенә хикәя төзеп сөйләргә өйрәнәләр.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проектлар методын куллану – укучыларның иҗади сәләтен устерүгә этәргеч булып тора. Укучыларыбызда үз-үзләренә ышаныч, бер-берсенә карата хөрмәт, ихтирамлы мөнәсәбәт булдыруда ярдәм итә. Укучыларда татар теле һәм әдәбияты буенча яңа проектлар эшләү теләге туа һәм фәнгә карата кызыксыну уяна. Иҗади эшчәнлек тәҗрибәсенә ия булган саен укучыларның белем сыйфаты да үсә.

## ӘДӘБИЯТ

1. Камаева Р.Б., Мөхәммәтҗанова А.Х. Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм. – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 110 б.

2. Мөхәммәтҗанова А.Х., Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбият укытучысына ярдәмгә: ФДББС турында белешмәлек һәм терәк схемалар: методик ярдәмлек. – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 68 б.

3. Сафиуллин М.Р. Татар теле һәм әдәбиятын укытуда проектлар методы // «Мәгариф», 2014 № 7, 96 б.

**И.И. ГАЛИМБИКОВА,**
*магистрант*
*Казанский федеральный университет*

# ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ИГРОВЫХ ТЕХНОЛОГИЙ В НАЧАЛЬНОЙ ШКОЛЕ

**Аннотация.** Учитель начальной школы – это специалист, который закладывает базу для дальнейшего успешного обучения учеников. Именно в начальной школе формируется учебная деятельность, главная задача которой – научить ребенка учиться. Многие дети после детского сада приходят в школу с желанием познать что-то новое, но есть дети, которые не могу преодолеть барьер и с трудностью проходят адаптацию. Первый учитель – это тот человек, который у детей первой группы должен сохранить и повысить желание к учебе, а для второй группы создать все условия для появления желания учиться. Поэтому очень важным компонентом является мотивация школьников. Одним из часто используемых методов в начальной школе является применение игровых технологий. Игровые задания повышают уровень интереса детей к учебному процессу и повышают его привлекательность в глазах учащихся, выполняя не только развлекательную функцию, но и служа практическим целям.

**Ключевые слова:** мотивация, начальная школа, учебная деятельность, игровые технологии, происхождение игр, функции игр.

**Abstract.** An elementary school teacher is a specialist who lays the foundation for further successful education of students. It is in primary school that educational activities are formed, the main task of which is to teach the child to learn. Many children come to school after kindergarten with a desire to learn something new, but there are children who cannot overcome the barrier and have difficulty with adapting. The first teacher is a person who should preserve and increase the desire to study in children of the first group, and create all conditions for the second group to have a desire to learn. Therefore, a very important component is the motivation of schoolchildren. One of the most frequently used methods in elementary school is the use of gaming technologies. Game tasks increase the level of children's interest in the educational process and increase its attractiveness in the eyes of students, performing not only an entertainment function, but also serving practical purposes.

**Keywords:** motivation, primary school, educational activities, game technology, the origin of games, the functions of games.

Современный учитель должен дать ребенку не только знания, но главной его задачей является то, что он должен научить применять данные навыки в жизни. Ученик сам должен интересоваться, стараться находить ответы на инте-

ресующие его вопросы, только при таком раскладе у детей данная информация остается в памяти и появляется желание приобретать новые. Для того чтобы у ребенка было желание учиться, его нужно мотивировать.

Слово мотивация произошло от латинского глагола «movere», двигать. Учебная мотивация – это процесс, который запускает, направляет и поддерживает усилия, направленные на выполнение учебной деятельности.

Сегодня мы живем в мире, где много информации, и зачастую эта информация доступна всем и легко. Главной задачей в начальной школе является донести до детей основную мысль и заинтересовать их. Традиционные уроки не вызывают интерес к учебе у школьников, чтобы привлечь внимание во время урока, заставить детей самих рассуждать и проникнуть в тему, нужно использовать разные виды уроков или разные приемы во время объяснения темы. Это является одним из методов мотивации школьников. Если урок будет интересным, дети не смогут остаться в стороне и не участвовать, они будут заниматься, будут стараться показывать себя, но нужно учесть, данный подход должен использоваться не один раз, а регулярно. Еще один важный момент, – при использовании определенных приемов лучше чередовать и применять разные методы, так как однообразный подход к урокутакже может понизить интерес обучающихся к учебе.

Главным фактором мотивации школьников является то, что учитель должен видеть и хвалить учеников не только за правильные ответы, но должен уметь направлять их на верный путь. Хвалить их за исправленные ответы, также выделять среди неправильного верные моменты, чтобы школьник стремился к совершенству и понимал, что за правильные ответы он будет поощрен.

Чтобы доступнее преподнести детям материал в начальной школе, мотивировать их к изучению языка зачастую используют игровые технологии.

Если начать разбираться, откуда появились игры, то истоки нас приведут к религиозным началам, они служили главным стимулом культуры человека. Общую теорию игры в своих трудах начали разрабатывать Бюлер, Гросс, З.Фрейд, Вундт, Бейтендейк, Пиаже, Штерн, К.Д.Ушинский, П.П.Блонский, Н.К.Крупская, А.С.Макаренко, Ю.П.Азаров и др. Есть много научных подходов к объяснению причины появления игры: теория инстинктивности, функции упражнения, теории отдыха в игре, теория духовного развития ребенка в игре, теория воздействия на мир через игру, труд как источник появления игры, теория абсолютизации культурного значения игры и др. [1, с. 8]. Сущность теории функционального удовольствия, реализации врожденных влечений заключается в том, что дети если даже не генетически, то интуитивно во время игры стре-

мятся осознать новые границы, раскрыть истину. Теория инстинктивности, функции упражнения в игре, предупреждения инстинктов говорит о том, что игра – это не трата времени для ребенка, а серьезная деятельность. Он погружается в мир, который для него является реальной жизнью. В начальной школе особенно актуально использование игровых технологий, так как они не только захватывают интерес, но и вовлекают в учебную деятельность детей разных уровней обученности.

Игровые технологии формируют коммуникативные УУД, познавательные УУД, личностные УУД, регулятивные УУД.

Использование игровых технологий на уроках способствует не только приобретению новых знаний, но также дети получают удовольствие от самого процесса, что очень важно во время адаптационного периода в школе, также во время всего учебного процесса. Игровые технологии развивают у школьников творческий подход к работе, усиливают фантазию и расширяют кругозор; также во время игры дети учатся противостоять соперничеству, состязательности и конкуренции. Благодаря данной технологии ученик приобретает навыки целеполагания, планирования и реализации цели, а также учатся анализировать результаты, в процессе, которого реализует себя в качестве субъекта.

Выделяют следующий спектр целевых ориентаций:

1) Дидактический: расширение кругозора, познавательная деятельность; применение ЗУН в практической деятельности; формирование определенных умений и навыков, необходимых в практической деятельности; развитие общеучебных умений и навыков; развитие трудовых навыков.

2) Воспитательные: воспитание самостоятельности, воли; формирование определённых подходов, позиций, нравственных, эстетических и мировоззренческих установок; воспитание сотрудничества, коллективизма, общительности, коммуникативности.

3) Развивающие: развитие внимания, памяти, речи, мышления, воображения, фантазии, творческих способностей, рефлексии, умений сравнивать, сопоставлять, находить аналогии, оптимальные решения: развитие мотивации учебной деятельности.

4) Социализирующие: приобщение к нормам и ценностям общества; адаптация к условиям среды; стрессовый контроль, саморегуляция; обучение общению, психотерапия [1, с. 2].

Также игры делятся по виду деятельности. Различают такие виды как: физические (двигательные), интеллектуальные (умственные), трудовые, социальные и психологические. Функции игры – ее разнообразная полезность. У

каждого вида игры своя полезность [3, с. 62]. В трудах С.А. Шмакова выделяют такие виды игр: игра-труд, игра-искусство, игра-загадка, игра-ориентир, игра-общение, игра-коррекция, игра-упражнение и др.

Существует много функций игры как в досуговой, так и в познавательной деятельности: социокультурное назначение игры, функция межнациональной коммуникации, развлекательная функция игры и т.д. С учебной деятельностью напрямую связаны такие функции как: социокультурная (позволяет ребенку влиться в коллектив, преодолеть внутренние барьеры, также формирует навыки социального поведения); коммуникативная (научить ребенка выстраивать правильные взаимоотношения с одноклассниками – одна из самых главных целей классного руководителя в начальной школе. Использование игровых технологий, точнее их функция коммуникации помогают выявить проблемных детей, так как в коллективных играх такие дети отдаляются от работыи не вступают в связь с одноклассниками); диагностическая функция игры (во время игры ребенок максимально проявляет себя, именно в этот момент учитель может распознать отклонения учащихся, так как игра вводит детей в «поле самовыражения»); игротерапевтическая (данная функция применяется по отношению к больным детям и детям имеющих отклонения); функция коррекция в игре (данная функция помогает вносить изменения в личностные показатели индивида); развлекательная функция (данная функция неразрывная часть игры, данная функция позволяет создать благоприятную атмосферу во время урока, помогают детям перейти в мир увлекательных приключений).

Игровые технологии помогают выстроить мост между учителем и учащимися. Несмотря на то, что данная познавательная деятельность носит игровой характер, учащиеся относятся к ней серьезно, благодаря этому осуществляют личностное становление учащихся. Применение игровых технологий помогает решить ряд психологических задач, одной из самых важных является – снятие напряженной обстановки, тем самым способствование созданию положительной психологической готовности обучающихся к ответам на уроках.

### ЛИТЕРАТУРА

1. Волкова Г.А. Начальная школа. Все для учителя: научно-методический журнал / Г. Волкова / Использование игровых технологий на уроках русского языка в начальной школе // Издательская Группа «Основа». – 2017. – № 2. – С. 2-11.

2. Евдокимова И.В. Инклюзия в образовании: научно-методический журнал / И. Евдокимова. – Использование игровых технологий при обучении иностранному языку как средство развития личности младшего школьника. – 2018. – Т. 3. – № 2. – С. 8-19.

3. Шмаков С.А. Игры учащихся – феномен культуры. – М.: Новая школа, 1994. – 240 с.

**А.Р. ГАТИЯТОВА**

*студент*

*Казан федераль университеты*

# ЛАНДЫШ ӘБҮДӘРОВАНЫҢ «ГАЗАП» ХИКӘЯСЕНДӘ СУРӘТЛӘНГӘН ДӨНЬЯ

**Аннотация.** В статье рассматривается изображенный мир в одном из рассказов современной татарской писательницы Ландыш Абударовой «Газап». В процессе повествования Ландыш Абударова часто обращается к приемам портрета, пейзажа и психологизма. Успешно используя эти литературные приемы, автор создает своеобразную модель мира. Мир, изображенный в рассказах Ландыш Абударовой, довольно интересен, главная особенность его заключается в стремлении раскрыть образ жизни людей нового времени, их взгляды на жизнь.

**Ключевые слова:** рассказ, портретное описание, пейзаж, литературный прием, психологизм.

**Abstract.** The article examines the depicted world in one of the stories of the modern Tatar writer Landysh Abudarova. Landysh Abudarova often turns to the techniques of portrait, landscape and psychology in the process of narration. The author successfully uses these literary techniques and creates a kind of model of the world. The world depicted in the stories of Landysh Abudarova is quite interesting, its main feature is desire to reveal the lifestyle of people of the new time, their views on life.

**Keywords:** short story, portrait description, landscape, literary technique, psychology.

Ландыш Әбүдәрова хикәяләре күтәрелгән тема, проблема, сюжет-композиция ягыннан караганда шактый төрле. Соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре арасында «Газап» хикәясе игътибарга лаек. «Газап» мәхәббәт темасы чагылыш тапкан матур, лирик-моңсу әсәрләрнең берсе булып тора. Хикәянең исемендә үк чагылыш тапканча, әсәр газаплы мәхәббәт тарихы турында. «Җирдәге оҗмахымда мин көннән-көн сүнә, көннән-көн пыскып кына сүрелә, тәмугъ кисәвенә әйләнә барам, әмма аннан ваз кичә алмыйча шушы хәлемә мең кат разый булып, шөкер итеп яшим» [1, б. 54]. Ландыш Әбүдәрова әсәр башында геройның хис-кичерешләренә өстенлек биреп, эчке монолог ысулы ярдәмендә хикәяләүченең күзгә ташланмаган эчке үзгәрешләрен, газаплануларын чагылдыра. Әлегә геройның кем өчен яки нәрсә өчен шундый халәттә булуын белмәсәк тә, язучы безнең игътибарны җәлеп итә алырлык дәрәҗәдә оста итеп хәл-вакыйгаларны геройның күңеле, эчке дөньясы аркылы сурәтли.

Ландыш Әбүдәрованың күпчелек әсәрләрендә кешенең тышкы кыяфәтен сурәтләве, ягьни портрет алымын куллануы мөһим роль уйный. Әсәр башында геройның тышкы кыяфәте түбәндәгечә тасвирлана: «Мин аны гавам арасыннан аерып билгеләгәндә, ул гап-гади, күзгә чалынырдай бер җире дә булмаган бер

кыз иде. Андыйларны соры тычкан диләр урыста. Күзлекле, озын чәчләрен артка койрык итеп җыеп куйган, өстендә ак блуза, кара итәк. Әллә ни төз дә, кәкре дә түгел аякларында тигез табанлы балеткалар иде. Башкалар кычкырып көлгәндә, ул сүрән генә елмаеп куя» [1, б. 54]. Шул рәвешле, күз алдына кызның кыяфәте, буй-сыны, үз-үзен тотышы килеп баса, китап укучы геройның исеме белән таныш булмаса да, аның турыда күпмедер дәрәҗәдә мәгълүмат ала. Соңрак әсәр дәвамында без кызның Нәфисә исемле булуын беләбез, Нәфисә һәм Русланның танышу тарихларын, аларның үзара мөнәсәбәтләрен күзәтәбез. Беренче карашка кызның гадилеге, берни белән дә аерылып тормавы гаҗәпләндерә. Аның «сорылыгы», төссез тышкы кыяфәте хикәяләүченең игътибарын җәлеп итә алмас кебек тоела, әмма алга таба без кызның ихлас һәм кызыксынучан булуын күрәбез. Руслан эрудицияле, белемле егет булуга карамастан, Нәфисәнең гади бер соравына җавап таба алмый, югалып кала. Бу аның өчен җиңелүгә тиң. «Ул вакытта мин исемен дә белмәгән бу кызның күзләрендә баягы «сорылык» каядыр юкка чыккан кебек тоелды», – дип яза автор. Хикәяләүче егетнең күңелендә Нәфисәгә карата билгесез хисләр кабына, ул үзен «мәче тырнакларындагы тычкан кебек» хис итә башлый. Хикәяләүчегә карата психологизм алымын Ландыш Әбүдәрова аеруча уңышлы куллана. «...аның белән очрашудан соң күңелне бер корт кимерә иде. Соңрак кайта-кайта хатирәләрдә казына торгач аңладым: ул корт минем күңелгә беренче очрашуда ук кереп оялаган да тора-бара үзенең ятьмәсен минем бөтен тамырларыма кадәр җәелдергән иде. Агулаган, үзенеке иткән» [1, б. 57]. Автор Нәфисәнең тышкы кыяфәтен шактый тулы сурәтләүгә ирешә. «Ихлас, өмет тулы караш. Күзләре дә бик матур икән бу кызның, сирәк очрый торган соры күзләр. Кара белән сөрмә тарткан кебек, керфекләре дә озын...» [Әбүдәрова, 2018: 60]. Шул рәвешле Нәфисә әсәр дәвамында игътибар үзәгендә була, хикәяләүче дә кызга башкача карый башлый, Нәфисәнең карашы, саран елмаюы әйтерсең лә аны сихерли.

Әсәрдә Русланның авылга кайтуы, авылда тойган хис-кичерешләр турында хикәяләнә. Авыл романтикасын үзендә тойган хикәяләүчене андагы тынычлык тиз туйдыра. Бу урында автор пейзаж алымына мөрәҗәгать итә: «...озак итеп шәфәкъка карап торам. Авыл күгендә кояш япа-ялгыз: сәгатьләр буе тәгәри-тәгәри, офыклар артына кереп бата. Төнгә каршы чыгам да айга карыйм. Ай да ялгыз» [1, б. 66]. Әлеге өзектә кулланылган табигать сурәте әһәмиятле вазифа башкара. Ялгыз кояш һәм ай сурәтләре хикәяләүче Русланның халәте белән чиктәш бер халәт тудыра. Руслан үзенең ялгызлыгын таный.

Ландыш Әбүдәрованың «Газап» хикәясендә сурәтләнгән дөньяны өйрәнү аша авторның иҗат итү барышында портрет, пейзаж, психологизм алымнарына еш мөрәҗәгать итүен күзәттек. Югарыда анализланган хикәядә геройларның һәр гамәле, һәр кичереше сәнгатьчә нигезләнгән. Моңа ирешү өчен автор психологик халәтне дөрес оештыра алу, эчке кичерешләрне яңа төсмерләр белән баету омтылышы ясый.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Әбүдәрова Л.Р. Мандариннар: повесть, хикәяләр, нәсер, әкиятләр / Ландыш Әбүдәрова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 191 б.

2. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / Төз. Д.Ф. Заһидуллина, В.Р. Әминева, М.И. Ибраһимов, Н.М. Йосыпова, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйлаҗев, Г.Р. Гайнуллина. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

3. Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәр: өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз. – Казан: Мәгариф, 2007. – 112 б.

**Э.И. ГЫЙЛӘҖЕТДИНОВА,**

*студент*

*Казан федераль университеты*

## ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КОММУНИКАТИВ КОМПЕТЕНЦИЯ ФОРМАЛАШТЫРУ ЧАРАСЫ БУЛАРАК КЕЧЕ ТӨРКЕМНӘРДӘ ЭШ

**Аннотация.** В статье обосновывается эффективность применения метода работы в малых группах и предлагаются конкретные виды заданий. Автор приводит конкретный пример использования метода работы в малой группе в рамках учебной дисциплины «Родной язык» на уроке татарского языка в пятых и шестых классах. Применение метода работы в малых группах позволило повысить эффективность обучения, развить творческую активность учеников и проявить индивидуальный подход в обучении. Метод работы в малых группах применим на уроках по различным дисциплинам.

**Ключевые слова:** малая группа, коммуникативная компетенция, родной язык.

Кешеләр арасындагы аралашу билгеле бер тәртиптә оештырыла һәм формалаша. Бу процесска берничә фактор тәэсир итә: аралашуда катнашучылар үзләре, аларның белемнәре, физик һәм психологик торышлары, максатлары, аралашу объектлары һәм ситуацияләре, социаль нормалар, мәдәни традицияләр һәм кыйммәтләр һ.б. Аралашу мохитенә һәм иҗтимагый рольгә карап, бер үк мәгълүматны төрлечә әйтеп (язып) була, шуңа күрә һәр кешенең үзенчәлекле коммуникатив тәҗрибәсе була һәм бу тәҗрибә конкрет ситуацияләрдә һәм конкрет шартларда кулланыла. Хәзерге гуманитар күзлектән караганда, социаль һәм мәдәни яктан билгеләнгән кешеләрнең мондый үзара аралашу традициясе "дискурс" термины белән билгеләнә. Җәмгыятьнең рухи мәдәнияты, аның тормыш өлкәләренең төрлелеге күптөрле дискурсларны барлыкка китерә: көндәлек, рәсми, фәнни, сәяси, дини һ.б. дискурслар.

«Яшьләр дискурсы» төшенчәсен прагмалингвистик алым нигезендә билгеләү шулай ук дискурс типологиясе проблемасына кагылышлы берничә проблеманы чишүне таләп итә: яшьләр арасындагы сөйләшү чикләрен билгеләү һәм аның характеристикаларын ачыклау.

Яшьләр дискурсында җәмгыятьнең үсеш дәрәҗәсе, иҗтимагый-сәяси, мәдәни үзгәрешләр, яшьләрнең кызыксынулары һәм ихтыяҗлары чагылыш таба. Хәзерге татар яшьләре дискурсы, татар теленең функциональ төрлелеген, студент кызыксынуларының бөтен спектрын чагылдыра, микросоциум эчендә һәм аннан читтә аралашу даирәсен булдыра. Шуңа күрә дә бүгенге көндә татар яшьләре дискурсында кулланылышта йөргән төрле лексик катламнарны өйрәнүне актуаль дип саныйбыз.

Мәкаләнең максаты – хәзерге татар яшьләре дискурсында алынмалар кулланылышын тикшерү.

Тикшеренүнең өйрәнү объекты – хәзерге татар яшьләре дискурсы, ә тикшеренү предметы буларак хәзерге татар яшьләре дискурсында алынмаларның тоткан урынын билгеләү тора.

Татар яшьләре сөйләмендә алынмалар гаять зур урын алып тора. Гомумән, һәр телдә дә алынмалар бар, бу – табигый күренеш, чөнки бер генә телне йөртүче халык та изоляцияләнеп яши алмый. Хәзерге татар яшьләре дискурсындагы алынмалар, башлыча, алынмалар, калькалар, жаргоннардан

гыйбәрәт. Килеп чыгышы буенча татар яшьләре сленгындагы алынмаларны без ике төрлегә бүлеп карыйбыз: гарәп-фарсы алынмалары һәм рус-европа алынмалары. Билгеле, соңгылары бүгенге көн яшьләр телендә күпчелекне тәшкил итә, шулай да сленгта гарәп-фарсы алынмаларының да булуын инкяр итеп булмый. Соңгы елларда татар яшьләре дискурсында гарәп-фарсы алынмалары актив кулланылышка кертелә башлады. Мәсәлән: *сөбханалла, машалла, нөсхәләү, сәхифә, җария – рабыня, сарайби – придворный, мәмләкәт, әйдаман, кулдаш, сәлкеш, алан* һ.б.

Бүгенге көндә яңа технологияләр өлкәсендә яңа терминнар барлыкка килүе, шулай ук рус һәм чит телләрдән алынмалар үтеп керү процессы көчәюе белән аерылып тора. Татар телендә алынмалар темасы – тарихи аспекттагы тел үзгәрүләрен анализлаучы татар лингвистларының тикшерү темасы булып тора. Тикшерүчеләр билгеләп үткәнчә, XX гасыр башы белән чагыштырганда, хәзерге вакытта татар телендә сөйләшү рус теленнән кергән алынмаларның артык төрләнеше һәм лингвистик нормадан тайпылу белән аерылып тора. Л.К. Бәйрәмова фикеренчә, рус сүзләренең татар теленә үтеп керү процессы революцияләр һәм сугышлар, мәгариф реформалары, зур төзелеш проектлары һәм бер үк территориядә төрле этник төркемнәр вәкилләренең бергә яшәве кебек күп вакыйгалар белән аңлатыла. Г.Р.Галиуллина, үз чиратында, варваризмнарны – татар телендә чит ил сүзләренең актив куллануына игътибарны җәлеп итә [2, с. 112].

Бер очракта алынма лексемалар башка телгә күчкән вакытта сүзнең семантикасын саклап кала *(шухер, кайф һ.б.)*, ә икенче очракта, мәгънәсен үзгәртеп, образлылык, экспрессия, кызыклы төсмер, ала *(корона – коронавирус, спутник – вакцина атамасы)*. Гади сөйләм теленнән кергән сүзләр чагыштырмача кимрәк кулланыла.

Интернеттан алынмаларның сөйләмгә үтеп керүе – неологизмнар барлыкка килү өчен традицион канал. Шулай итеп, 2021–2023–нче еллар аралыгында Тикток (Рәсәйдә эшчәнлеге тыелган социаль челтәр) иң модалы социаль челтәрләрнең берсенә әверелде һәм бу социаль челтәрдә таралган күпчелек алынмалар яшьләр дискурсында да үз урынын тапты. Мисал өчен, *«реки»* (*рекомендации* сүзенең кыскартылган варианты*), стриммер, тиктокер* һ.б. сүзләр татар яшьләре дискурсында еш кулланыла башлады. Коронавирус эпидемиясы да яшьләр дискурсына бик күп яңа сүзләр кертте. Оксфорд сүзлеге буенча 2021 нче елда ел сүзенә әверелгән «вакцина» сүзе дә бу исемлектә. А.С. Пушкин исемендәге тел һәм әдәбият институты белгечләре исә 2021нче ел сүзе дип «Спутник» (вакцина атамасы) сүзен атаган. Әмма бу безгә мәгълүм булган

спутник мәгънәсендә түгел, ә коронавирустан саклаучы Россиядә чыгарылган вакцинаның атамасы мәгънәсендә телгә кереп урнашкан. Бу сүз үзе инде күптән неологизм булмаса да, 2021нче елда аның семантикасы үзгәреш кичерә, семантик кыры киңәйгән дип әйтә алабыз. Моннан тыш, иң еш кулланыла торган неологизмнар арасында белгечләр *куар код, антипрививкачы, антиваксер* кебек эпидемия белән бәйле лексемаларны да атыйлар.

Билгеле булганча, язма телгә караганда телдән сөйләмгә башка тел йогынтысы бермә-бер көчлерәк. Хәзерге шартларда татар теленә рус теленең йогынтысы шактый көчле. Аның аркылы, күбесенчә телдән сөйләгәндә функцияләшүче, шактый күләмдә инглиз-американизмнардан гыйбарәт неологизмнар керә. Аларның типик чагылыш өлкәсе булып, көнкүреш тора. Мәсәлән, *шорты, мейк-ап, паб, кофе-хаус, киборг, триллер, лифтинг-крем, сайдинг, имидж һ.б.* Мондый төр алынмалар, аңлатмалы һәм татар теленең ике телле сүзлекләрендә урын алмасалар да, яшьләр тирәлегендә, аның аерым иҗтимагый группаларында актив таралганнардан саналалар [1, с. 14].

Нәтиҗә ясап шуны ассызыклап үтик: хәзерге татар яшьләре дискурсы күбесенчә алынмалардан тора. Алар арасында кимрәк дәрәҗәдә гарәп-фарсы алынмалары, башлыча – рус теленнән һәм рус теле аша башка Европа телләреннән кергән алынма сүзләр тәшкил итә. Алынмалар әдәби телдәге сүзләрнең кыскартылуы, берникадәр үзгәртелүе нигезендә барлыкка килгәннәр. Тора-бара бу алынмалар актив лексикага кертеп карала башлый, чөнки бик тиз үз кулланылыш даирәсендә, ягъни яшьләр тирәлегендә, әлеге лексика көндәлек кулланылышка ия башлый. Шул ук вакытта, хәзерге татар яшьләре дискурсындагы алынмалар ничек тиз актив кулланылышка кергән, шундый ук динамика белән юкка чыгарга, онытылырга да мөмкин.

## ӘДӘБИЯТ

1. Абдуллин Е.М. Английский подпласт заимствованной лексики современного татарского литературного языка: Автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2007. – 28 с.

2. Галиуллина Г.Р. Сленговая лексика в современном татарском языке // Языковые контакты народов Поволжья и Урала: сб. ст. XI Международного симпозиума (Чебоксары, 21-24 мая 2018г.) / сост. и отв. ред. А.М. Иванова, Э.В. Фомин. Чебоксары: Изд-во Чуваш. ун-та, 2018. – 352 с.

**Э.А. РАХИМОВ**

*учитель английского и арабского языков*

*МБОУ «Татарская гимназия № 2 при КФУ» Московского района г. Казани*

# ПОТЕНЦИАЛЬНЫЕ ВОЗМОЖНОСТИ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ СЕТИ ИНТЕРНЕТ И МУЛЬТИМЕДИЙНЫХ ТЕХНОЛОГИЙ ПРИ ОБУЧЕНИИ ИНОСТРАННОМУ ЯЗЫКУ В ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ УЧРЕЖДЕНИЯХ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Аннотация.** Обучение иностранному языку в средней школе имеет в качестве целевой доминанты – формирование коммуникативной компетенции ученика, то есть приобретение и формирование им навыков правильного применения знаний в области иностранного языка и межкультурного взаимодействия, соответственно, Интернет, являясь глобальной сетью, предполагает именно межкультурное взаимодействие представителей различных языковых групп, а, значит, его можно рассматривать в качестве принципиально нового средства обучения и мощного инструмента познания, требующего развития методов и организационных форм обучения. Кроме того, Интернет при обучении иностранному языку открывает широкие возможности для общения с носителями языка.

**Ключевые слова:** Интернет, обучение, компетенция, язык, коммуникация.

**Abstract.** Teaching a foreign language in secondary school has as a target dominant – the formation of a student's communicative competence, that is, the acquisition and formation of skills for the correct application of knowledge in the field of a foreign language and intercultural interaction, respectively, the Internet, being a global network, assumes precisely intercultural interaction of representatives of various language groups, and, therefore, it can be considered in as fundamentally new means of learning and a powerful tool of cognition, requiring the development of methods and organizational forms of learning. In addition, the Internet, when teaching a foreign language, opens up a wide range of opportunities for communication with native speakers.

**Keywords:** Internet, teaching, competence, language, communication.

Овладение коммуникативной компетенцией предполагает овладение иноязычным общением в единстве всех его функций: информационной, регулятивной, эмоционально-оценочной и этикетной. В ходе реализаций этих функций решаются определенные коммуникативные задачи и формируются основные коммуникативные умения. Обучение иностранному языку на каждом этапе школьного обучения имеет свою специфику, учитывающую возрастные, психолого-педагогические характеристики личности учеников на данном этапе обучения, а также их уровень знания в области данного языка. Естественно, цели обучения также варьируются при наличии ряда общих моментов.

Для применения Интернета в качестве средства обучения, необходимо предварительное освоение учениками правил пользования персональным компьютером и его обучающих программ. Рассмотрим их виды и ключевые особенности: 1) **компьютерные обучающие системы** – в таких системах особое значение приобретает применение мультимедиа-технологий. В частности, использование звука позволяет применять компьютерные обучающие системы для обучения и развития детей младшего и среднего школьного возраста, еще не умеющих или только начинающих читать на иностранном языке. При этом компьютер (преподаватель) в процессе продвижения по игре-обучению дает ребенку инструкции. Важно отметить, что в однопользовательских компьютерных системах исключено «реальное» диалоговое наполнение. Поэтому при разработке программ, предназначенных для индивидуального обучения, необходимо с особой тщательностью разрабатывать как общую структуру условного диалога, так и, в особенности, формулировки, дополнения и уточнения заданий, вопросов и других подобных элементов. Функционально развитые, удобные программы с интуитивно-понятным интерфейсом позволяют улучшить диалог обучающей программы с пользователем, расширить сферы применения программы. Особое значение имеет адекватность реакции компьютера на логичное (ожидаемое) действие обучаемого, а также универсальность в плане интерпретации или выдачи соответствующего сообщения в случае некорректной постановки вопроса обучаемым; 2) **автоматизированные и экспертные обучающие системы** – такие системы могут накапливать информацию о прохождении обучаемым как всего курса иностранного языка, предусмотренного школьной программой за конкретный год обучения, так и отдельных его (ее) частей, а затем использовать сохраненные данные при построении диалогов, моделировании подсказок и помощи. Обучающая система должна обладать определенным интеллектом при создании оценочных суждений, потому что после нескольких неудачных ответов реплики типа «отличное решение», «замечательно» и т.п. могут вызвать отрицательную реакцию. Очевидно, целесообразнее отказаться от промежуточной оценки или не использовать ярко выраженную эмоциональную окраску для такой оценки. Возможность задавать вопросы обучающей программе позволяет обучаемому почувствовать в компьютере собеседника, что нередко снимает страх перед работой (общением) с неодушевленной и сложной техникой; 3) **компьютерные обучающие программы, функционирующие в рамках интрасети школы** – рассчитаны на максимально приближенное к действительности диалоговое взаимодействие между обучаемыми; оно позволяет им осуществлять взаимо-

помощь, участвовать в коллективном решении задач и деловых играх; 4) **Skype-технологии** – применение таких технологий обеспечивает при обучении иностранному языку живое общение, при котором смысловую нагрузку несут не только слова, но и жесты, мимика и другие невербальные элементы. Используя Интернет в обучении иностранному языку, учащиеся могут принимать участие в тестировании, в викторинах, конкурсах, олимпиадах, проводимых по сети Интернет, переписываться со сверстниками из других стран, участвовать в чатах, видеоконференциях и т.д. Также они могут получать информацию по проблеме, над которой работают в данный момент в рамках проекта. Это может быть совместная работа российских школьников и их зарубежных сверстников из одной или нескольких стран. В качестве примера нами приводится Международная образовательная и ресурсная сеть **I*EARN**, которая предлагает учащимся лучше понять жизнь на планете, участвовать в совместных исследовательских, научных и творческих проектах, развивать любознательность и мастерство. Она объединяет более 3000 школ и молодёжных организаций в 70 странах. В частности, тексты ресурсной сети **I*EARN** проекта **«Мои впечатления о стране, которую я посетил»** могут пригодится при изучении устной темы **«Путешествие»**, тексты проекта **«Street's children»** помогают разобраться в проблеме бездомных детей. Материалы такого рода интересны тем, что сами подростки обсуждают разные темы, поднимают волнующие их вопросы, предлагают их решения.

К настоящему времени в обучении иностранному языку в средней школе фундаментальных преобразований не произошло: обучение по-прежнему основывается на базовых принципах наглядности, системности, доступности и достаточности изложения материала, средства обучения также подразделяются на те же базовые группы. Однако, в области технических средств обучения произошел существенный прогресс – активно используются последние разработки в области компьютерных и информационных технологий, в частности, широкое применение получили интерактивные доски, обучающие компьютерные программы и комплексы, начинает внедряться использование сети Интернет в обучении иностранному языку, которая обладает для этого широкими потенциальными возможностями. Использование того или иного свойства в сочетании с последними разработками науки и техники позволяет устраивать онлайн конференции, тематические творческие вечера на иностранном языке, музыкальные концерты, в рамках которых исполняются песни изучаемой страны. Кроме того, общаясь с помощью международных социальных сетей, которые стали весьма популярны в последние годы, применяется

своего рода метод погружения в языковую среду, где ученики могут тренировать и навыки правильного письма, и если после более близкого общения применяются Skype-технологии, то и правильного произношения. В ходе проведенного исследования была самостоятельно создана методика для диагностики уровня развития базовых знаний в области английского языка, а также программа заданий для формирующего эксперимента, предполагающих практическое использование потенциальных возможностей сети Интернет в обучении иностранному языку в средней школе. Полученные в контрольном эксперименте результаты свидетельствуют о высоком уровне владения базовыми знаниями в области английского языка. Сравнительный анализ полученных результатов показывает достоверность выявленных различий в уровне базовых знаний английского языка между результатами констатирующего и контрольного экспериментов, а, значит, использование потенциальных возможностей сети Интернет при обучении иностранному языку в средней школе обладает высокой эффективностью.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Баклашкина М.В. Обучение иноязычному межличностному общению на занятиях по иностранному языку в школе и вузе // Иностр. языки в школе. – 2009. – № 1. – С. 9-13.

2. Бим И.Л. Некоторые особенности педагогического процесса. // Английский язык 5-9 классы. – [Электронный ресурс]. Режим доступа: http://www.prosv.ru/ebooks/Bim_Nemeckii_5-9kl/3.html

3. Бордовская Н.В., Реан А.А. Педагогика. Учебник для вузов. – СПб: Питер, 2000. – 304 с.

4. Буланова-Топоркова М.В. Педагогика и психология высшей школы: учебное пособие. – Ростов-на-Дону: Феникс, 2002. – 544 с.

5. Буторина Е.П. Об использовании компьютерных технологий в конрастивных исследованиях и обучении языку / Е.П. Буторина, Н.И. Сайтанова // Московский лингвистический журнал. – 1996. – N 3. – С. 70-79.

**А.А. РАХМАТУЛЛИНА,**

*магистрант,*

*Казан федераль университеты*

**Г.К. ҺАДИЕВА,**

*филология фәннәре кандидаты, доцент*

*Казан федераль университеты*

# БАЛАЛАР СӨЙЛӘМЕНӘ ФОНОСЕМАНТИК АНАЛИЗ (ГӨЛИНӘ ШӘЙХИ ШИГЫРЕ МИСАЛЫНДА)

**Аннотация.** В статье было отмечено выявление и описание фоносемантических особенностей поэтического текста Гулины Шайхи. Работа по-своему уникальна и приносит

новость, так как помимо методов описания, анализа, синтеза, обобщения и наблюдения используется экспериментальный метод. Он предоставляет дополнительные возможности для исследования фонетической выразительности стихотворения. Программа Speech Analyzer же оказывает большую помощь в реализации этого эксперимента. Проведенный анализ позволил выяснить, что в поэзии Г. Шайхи фонема играет важную смысловую роль. Поэтесса от-открывает потенциал звука и использует его вместе с другими средствами выразительности в своих целях. Рассказчик же понимает все те смыслы, которые хотел передать автор.

**Ключевые слова:** экспериментальная фонетика, фоносемантический анализ, татарский язык, эмоциональность

**Abstract.** The article noted the identification and description of the phonosemantic features of the poetic text of Gulina Shaikhi . The work is unique in its own way and brings news, since in addition to the methods of description, analysis, synthesis, generalization and observation, an experimental method is used. It provides additional opportunities for the study of the phonetic expressiveness of the poem. The Speech Analyzer program also provides great assistance in the implementation of this experiment. The analysis made it possible to find out that the phoneme plays an important semantic role in the poetry of G. Shaikhi. The poetess discovers the potential of sound and uses it together with other means of expression for her own purposes. The narrator understands all the meanings that the author wanted to convey.

**Keywords:** experimental phonetics, phonosemantic analysis, tatar language, emotionality

Чит илләр психолингвистикасында фонетик мәгънә һәм фонетик ассоциацияләрнең барлыгы эксперименталь рәвештә расланган. Телләр үсешендә фонетик мәгънәнең мөһимлеге билгеләнде. Тавышларның экспрессив һәм символик мәгънәләре барлыгы да танылды. Фәнгә «фонетик мәгънә», шулай ук «фонетик мәгънәнең төс аспекты» терминнары кертелә, фоносемантик кыр феномены сурәтләнә [5, с. 28].

Нәкъ менә лирик әсәр мисалында галимнәр текстның тавыш оештыру ысулларын һәм алымнарын күзәтә ала. Бу исә мөһим мәгънәләрне ачарга мөмкинлекләр бирә. С.А. Марухина үзенең «Шигъри текстны фоносемантик тикшерү методлары» дигән хезмәтендә югарыда бәян ителгән фикерләрен чираттагыча исбатлый: «Хәзерге вакытта шигырьнең мәгънәви ягы аваз белән аерылгысыз бәйләнештә яши, нәкъ менә бу «авазлы» як шигъриятне сүз иҗатының төре буларак билгели...» [4, с. 184-187].

Шигърияттә, музыка сәнгатендәге кебек, әсәрнең аваз ягы гаять мөһим. Шуңа күрә дә шагыйрьләр сүз һәм аның яңгыраш ягына зур әһәмият бирәләр. Шул рәвешле шагыйрьләр әсәрләренең укучыларга йогынтысын көчәйтә. Шигъри сөйләм – ритмлашкан сөйләм. Анда барлык сүзләр дә билгеле бер урынга ия. Көндәлек яки прозаик сөйләмдә дә без яңгырашның нинди дер нечкәлекләренә игътибар итмәскә мөмкин, ләкин шигърияттә тавыш идеяне тапшыруда һәм кабул итүдә катнаша.

Димәк, мондый шартларда укучылар да язучының кайбер мәгънәләрен һәм яңгырашын белдерү өчен кулланыла торган аерым алымнарны таный ала. Әмма уку-укыту процессында мәгънәне дөрес табу һәм аны балаларга тапшыру күбрәк укытучылар җилкәсенә төшә. Алар шигъри текстның мәгънәсен аңлап, фоносемантик яктан анализлап аудиториягә укыган вакытта гына укучының әсәр асылын үзләштерүенә ирешә ала.

Шуңа сөйләме олы буыннан күпкә аерылган, әле тембры формалашмаган, тавыш диапазоны үзгәрүчән, югары яңгыравыклы булган бала сөйләмен экспериментал ь тикшерү теләге туды. Бу юлда безгә Speech Analyzer программасы ярдәмгә килде: сөйләмне интенсивлык [Дб], пауза [с.] һәм тон ешлыгы [Гц] күрсәткечләрен тапшыра торган графиклар аша экспериментал ь өйрәндек.

Алда әйтелгәннәргә бәйле төстә яшь язучы – Гөлинә Шәйхи иҗаты кызыксыну уята. Шагыйрә мәгънә ягына гына түгел, бу мәгънәне белдерү планына да игътибар бирә.

«Әнием, мин сине...» әсәрен интернет челтәрендә сөйләп популярлык казанган яшь башкаручы – ул Галиәскәр Сидеев. Поэтик әсәрне уку барышында әнигә булган мөрәҗәгатьләрдән соң 0,3 с. тукталыш ясала. Паузалар юл саен да, юлара да эшләнелә. Беренче строфада беренче ике юл бер сулышта укыла, ә өченче юлдан соң 0,4 с. пауза урын алган. Икенче строфадагы икенче юлдан соң кыска 0,2 с. тукталыш ясала. Соңгы строфаның беренче юлындагы «әни» эндәш сүзен әйтүгә 0,3 с. пауза чагылыш таба. Һәм соңгы строфаның икенче юлы азагында 0,5 с. туктап торыла. Строфалардагы өченче һәм соңгы юллар саен 0,4 с. тукталыш күзәтелә. Икенче юлдагы «зур» сыйфатының 0,6 с., «мәңге» сүзенең 0,4 с. озынлык белән әйтелүе аерым игътибарга лаек.

Интенсивлыкның иң югары ноктасы – 63 дб. Моннан тыш 20,8 дб «әнием», 26,3 дб «җылы», 28,6 дб «мәңге» сүзләрендә, 20,9 дб «синең өчен» сүзтезмәсендә ирешелә. Әлеге күрсәткечләр аша Әни кешенең кыйммәте күрсәтелә, аның җылылык һәм наз чыганачы булуы искәртелә. Гомумән алганда, «әнием» сүзе аерым йомшаклык һәм югарылык белән әйтелә. Аңлашыла ки, бала өчен ул тиң булмаган илаһи вә мәңгелек яклаучы, саклаучы зат («Синең кебекләр булганда мин мәңге туңмам»).

Тон ешлыгын караган вакытта, аның иң түбән күрсәткече 35,27 Гц күләмендә «үрнәк» сүзендә үлчәнде. Киресенчә, иң югарысына игътибар юнәлтсәк, аның 481 Гц белән «әнием» эндәш сүзендә ирешелүен күрәбез. Бу, әлбәттә, ананың баласы өчен эталон, чын үрнәк, маяк булуы хакында сөйли.

Шулай итеп, махсус платформаны куллану зур мөмкинлекләргә юл ачты. Аудиоязманы Speech Analyzer программасына кертеп шигырьнең аерым

өлешләрен, ягъни сүзләрне, гыйбарәләрне, сүзтезмәләрне, тулы бер юлларны анализлый алдык. Интонация һәм шигырьнең төп мөһим мизгелләре үзара бәйләнгән дигән нәтиҗәгә Г. Шәйхинең «Әнием мин сине...» шигыре мисалында инаныл булды. Бу үз чиратында сөйләүченең төп мәгънәви йөкләнешне сүзләрдә, сүзтезмәләрдә күрсәтергә тырышуын аңлата. Шулай итеп, язучының үз иҗат җимешенә салган мәгънәсе белән шигырьне укучының эмоциональлеге, кайбер урыннарда тукталыш һәм пауза ясаулары арасында чыннан да бәйләнеш бар.

## ӘДӘБИЯТ

1. Байчура У.Ш. Татар теленең кайбер фонетик үзенчәлекләре (Эксперименталь фонетик мәгълүматлар буенча) // Татар теле һәм әдәбияты мәсьәләләре. – Казан, 1963. – 127-140 б.

2. Воронин С.В. Основы фоносемантики / С. В. Воронин — Л.: Изд-во Ленингр. ун-та, 1982. – 243 с.

3. Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 108 б.

4. Марухина С.А. Методы фоносемантического исследования поэтического текста // Ярославский педагогический вестник. – 2013. – № 4. – 184-187 с.

5. Фадеева Е.Н. Фоносемантическая характеристика индивидуального стиля автора: дис… канд. филол. наук [Электронный ресурс]: URL: https://new-disser.ru/_avtoreferats/01002634945.pdf?ysclid=lnnj9rzb52980635446 (Дата обращения: 09.02.2023).

**С.П. САБАНИНА**

*учитель начальных классов*

*муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Гимназия № 75»*

*Московского района г. Казани*

# ПОЛИКУЛЬТУРНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ: ДИАЛОГ КУЛЬТУР И БИЛИНГВАЛЬНОЕ ОБУЧЕНИЕ

**Аннотация.** В статье говорится о системе билингвального образования. Кратко изложены история ее фор-мирования, причины и следствия трансформации многоэтнического образования в поликультурное. Отмечена взаимосвязь билингвального и поликультурного обучения, укрепление которой происходит не только благодаря историческим и социокультурным предпосылкам, но и в связи с развитием общемировых традиций философии, педагогики и психологии.

Конкретизировано понятие «билингвальное обучение», рассмотрены его модели. Их предпочтение в каждой стране и в каждом регионе зависит от специфических, порой очень сложных социолингвистических условий.

Показана актуальность обучения на двуязычной основе, обусловленная, прежде всего, тенденцией к всеобщей интеграции в экономической, культурной и политической сферах. Перечислены преимущества билингвального образования, которое обеспечивает учащимся широкий доступ к новой информации в различных областях в соответствии с индивидуаль-

ными потребностями, возможности непрерывного повышения своего образовательного уровня, а также конкурентоспособность в будущем на общеевропейском и мировом рынке.

**Ключевые слова:** билингвальное обучение, межкультурное взаимодействие, поликультурное образование.

**Abstract.** The article talks about the system of bilingual education. The history of its formation, the causes and consequences of the transformation of multi-ethnic education into multicultural education are briefly outlined. The relationship between bilingual and multicultural education is noted, the strengthening of which occurs not only due to historical and sociocultural prerequisites, but also in connection with the development of global traditions of philosophy, pedagogy and psychology.

The concept of “bilingual education” is specified and its models are considered. Their preference in each country and in each region depends on specific, sometimes very complex sociolinguistic conditions.

The relevance of education on a bilingual basis is shown, due, first of all, to the trend towards universal integration in the economic, cultural and political spheres. The advantages of bilingual education are listed, which provides students with wide access to new information in various fields in accordance with individual needs, opportunities for continuous improvement of their educational level, as well as competitiveness in the future in the pan-European and global market.

**Key words:** bilingual teaching, cross-cultural communication, poly-cultural education.

Поликультурное образование в России приобретает особую значимость и сложность в связи с тем, что социально-экономические и политические реформы привели к созданию новых условий обучения. В этом контексте поликультурное образование способствует формированию национальной идентичности и культурного самосознания учащихся, с одной стороны, и препятствует их этнической и культурной изоляции от других стран и народов, с другой. Поликультурное образование в развивающихся странах требует нового понимания их образа жизни, национальных идей, образовательных традиций и норм общения. Педагоги стремятся достичь сближения между формальным, абстрактным и независимым от контекста мышлением, характерным для развитых стран, и непосредственным опытом и чувственным мышлением, характерным для развивающихся стран. Для этого преподаватели опираются на многие национальные, международные педагогические, образовательные, психологические традиции. Особый интерес представляет программа "широкого чтения", разработанная Коменским в XVI веке [6]. Этот великий мыслитель сделал "обширное чтение" универсальной образовательной программой для всего человечества, основанной на общности людей, их потребностях и стремлениях. Методы адаптации поликультурного образования, основанные на идеях открытости, культурного диалога и культурного плюрализма, не получили широкого распространения в отечественных исследованиях [2]. Для России тем более

важно сохранять и обогащать как русскую культуру, являющуюся доминирующей в стране, так и национально-культурное своеобразие других народов, проживающих в России. В то же время для России все более актуальной становится интеграция отечественной системы образования в глобальное общеевропейское культурно-образовательное пространство. Принцип диалогичности не является общепризнанным в педагогике и философии. С точки зрения нашего исследования, диалогичность - это универсальный принцип, организующий сознание человека и обеспечивающий условия для культурного саморазвития, воспроизводства индивидуальности и коммуникативной компетентности. Все исторические и культурные явления – это продукт общения, взаимодействия, результат отношений с самим собой, обществом и Вселенной. Вся история и культура - это результат взаимодействия человека с самим собой, обществом и Вселенной. Феномен взаимодействия (в том числе и «событийного») с другими нациями и народами, проживающими на территории нашей страны. На наш взгляд, это один из важнейших культурных феноменов, который является результатом отношения к себе, собственному бытию, социальным отношениям, а поскольку он является продуктом общения, к собственной личности, социокультурной среде и межличностным отношениям, что приводит к установлению связи с самим собой. Это позволяет людям позитивно взаимодействовать с окружающими их людьми [5].

Поликультурное образование основано на третьем типе межкультурных отношений. По мнению Д. Драгонского, иллюзия самодостаточности основана на многочисленных эстетических и культурных факторах. Иллюзия самодостаточности основана на существовании внутри культуры множества эстетических и мировоззренческих конфликтов, которые, казалось бы, должны гарантировать ее саморазвитие, свободное от внешних воздействий. Однако такие конфликты формируются внутри данной культурной формации и зачастую осваиваются настолько глубоко, что перестают считаться чужеродными [2, с. 23-215]. Культивирование первого отношения в обществе приводит к эгоцентризму, самоотречению, добровольному подчинению другим культурам – таким явлениям, как англомания, франкомания, германомания. Следствием развития второго типа отношений является прочное закрепление в общественном сознании чувства неполноценности представителя культуры как объекта, ведущее к добровольному подчинению, т.е. идентификации с субъектом другой культуры. В.С. Библер разделяет «историческую преемственность» на две формы. Одна - схематизм, поднимающийся по лестнице прогресса и развития, другая - культурный диалог, интегрированный с другим и замкнутый «в себе»

[4]. Такая культура может выжить и развиваться (как культура) только на периферии культуры, в диалоге с другими интегрированными и закрытыми культурами, преодолевая при этом собственную ограниченность» (Г.Д. Гачев). Краткое описание понятия «диалог культур» может помочь осмыслить его значение в теории поликультурного образования. Монолог вполне закономерно ассоциируется с авторитаризмом, директивностью, нетерпимостью к чужому языку и взглядам, ритуалами, словом, со всем тем, что неприемлемо в теории поликультурного образования [3].

Дмитриев отмечает, что то, что многие исследователи называют поликультурным или мультикультурным образованием, по сути, является полиэтническим образованием. В то же время можно выделить несколько особенностей поликультурного образования, важнейшими из которых являются специфические социально-воспитывающие и ценностно-ориентированные качества, позволяющие людям, заканчивающим среднюю или высшую школу, вступать в углубленную межкультурную коммуникацию, понимать разные культуры и проявлять толерантность к носителям разных культур, Это позволяет рассматривать поликультурное образование как особый способ развития коммуникативных и эмпатических навыков [1].

Поскольку данный аспект включает в себя развитые формы общения, гарантирующие формирование коммуникативно-ориентированной личности, способной к межкультурному общению, большое значение имеет изучение возможностей, которые предоставляет билингвальное образование для формирования такой личности. Если для лингвистики на первом месте стоит языковая компетенция, отражающая степень владения родным и иностранным языком, то для психолингвистики важно то, когда и для каких целей индивиды и социальные группы используют язык. На наш взгляд, самым большим недостатком программ переходного обучения является игнорирование подлинного билингвизма и отсутствие эквивалентности между родным и национальным языком.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Веденина, Л.Г. Межкультурное обучение как полилог языков и культур // Межкультурная коммуникация: тез. докл. – Иркутск, 1993. – С. 42-47.

2. Выготский Л.С. Собр. соч. Т. 3. – М., 1983. – 145 с.

3. Дмитриев Г.Д. Многокультурное образование. – М.: Народное образование, 1999. – 208 с.

4. Менская Т.Б., Поликультурное образование: Программы и методы. В: Общество и образование в современном мире. Сб. материалов из зарубежного опыта. Вып. 2. – М., 1993.

5. Певзнер М.Н., Ширин А.Г. Билингвальное образование в контексте мирового опыта. – Новгород, 1999. – 94 с.

6. Шафикова А. В. Мультикультурный подход к обучению и воспитанию школьников: автореферат дис. ... кандидата педагогических наук : 13.00.01. – Казань, 1999. – 18 с.

**Р.К. СӘГЪДИЕВА,**
*филология фәннәре кандидаты, доцент*
*Казан федераль университеты*

**Г.Г. ӘСХАДУЛЛИНА,**
*магистрант,*
*«Адымнар – Казан» күптелле мәктәбенең*
*туган тел һәм әдәбияты укытучысы*

# ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ) ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНДӘ «ТАТАР ДӨНЬЯСЫ» ТЕМАСЫНЫҢ ЯКТЫРТЫЛЫШЫ

**Аннотация.** В статье рассмотрены основные подходы в обучении татарскому родному языку, актуальные направления работы по формированию ценностного отношения к родному языку как феномену национальной культуры. На конкретных примерах раскрываются особенности обучения языку как средству формирования языковой личности, обладающей духовно-нравственными ценностями.

**Ключевые слова:** родной татарский язык, языковая личность, антропоцентрический и аксиологический подходы в образовании, воспитательный потенциал обучения татарскому языку, язык как феномен национальной культуры.

**Abstract.** The article discusses the main approaches to teaching the Tatar native language, current areas of work on the formation of a value-based attitude towards the native language as a phenomenon of national culture. Specific examples reveal the features of language teaching as a means of forming a linguistic personality with spiritual and moral values.

**Keywords:** native Tatar language, linguistic personality, anthropocentric and axiological approaches in education, educational potential of teaching the Tatar language, language as a phenomenon of national culture.

Туган телләрне өйрәтүнең мәдәни аспекты уку-укыту процессында әһәмиятле бер бүлеккә әверелде, чөнки ул халыкның яшәешен һәм мәдәниятын өйрәнергә булыша, ә бу исә укучыларда туган телләренә карата фәнни кызыксыну, мәхәббәт һәм хөрмәт хисләре тәрбияләргә булышлык итә. Бу урта мәктәптә татар телен укытуда милли-мәдәни компетенцияне формалаштыру белән бәйле мәсьәләләрнең мөһимлеген һәм актуальлеген билгели. Практик яктан караганда, мәдәни аспект аралашу максатын тормышка ашыруга юнәлдерелгән.

Туган тел (татар теле) дәресләре соңгы елда дүрт зур лексик темага бүлеп бирелә: «Мин», «Тирә-як, көнкүреш», «Туган җирем» һәм «Татар дөньясы».

Туган тел (татар теле) дәресләрендә «Татар дөньясы» темасын өйрәнү тел материалларын өйрәнүдән тыш, халыкның гореф-гадәтләре, тарихы, мәдәнияте, әдәбияты, географиясе, икътисады, сәясәте турындагы мәгълүматлар комплекслы белем бирү процессына әверелергә тиеш.

«Татар дөньясы» темасы, гадәттә, дүртенче чиреккә туры килә. Әлеге бүлек грамматиканы үзләштерү белән бәйле булса да, анда иң беренче планга лексик темалар алгы планга чыга. Теге яки бу лексик тема аша укучыларны, беренчедән, тәрбияләү максаты үтәлсә, икенчедән, коммуникатив компетенция тормышка ашырыла, өченчедән, теге яки бу фактик материал аша укучыларга тиешле теоретик материал аңлатыла, төшендерелә.

Сәгъдиева Р.К., Фәйзрахманова К.Ф. авторлыгындагы 2 сыйныф дәреслегендә «Татар дөньясы» темасы укучыларга сүз һәм сүзтезмә төшенчәләрен аңлату белән башлана. Ул «Лалә чәчәге» дип аталган лексик тема белән бәйле алып барыла. Бу исә юкка түгел, чөнки татар халкының көнкүрешендә, кул эшләрендә нәкъ менә лалә чәчәге төп урынны алып тора. Укучыларга татар халкының милли киемнәре (читек, итек, кәләпүш, калфак) турында аңлатма бирелә, аларның бизәлеше чагылыш тапкан күрсәтмә материаллар да дәреслектә урын ала. Милли киемнәр турында сөйләшкәннән соң, «Фигыль» темасы милли ризыклар турында сөйләшүдән башлана. Аерым бер күнегүдә укучы үзенең яраткан ризыгы турында презентация дә ясарга тиеш. Бала аның ничек әзерләнүен, әзерләү өчен нинди азык-төлек кирәклеген, әлеге ризыкның файдалы сыйфатлары һ.б. турында иптәшләре алдында чыгыш ясый. Татар халкы элек-электән файдалы үләннәр җыйган, киптергән. Алар дәвалану өчен дә, чәй кайнату өчен дә кулланылган. Әлеге бүлектә шул турыда да мәгълүмат алып була. Җөмлә төрләрен аңлатканда, татар халкының һәр эшне күмәк башкарганлыгы, гаиләдәге татулык турында аңлатыла. Тойгылы җөмләләрнең үзенчәлекләре турында белешмә биргәндә, татарлар куллана торган исәнләшү, саубуллашу калыплары бирелә [1, б. 84-111].

3 сыйныф дәреслегендә «Татар дөньясы» темасы сыйфат, җөмлә, җөмләнең баш кисәкләре, аергыч темаларын аңлату белән бәйле. Әлеге бүлектә авторлар татар халкының тормышында билгеле бер урынны алып торган чишмәләр турында сүз алып баралар. Чыннан да, татар халкы чәйне самоварда кайнаткан, суны гел чишмәдән алып кайтканнар, чишмәгә төрле исемнәр биргәннәр, чишмәләрне чистарту саваплы эш булып саналган. Хәзерге көндә дә авыл җирлегендә әлеге гореф-гадәтләр юкка чыкмаган, һәм яшь буын әлеге изге гамәлләрне дәвам итәргә тиеш. Фактик материал Г. Тукай, М. Рәфыйков, Р. Миңнуллин, Д. Гарифуллин һ.б. авторлар иҗатынан тупланган. Марсель

Галиевның чишмәләргә багышланган шигырен укучыларга тәкъдим итү исә предметара бәйләнешне булдырырга ярдәм итә. Мәсәлән:

Чишмә – суның сабый чагы,
Челтер-челтер ашыга.
Ярны тишеп чыга да
Тын инешкә кушыла.
Үз ярларын узып китеп,
Килеп керә Иделгә.

Юлын дәвам иттереп,
Тоташа ул диңгезгә.
Чишмә сулары, диңгездән
Әверелеп болытка,
Туган якка кайтып ява
Кар һәм яңгыр булып та.

Шигырьдә сурәтләнгәннәрне кулланып, укучылар «Су тамчысының сәяхәте» дигән темага хикәя төзеп язарга тиешләр. Әлеге эштә әйләнә-тирә мохит предметы белән турыдан-туры предметара бәйләнеш килеп чыга.

Алга таба Равил Заһидуллинның «Мунчадан соң чәй эчү» дип аталган картинасы бирелә. Бабайның мунчадан соң аяк бөкләп самовардан чәй эчүе, кайнар чәйне тәлинкәгә салып эчү, самоварны чишмә суы салып кайнату һ.б. күркәм гадәтләр турында фикер алышу үткәрелә.

Җөмләдәге баш кисәкләрнең урыны исә «Чәй эчәбез бал белән, бала-чагалар белән» дип аталган лексик тема белән үрелеп китә. Бу очракта татар халкында чәй эчү традицияләре, чәй табыны, милли ризыклар, кунакны сыйлау, табын әзерләү кебек мәсьәләләр кызыклы фактик материаллар, текстлар үрнәгендә укучыларга җиткерелә. «Кунакка рәхим итегез! » дип аталган проект эшендә укучылар үткән грамматик материалны кабатлыйлар, шул ук вакытта чәй һәм әлеге тамырдан ясалган сүзләрнең лексик мәгънәләренә төшенәләр, сүзтезмәләр төзергә өйрәнәләр, чәй куагының кайда үсүе, җитештерелүе белән бәйле кызыклы мәгълүматларга ия булалар. Аергыч темасын аңлатканда, татар халкындагы табын әзерләү үзенчәлекләре, табын артындагы кагыйдәләр турында тәрбия эшләре алып барыла. Табын әзерләү белән бәйле кашыклар турында да кызыклы мәгълүматлар алу дәресне җанландырып җибәрә, укучыларның кызыксынуларын арттыра.

Ел буе үткәннәрне кабатлаганда, Н. Верзилин, Н. Хәкимуллин, Х. Халиков кебек авторларның әсәрләреннән алынган өзекләр дару үләннәре турында файдалы мәгълүматлар бирергә ярдәм итә [2, б. 74-122].

Дидактик материал буларак, бу төр дәреслекләрдә татар халык авыз иҗаты текстлары (халык җырлары, әкиятләр, гыйбрәтле хикәяләр һ.б.) бик отышлы кулланыла. Фольклорның кечкенә жанрларына караган мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар, санамышлар һ.б. мөрәҗәгать итү дә актуаль.

Гомумән алганда, «Татар дөньясы» темасы татар халкының милли гореф-гадәтләре, мәдәнияте, көнкүреше, танылган шәхесләре турында мәгълүмат алырга ярдәм итә.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Сәгъдиева Р.К., Фәйзрахманова К.Ф. Туган тел (татар теле). 2 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Р.К. Сәгъдиева, К.Ф. Фәйзрахманова. – Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2022. – 132 б.

2. Сәгъдиева Р.К., Фәйзрахманова К.Ф. Туган тел (татар теле). 3 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Р.К. Сәгъдиева, К.Ф. Фәйзрахманова. – Казан: «Мәгариф-Вакыт» нәшр., 2022. – 128 б.

**И.Р.САДРИЕВА**

*магистрант*

*Казан федераль университеты, Россия, Казан*

## ТЕЛ МАТЕРИАЛЫН ҮЗЛӘШТЕРҮДӘ ЭЛЕКТРОН ЧАРАЛАР КУЛЛАНУ

**Аннотация**. В данной статье рассматриваются вопросы эффективности использования электронных дидактических средств при обучении татарскому языку. Также анализируются информационные технологии, изучаются как положительные, так и отрицательные стороны внедрения электронных средств обучения в образовательный процесс.

**Ключевые слова:** иностранный язык, электронный дидактический материал, электронный тест

**Abstract.** This article discusses the effectiveness of the use of electronic didactic tools in teaching the Tatar language. Information technologies are also analyzed, both positive and negative aspects of the introduction of electronic learning tools into the educational process are studied.

**Keywords:** foreign language, electronic didactic material, electronic test

Бүгенге көндә педагогик тестлар белем бирү сыйфатын бәяләүнең иң объектив ысулларының берсе буларак билгеләнә. Тестлар, белемне контрольдә тотуның башка традицион ысуллары белән чагыштырганда, белем бирү процессын билгеле бер дәрәҗәдә камилләштерергә мөмкинлек бирә. Белемнәрне объектив критерийлар буенча бердәм таләпләр нигезендә тикшерергә кирәк, һәм әлеге тикшерү белем бирү процессы нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны да үз эченә алырга тиеш. Укытучы тарафыннан традицион рәвештә куела торган билге күпкә субъективрак характерда була. Укучыларның күнекмә һәм

белемнәренә йомгаклау контроле ясалганда, еш кына укытучының куелган билгесе белән укучының белемнәре арасында аерма барлыкка килә. Әлеге аерма укытучының объектив факторларга һәм белем бирү процессында катнашучыларга карата субъектив мөнәсәбәте нәтиҗәсендә туа. Белемнәрне тикшерүнең традицион ысуллары укучының шәхесен тискәре бәяләүгә нигезләнә. Ел саен тест нигезендә контроль үткәрелә, ул һәр укучыга объектив критерийларга нигезләнеп белемнәрен тикшерергә мөмкинлек бирә. Тестта үтелгән темалар буенча биремнәр тәкъдим ителә. Ачкыч буенча тикшерү үткәрелә, дөрес җаваплар исәпләнә һәм узган елгы тикшерү нәтиҗәләре белән чагыштырыла. Тестлар һәрбер укучының белем үзләштерү темпын билгеләргә, белемнәрне тикшерү өчен сарыф ителгән вакытны минималь дәрәҗәгә кадәр киметергә, шулай ук җитешсезлекләрне ачыкларга мөмкинлек бирә. Компьютерда башкарыла торган тестлар белемнәрне контрольдә тотуның гадәти ысулларыннан заманча адаптив уку һәм контроль системаларына күчү мөмкинлеге бирә. Укучыларны укытуда белемнәрне тулысынча үзләштерү системасына нигезләнгән процесска тестлар кулланмыйча ирешеп булмый. Уку елы, гадәттә, тест формасындагы биремнәрдән башлана һәм уку елы азагында укучыларның үзләштергән белемнәрен тикшерү максатыннан, кабаттан тест үткәрелә. Моннан тыш, тестлар сыйныфтагы гомуми күрсәткечләрне ачыкларга ярдәм итә, ул шулай ук укуга карата мотивация үсешенә дә этәргеч бирә.

Чит телләрне өйрәтүнең төп максаты – укучыларда коммуникатив күнекмәләрне үстерү, телне аралашканда – көндәлек тормышта куллана белү. Чит тел дәресләрендә заманча компьютер технологияләрен куллануның төрле вариантлары бар: кирәкле мәгълүматны Интернет челтәреннән эзләү, төрле методик уеннар уйнау һәм төрле юнәлештәге программаларны куллану. Хәзерге педагогик технологияләр укучыларның сәләтләрен исәпкә алып, шәхси үзенчәлекләрен күз уңында тотып эш итү мөмкинлеген бирә. Компьютер программалары белән танышу уку йортларында чит телләрне укытуга карата үз мөнәсәбәтеңне үзгәртергә мәҗбүр итә. Төрле эшчәнлек һәм темалар, мавыктыргыч күнегүләр, электрон дәреслекләрнең төрле характерда булуы укучыларда зур кызыксыну уята. Электрон технологияләр барлык булган мәгълүматны текст, видео һәм тавыш рәвешендә тәкъдим итәргә мөмкинлек бирә. Компьютер программалары ярдәмендә белем бирү, беренчедән, һәр укучының мөстәкыйль гамәлләрен бәяләү мөмкинлеге тудыра, икенчедән, укытучы җитәкчелегендә парлы һәм төркемле эшне гамәлгә ашыра. Хәзерге вакытта чит телләрне өйрәтүдә чагыштырмача уңайлы һәм бик нәтиҗәле ысулларның берсе – электрон дәреслекләр куллану. Электрон дәреслек белем бирүгә карата

индивидуаль һәм дифференциаль караш принципларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Электрон дәреслек ярдәмендә төрле сөйләм эшчәнлеген, мәсәлән, ишетеп аңлау һәм укуны активлаштырырга, белемнәрне тикшерергә, шулай ук укучыларның лексик, грамматик һәм сөйләм күнекмәләрен үстерергә һәм формалаштырырга мөмкин. Электрон дәреслек – компьютер һәм программага нигезләнгән педагогик чара. Ул басма матбугатта булмаган яңа өстәмә мәгълүматны тәкъдим итү өчен эшләнгән. Индивидуаль якын килеп өйрәтү өчен хезмәт итә, шулай ук укучының осталыгын һәм белемен билгеле бер дәрәҗәдә сынап карарга да мөмкинлек бирә. Күп кенә заманча педагогик технологияләр (мәсәлән, проектлар методы, хезмәттәшлеккә нигезләнеп укыту, яңа мәгълүмати технологияләрне куллану), шулай ук Интернет-ресурслар белем бирүдә шәхескә юнәлтелгән алымны гамәлгә ашырырга ярдәм итә, укучыларның сәләтләрен, аларның уку дәрәҗәсен, шулай ук шәхси омтылышларын исәпкә алып, укуны дифференциацияләүне һәм индивидуальләштерүне тәэмин итә. Компьютер программалары белән танышу чит телләрне укыту юнәлешендә мөнәсәбәтне үзгәртүгә китерә. Төрле сәбәпләр аркасында электрон дәреслекләр укучыларда зур кызыксыну уята бу, мәсәлән, әлеге дәреслекнең кызыклы һәм мавыктыргыч булуы, биремнәрнең төрләре һәм темаларның төрлелеге белән бәйле. Хәзерге вакытта мәгълүматны төрлечә тәкъдим итәргә мөмкинлек бирүче төрле чаралар бар. Компьютерга нигезләнеп укыту шактый мөмкинлекләр тудыра: һәр укучының мөстәкыйль гамәлләрен оештыру, шулай ук укытучы җитәкчелегендә төркемнәрдә һәм парлап эшләү. Соңгы вакытта күпләр яңа мәгълүмати технологияләр куллану мәсьәләсен күтәрә. Бу заманча техник чаралар гына түгел, ә уку процессына карата яңа караш, укытуның яңа формалары да.

Компьютер программалары ярдәмендә татар телен өйрәнү укучыларда зур кызыксыну уята. Гадәти дәресне компьютер программалары белән бәйләп алып бару укытучыга үз эшенең бер өлешен компьютерга күчерергә мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта уку процессы кызыклырак һәм нәтиҗәлерәк тә була.

Компьютерларны чит телләрне өйрәтүдә куллану киң яссылыкта карала: компьютерны төрле тел материаллары һәм әйтелеш үрнәкләрен тәкъдим итү, шулай ук чит телдәге сөйләм эшчәнлеге белән таныштыру өчен дә кулланалар. Ул төрле программа материалларын тиешенчә үзләштерү өчен уңайлы шартлар тудыра: барлык укучыларга да тиешле күләмдә күнегү һәм биремнәр тәкъдим ителә. Моннан тыш, укытучы тарафыннан укучыларның эшчәнлеген контрольдә тоту процессында, шулай ук үз-үзеңә бәя бирү чарасы буларак та компьютерның роле зур. Укучыга нәрсә дә булса аңлаешсыз булган очракларда,

1. рус теле йогынтысы нәтиҗәсендә хәзерге татар теленен орфоэпик нормалары бозылу очраклары бар. Мәсәлән, Галимзянов, Тимирова дип, фамилияләрдә орфоэпияне бозулар еш күзәтелә. Гарәп-фарсы телләреннән кергән сүзләр дә бозып әйтелә: хис сүзен тел арты [х] белән әйтү, [и] алдыннан килгән [т] тартыгын артык нечкәртеп, мәсәлән, ихтимал сузен ихт'имал дип әйтү һ.б.; 2. рус теленең йогынтысы татар теленең әдәби нормасына әверелгән очраклар да бар (автомобиль, футбол, спорт һ.б.).

Рус-европа телләре аша татар әдәби теленә үтеп кергән үзенчәлекләрне карап китик:

1. Телебезгә рус-европа телләре сузыкларының үтеп керүе һәм формалашуы.

1) киң әйтелешле [ō] фонемасы 1) басым астында ачык итеп әйтелә: поезд, форма, курорт; 2) басымсыз [ō] сузыгы [а°] белән алышына, ләкин язуда

[ō] сакланып кала: солдат; 3) соңгы иҗектә [р] тартыгы алдыннан [ō] ишетелми, ләкин язуда саклана: доктор.

2) киң әйтелешле [ē] фонемасы басым астында ачык итеп русча әйтелә: газета, техника.

3) киң әйтелешле [ы] һәм [ā] фонемалары шул ук кагыйдәгә буйсына: сыр, карта.

4) [и] һәм [у] авазлары үзгәрешләргә бирелми: сумка, студент, кино.

5) рус-европа телләреннән татар теленә дифтонглар һәм дифтонгоидлар үтеп керде: оа (коала), ае (аэропорт), аи (мозаика), иу (аквариум) һ.б. Европа телләреннән кергән дифтонглар ике иҗеккә дә бүленергә мөмкин: вариант, миллион.

2. Рус теленең басым үзенчәлекләре нормалашуы. Татар телендә басым, нигездә, соңгы иҗеккә төшә, ә рус телендә ул төрле иҗектә булырга мөмкин. Әлеге үзенчәлек татар теленә дә йогынты ясамый калмаган. Күп кенә алынма нигез сүзләрдә басым үзгәрешсез кала:

1) рус-европа телләрнең кушымчалары ялганган сүзләрдә басым үзгәрешсез кала: взятка; 2) алынма сүзнең ачык иҗегенә төшкән басым татар кушымчасы ялганганда да үз урынында кала: тема – теманы, темага, темалар; 3) ябык иҗектә басым үз урынында калырга яки соңгы иҗеккә күчәргә мөмкин: алынмада басым соңгы иҗектә булса, кушымча ялгагач, ул күчә: педагог – педагоглар, ләкин -ча кушымчасына беркайчан да басым күчми: педагог – педагогларча; 4) бер иҗекле алынмалар күбесе ябык: морж, герб, аларда басым рус телендәгечә саклана (моржлар).

3. Рус теленең тартыклары үтеп керүе һәм нормалашуы. Рус-европа алынмалары аша телебезгә ирен-теш [в], тел очы [ж], тел арты [х], аффрикат [ц], [$^{т}$ч] фонемалары кергән.

1) чемпионат, чек кебек алынма сүзләрдә [ч] тартыгы ачык ишетелә. Кайбер сүзләрдә әлеге аффрикат татар һәм рус телендәге бертөрле сүзләрең мәгънәсен аеру функциясен башкара: чага(рус.)- гөмбә төре – чага (тат.) – фигыль; 2) [ж] [ш] [ц] тартыклары рус телендә калын әйтелә, татар телендә дә әлеге әйтелеш саклана: жираф, цирк; 3) сүз һәм иҗек башындагы [в] авазы фонетик принцип нигезендә в хәрефе белән язылa: вагон, виза.

4. Палаталь тартыклар үтеп керүе. Алынмалардагы палаталь тартыклар нәтиҗәсендә татар телендә арткы рәт сузыклары нечкәртеп әйтелә башлый: ветеран, октябрь. Татар телендә ю хәрефе алдыннан кайбер палаталь тартыклар ачык итеп әйтелә ([з'] [б'] [в'] [л'] [р']).

Телгә үтеп кергән палаталь тартыклар авазлар системасында үз урынын алды, кайбер очракларда алар мәгънә аеру функциясен дә үтиләр. Бу күренеш гадәттә мишәр диалектына хас.

Барлык күзәтүләрдән чыгып, түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкин. Хәзерге татар орфоэпиясенә һәм орфографиясенә чит телләрнең алынмалары зур йогынты ясаган. Бу бигрәк тә телнең фонетик системасында күренә.

Хәзерге көндә орфографик һәм орфоэпик нормаларны бозуның ике төрен атарга була: татар телен начар белүчеләр язуындагы һәм сөйләмендәге хаталар һәм татар телен ярарлык дәрәҗәдә белгән яшьләрнең игътибарсызлык аркасында ясалган хаталар. Алынма сүзләрне төрлечә куллану нәтиҗәсендә дә телдә орфоэпик һәм орфографик вариантлар күбәйде. Сүзлекләрдә бирелгән сүзләр белән хәзерге көндә сөйләмдә йөргән сүзләр арасындагы каршылык һәм аерма көннән-көн зурая бара, бу мәсьәләдә төгәллек кирәклеге турында сөйләшүләр матбугат битләрендә дә һәрдаим урын алып килә.

Әлеге үзгәрешләрне өйрәнү татар теле белемендә мөһим бер мәсьәлә булып тора.


**ӘДӘБИЯТ**

1. Абдуллина Р.С. Алфавитка бәйле орфография һәм орфоэпия мәсьәләләре: Монография. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 284 б.
2. Абдуллина Р.С. Хәзерге татар теленең орфографиясе һәм орфоэпиясе: Югары һәм урта махсус уку йортлары студентлары өчен уку әсбабы. – Казан: Мәгариф, 2009. – 239 б.
3. Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы: (педагогия институтлары һәм колледжлары студентлары өчен кулланма). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 93 б.
4. Галиуллина Г.Р. Татар теле. Лексикология. – Казан: Мәгариф, 2007. – 95 б.
5. Галиуллина Г. Р. Хәзерге татар теле лексикологиясе. – Казан: Казан. ун-т, 2013. – 123 б.



**А.Л. ФАТЫХОВА**

*магистрант*

*Казан федераль университеты*


# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ «БАШ» СОМАТИК КОМПОНЕНТЫ БУЛГАН ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР КУЛЛАНЫЛЫШЫ


**Аннотация.** В данной статье рассматривается использование в современном татарском языке фразеологических единиц с соматическим компонентом «голова». Подчеркивается, что компонент «голова» является достаточно активно используемым соматическим наименованием для пополнения фразеологического фонда татарского языка.



**Ключевые слова:** татарский язык, фразеологизм, фразеологическая единица, голова,

соматик компонент.

**Abstract.** This article discusses the use of phraseological units with the somatic component "head" in the modern Tatar language. It is emphasized that the "head" component is a rather actively used somatic name to replenish the phraseological fund of the Tatar language.

**Keywords:** tatar language, phraseology, phraseological unit, head, somatic component.

Татар телендә *баш* сүзенең өч дистәгә якын мәгънәсе лексикографик рәвештә теркәлгән [2, б. 432-434]. Соматик атама буларак ул «Ми, чәч, йөз, күзләр, авыз, борын (яки танау), колаклар урнашкан кеше яисә хайван әгъзасы» дигәнне белдерә [2, б. 432]. Кул, аяк, җилкә, йөрәк һ.б. соматик атамалар кебек үк, *баш* сүзе дә еш кына фразеологизмнарның мөһим компоненты булып килә, һәм мондый берәмлекләрнең культурологик кыйммәте югары булуын ассызыклау сорала. Халык мәдәниятенең төрле формаларында – ышанулар, фольклор әсәрләре, йолалар, халык медицинасында кеше организмының соматик төзелеше һәм функциясе турындагы күзаллаулары чагылыш таба. Фразеологик берәмлекләрне дә шушы яссылыкта өйрәнү кызыклы нәтиҗәләргә китерә. Әлеге мәкаләдә «баш» соматик атамасы ярдәмендә ясалган берәмлекләрнең хәзерге татар телендә кулланылышы тикшерелә. Нәкъ менә «баш» атамасын соматик атама буларак тикшерү үзен аклый, дип уйлыйбыз, чөнки бу – кешенең иң күп һәм иң җитди вазифалар башкара торган әгъзасы буларак кабул ителә.

Баштан башка кешене күз алдына китереп булмый. Шуңа күрә еш кына баш дигәндә гомумән кеше күзаллана. Мәсәлән:

– *Бетте баш*! Ә нигә куркырга ул кадәре? [4, б. 87].

– Имче карчыкларның сүзенә ышансаң, *башың себер китәр*… дип үзен сүкте [1].

Биредә *бетте баш* фразеологизмы котылгысыз ситуациягә эләгүне белдерә, мондый ситуациядән котылып булмау, бетү баш атамасына нисбәтле әйтелсә дә, тулаем кешенең котылгысыз шартларга юлыгуы аңлашыла. Ә *баш себер китү* фразеологизмы, кешенең Себер якларына сөргенгә сөрелүе, ягъни җинаять өчен җәза алу дигән мәгънәне белдерә.

Метонимия нигезендә ясалган мондый фразеологик берәмлекләр рәтендә шулай ук *башны таш астында асрау* (авыр шартларда яшәп калу), *башын төрмәдә черетү* (озын срокка зинданга утырту), *баш арты килү* (ярышта, бәйгедә икенче булып килү, икенче урын алу), *баш белән уйнау* (кеше гомерен куркыныч астына кую), *башка бәла булу* (кем өчендер мәшәкатьләр тудыру), *бер башың ике булу* (өйләнү) кебекләр дә керә.

«Баш» компонентлы фразеологик берәмлекләр арасында язмыш, фаталистик күзаллаулар белән бәйле булганныры да бар. Мәсәлән:

– Әле ничекияләнеп эшли аласың... Мин булдыра алмас идем.

– *Башыңа төшсә* булдырасың [4, б. 81].

Игътибар итик: фаталистик күзаллау чагылыш тапса да, мондый берәмлекләрдә кешенең үзенә дә ышаныч белән карау ачык сизелеп тора.

Башның төп вазифасы акыл эшчәнлеген тәэмин итү буларак танылa, ягъни бу очракта баш һәм баш мие функцияләре тәңгәлләштерелгән килеш тәкъдим ителә. Хәзерге татар телендә киң кулланыла торган *башына да кереп чыкмый, башы эшләми, башка керми, башка да китермәү* һәм башкалар соматизмның барыннан да элек уйлау, фикерләү вазифасын күздә тотып төзелгәннәр. *Баш буталу* фразеологизмы болар арасында аерым урын алып тора, дип әйтергә кирәк, чөнки гадәттә акыл эшчәнлегенең ниндидер җитди сәбәпләр, стресс, көчле эмоциональ кичерешләр нәтиҗәсендә тиешле дәрәҗәдә эшчәнлек күрсәтә алмавына ишарә итә. Мәсәлән:

– Ике тапкыр Т...га кайтып килдем. Хатта язган идем бит, оныттыңмыни?

– Әйе шул. *Баш буталды* бөтенләй [4, б. 94].

Телебездә акылсыз яки җилбәзәк, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен аңламыйча, уйламыйча эш итә торган кешеләрне характерлаучы фразеологик берәмлекләрдә дә баш компоненты еш кулланыла. Мондый берәмлекләрдә башка зыян салучы, аңа факторлар буларак җил, кырау, башка физик зыян китерүче хайван (тай) образлары да кулланыла ала. Мондый берәмлекләрдә интелеллект үсешенең югары булмавы тотрыклы сыйфат булуы аңлашыла. Мәсәлән:

– Һыһ! Төн уртасында шәһәр буйлап ялгыз йөрергә минем *башыма тай типмәгән* бит әле [1].

– Юләр кыз син, синең *башыңда җил уйный* [3].

Акылсыз кешеләрнең интеллект дәрәҗәсен хайваннар белән чагыштыруга нигезләнгән фразеологизмнар да бар. Ешрак мондый берәмлекләрдә сарык, тавык һәм баш компонентлары янәшә килә. Мәсәлән:

– Күрсәтермен мин сиңа тол этәчеңне, миең черегән нәрсә, *тавык баш* [3].

Акылсыз кешеләр хакында әйтелгән мондый берәмлекләр рәтендә шулай ук *башына кырау тигән, башында салам селкенә, башына чүбек тутырган* фразеологизмнарын атарга була.

Акыллы, интеллекты югары булган кешеләрне тасвирлаганда яисә шушы сыйфатларны күрсәтергә кирәк булганда, *баш эшләтү, баш эшләү, баш*

*шәрифләрен эшләтү* кебек фразеологизмнарга мөрәҗәгать итү очрый. Боларда да баш һәм баш мие вазифалары тәңгәлләштерү сиземләнә. Мисал өчен:

– Болары да *баш шәрифләрен* бик шәпләп *эшләтергә* мәҗбүр иткәндер [3].

Баш соматизмы ярдәмендә ясалган фразеологик берәмлекләрнең кайберләре телебездә мөнәсәбәтләрне, шул исәптән, хөрмәт итүне, ризалашмау, каршылык күрсәтүне белдереп килә. Кайберләренең ясалыш логикасы инде онытылган булса да, алар киң кулланылалар. Мәсәлән:

– Инде бу эксперименттан *баш тарткансыздыр*? [3].

Алдагы очракны карыйк:

– Аларның җиң сызганып руль артына утырулары авыл эшчәннәре хезмәте алдында *баш июләреме*, әллә кайчандыр барлык дөньяга билгеле булган «Ростсельмаш» заводы комбайннарын рекламалау белән бәйлеме? [3].

Биредә борынгыдан калган йола – өстен булган шәхесләрне, ханнарны, патшаларны, олы түрәләрне танып, алар алдында башны түбән ию күренешенең йогынтысы ачык күренә. Бүген җәмгыятьнең барлык әгъзалары тигез дип таныган гуманистик җәмгыять шартларында мондый йола яшәми, әмма, күренгәнчә, фразеологизмнарда ихтирам һәм соклану, тирән хөрмәт билгесе буларак фразеологик берәмлекләрдә аның атамасы саклана.

Баш ию йола-гадәтенә килгәндә, аңа каршы рәвештә *баш күтәрү* күренешен атарга була. Бу очракта кеше, борынгы чорда яшәп килгән кануннар буенча баш иеп, хөрмәт күрсәтергә тиеш булып та башын ими, ә киресенчә күтәрә – үзен шул шәхес (түрә, хан һ.б.) белән тигез дәрәҗәдә булуын шушы гамәл белән күрсәтә. Тора-бара баш күтәрү гыйбарәсе тагын да масштаблырак мәгънәдә дә кулланыла башлый: фразеологик берәмлек аерым кешенең хакими көче үзеннән югарырак булган кеше белән каршылыкка керүен дә, кешеләр төркеме, гомумән, халыкның кешегә, хакимияткә, яшәп килүче строй, гадәтләргә каршы килүен дә белдерә башлый. Хәзерге татар телендә кулланылыш очракларын карыйк:

– Әмма халыкның күбесе *баш күтәрүләр* булмас дип уйлый [3].

Баш соматизмы авыру һәм терелү, шул исәптән эчүчелек авыруы белән бәйле рәвештә ясалган фразеологизмнарда да кулланыла. Шундыйлардан *баш кайнау, баш әйләнү, баш төзәтү* кебекләрне атарга була.

Гомумән, баш компоненты татар теленең фразеологик фондын тулыландыруда актив кулланыла торган соматик атама булып тора. Мондый берәмлекләр хәзерге татар телендә дә актив кулланыла һәм милли-мәдәни яссылыкта тикшерү өчен кыйммәтле ядкарь дип санала ала.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Абдуллин Ф. Юл чатында. – URL: http://maydan.tatar/yul-chatynda-povest/; мөрәҗәгать итү вакыты: 13.09.2023.
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: том: А–В. – Казан: ТӘhСИ, 2015. – 712 б.
3. «Туган тел» милли корпусы. – URL: https://tugantel.tatar/?lang=ru; мөрәҗәгать итү вакыты: 13.09.2023.
4. Хәким З. Сайланма әсәрләр. Гөнаh. Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 399 б.

**Р.Н. ФӘХРТДИНОВА**
*студент,*
*Казан федераль университеты*

# «YAÑA MÄHÄLLÄ HABÄRLÄRE» ЖУРНАЛЫНЫҢ ЛЕКСИКАСЫ: МИШӘР ДИАЛЕКТЫ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЕ АЛЫНМАЛАРЫ

**Аннотация.** «Yaña Mähällä Habärläre» - это журнал татар, которые больше века живут в Финляндии. В этом журнале освещаются новости из их жизни. Журнал привлекает внимание читателей не только темами, но и особенностями языка. Языковые особенности финских татар уникальны. В статьях, представленных в журнале, мы можем увидеть особенности мишарского диалекта, а также заимствования из европейских, и из тюркских языков, в особенности из турецеого языка.

**Ключевые слова:** наследие, язык, традиции, культура, заимствования.

**Abstract.** “Yaña Mähällä Habärläre” is a magazine of Tatars who have lived in Finland for more than a century. This magazine covers news from their lives. The magazine attracts the attention of readers not only with its topics, but also with its language features. The linguistic features of the Finnish Tatars are unique. In the articles presented in the magazine, we can see the features of the Mishar dialect, as well as borrowings from European and Turkic languages, especially from the Turkish language.

**Keywords:** heritage, language, traditions, culture, borrowings.

Финляндия татарларының туган телләре булып татар теленең көнбатыш (мишәр) диалекты санала. Европа, төрки телләренең йогынтысы никадәр зур булса да, милләттәшләребез туган телебезне гасырлар буе саклап килә, яңа буынга өйрәтә. Туган телне саклап калу мәсьәләсе дөньяның һәр почмагында яшәгән татар кешесен борчый. Финляндиядә яшәүче татарлар да яшь буынга туган телнең матурлыгын, байлыгын күрсәтер өчен гаиләдә һәм җәмгыятьтә туган телдә сөйләшә, дин һәм гореф-гадәтләр белән таныштыру өчен төрле милли чаралар, очрашулар уздырып тора. Милләтебез белән таныштыру балалар бакчасыннан ук башлана, ял көннәрендә көз һәм яз, җәй көннәрендә махсус татарча укыту курслары оештырыла. Яшьләр милли оешма эшләрендә катнаша,

төрле хор һәм театр куелышларында, спорт уеннарында уйнап, милләттебез тормышына үзләреннән зур өлеш кертә.

Финляндия татарлары җәмгыяте бай мирасы белән данлыклы. Алар татар халык җырларын, көйләрен саклый, мәдәни чаралар оештыра, татар әдәбиятының классик әсәрләре буенча спектакльләр куя. Фин татарлары элегрәк Татарстаннан төрле китаплар алып кайткан булсалар, бүгенге көндә аларның үзләре язган әсәрләре, үзләре чыгарган газета-журналлары бар. Шуларның берсе «Mähällä Habärläre» журналы.

«Mähällä Habärläre» журналының төп чыганагы – татар теленең үз лексик фонды. Белгәнебезчә, тел бары тик үзенең сүзләреннән генә тора алмый, төрле алынмалар да килеп керә. Әлеге басмада исә гарәп-фарсы алынмаларыннан тыш, төрек теленнән кергән алынмалар да шактый. Мисал өчен:

*Şulay uk 2012 nçe yıl turında* ***omumän*** *iskä töşerep kitäsem kil (Шулай ук 2012 нче ел турында омумән искә төшереп китәсем килә. (M. h.,1/2013); Avır çaklar buldı, yakınnarıbıznı mäñgelekkä ozattı* ***hastälänülär*** *dä buldı (Авыр чаклар булды, якыннарыбызны мәңгелеккә озатты, хасталанулар да булды). (M. h., 1/2013); Üzenä iPad* ***hädiyä*** *itelde (Үзенә iPad хадия ителде). (M. h., 1/2013); Mäglüm ki, «Ak Bars» hokkey* ***takımında*** *öç-dürt fin uynauçısı bar(Мәгълүм ки, «Ак Барс» хоккей такымында өч-дүрт фин уйнаучысы бар). (M. h., 1/2013); Üzebezneñ kiläçäk* ***fäaliyätlär*** *turında uylar tudı (Үзебезнең киләчәк фәалиятләр турында уйлар туды). (M. h., 3/2016);* ***dikkat itärgä*** *kiräk ikän (дикъкать итәргә кирәк икән) (M. h., 1/2013); idarä häyäte östennän böten* ***mäsüliyätne*** *rahmätlär belän töşerde. mesuliyet ((идарә хаяте өстеннән бөтен мәсүлиятне рәхмәтләр белән төшерде). (M. h., 1/2013); Cıyılış bu täklifne bertavıştan kuätläde häm kabul itte (җыелыш бу тәклифне бертавыштан куәтләде һәм кабул итте). (M. h., 1/2013); Finlandiyä möselmannarın* ***tämsil*** *itärgä turı kilde…(Финляндия мөселманнарын тәмсил итәргә туры килде...) (M. h., 1/2013); Bu süzlär belän Rinat äfände* ***mämnünlegen*** *häm rahmätlären belgertte (Бу сүзләр белән Ринат әфәнде мәмнүнлеген һәм рәхмәтләрен белгертте). (M. h., 1/2013); Uyın uzgaç, zur häm keçkenä* ***möhändislärgä tatlılar*** *takdim itelde (Уен узгач, зур һәм кечкеә мөхандисләргә татлылар тәкъдим ителде). (M. h., 1/2013); Foto-räsem häm Bäleş-beleş tügäräkläre* ***täklif itelep fäaliyätkä*** *kertelde (Фото-рәсем һәм Бәлеш-белеш түгәрәкләре тәклиф ителеп фәалияткә кертелде). (M. h., 3/2016);* ...balalar öçen tatar telendä äzerlängän **sızgıfilm** (multifilm) karıybız (...балалар өчен татар телендә әзерләнгән сызгыфильм карыйбыз). *(M. h., 3/2016)*

Төрки телле журналлар һәм газеталар еш кына төрек теле алынмаларыннан файдаланалар. Бу төрек теленең киң таралган телләрнең берсе булуына

бәйле. Әлеге телдән кергән алынмалар төрки телле халыкларның сүз байлыгын арттыра һәм халыкара бәйләнешләрне ныгытырга ярдәм итә.

Басма битләрендә мишәр диалектының үзенчәлекләре дә күренә. Бу гаҗәп күренеш түгел, чөнки Финляндиягә килүчеләр Түбән Новгород өлкәсеннән килүче мишәр сатучылары була. Бүгенге көндә дә аларның сөйләмнәрендә мишәр диалекты үзенчәлекләре сакланып калган. Моны **«Mähällä Habärläre» журналыннан алынган** түбәндәге мисалларда күреп була:

*Kazanda Finlandiyä tatarlarınıñ tarhların vä* ***adätlären*** *kıskaça añlattılar (Казанда Финляндия татарларының тарихларын вә адәтләрен кыскача аңлаталар). (M. h.,1/2013); İkençe öleştä üz saylauları buyınça süz, sigır, cır yäisä biyü* ***ütenelgän*** *ide (Икенче өлештә үз сайлаулары буенча сүз, шигырь, җыр, бию үтенелгән иде). (M. h., 1/2013);* ***Alnıbızda*** *2013 yıl tora (Алныбызда 2013 ел тора) (M. h., 1/2013; Däreslär başkönnän* ***koçatnaköngä*** *kadär alıp barıla (Дәресләр башкөннән кочатнакөнгә кадәр алып барыла) (M. h., 3/2016);* ***Bıyıl*** *bakçada karauçı apalar...(Быел бакчада караучы апалар...) (M. h., 3/2016); Älegä räsemnär kübesençä mömkin kadär iske häm vakıt buyınça 1960 nçılarga* ***hatle*** *saylandı (Әлегә рәсемнәр күбесенчә мөмкин кадәр иске һәм вакыт буенча 1960 нчыларга хатле сайланды) (M. h., 3/2016); İske räsemnäregez bulsa,* ***kaya*** *kuyarga,* ***kaya*** *iltärgä dip uylansagız yäki birep torırga hazer bulsagız... (Иске рәсемнәрегез булса, кая куярга, кая илтәргә дип уйлансагыз яки биреп торырга хәзер булсагыз...) (M. h., 3/2016)*

Күренгәнчә, язмаларда мишәр диалектының фонетик һәм лексик үзенчәлекләре күбрәк урын ала.

**«Mähällä Habärläre»** журналы теле татар әдәби телендә язылса да, сүзләр мәгънә ягыннан туры килмәгән очраклар да бар. Мисал өчен: *«Kongressniñ berençe köne 6 nçı dekaber yazılu köne bulganga katnaşuçılarnıñ* ***azat*** *vakıtı buldı häm alar Kazan şähärenä säyähat kıldılar»*, җөмләсендә ***«azat»*** (азат) сүзе урынына ***buş*** (буш) сүзен куллану мәгънә ягыннан күбрәк туры килә. Шулай ук, *«Ayıruça Finlandiyädä yäşägän töreklär häm tatarlar arasındagı duslıkka* ***igtibar birde»*** җөмләсендә ***«birde» (***бирде) урынына ***«itte»*** (итте) сүзен куллану; «*Älbättä päygambärlek kilgäç tä ul iskitkeç matur* ***misal*** *kürsätte*» җөмләсендә ***misal*** (мисал) урынына ***ürnäk*** (үрнәк) сүзен язу; «Ul **ireşü** yäşenä citkänçe Söyembikägä han vazifasın ütärgä kiräk bulaçak» **ireşü** (ирешү)не «балигълык» сүзенә алыштыру, «Kazan şähärendä bezne Universiada avılına **urınnnaştırdılar**» җөмләсендә **urnaştırdılar** (урнаштырдылар), «*Mähalläbez isemennän räis Atik Ali Rinat äfände Zakirovka* ***uñışlıklar*** *teläde»* ***uñışlıklar*** урынына ***uñışlar (***уңышлар) дигән сүзне куллану дөресрәк була.

Гомумиләштереп әйтсәк, «Yaña Mähallä habärläre» журналының теле уникаль. Фонетик үзенчәлекләренә күз салсак, фин татарларының теле күбрәк төрек теленә охшаш булуы сизелә. Журнал телендә булган алынмалар, бер яктан, телне баета, язманы үзенчәлекле итә, кабатлаулардан, гади әйтелмәләрдән саклыйлар. Икенче яктан, алынмаларның күплеге мәкаләгә аңлашылмаучнлык төсмере дә бирергә мөмкин.

«Yaña Mähallä habärläre»ндә Финляндиядә яшәүче милләттәшләребезнең тормышы һәр яклап яктыртыла. Журналистлар мәкаләләр аша татар мөхитен тудыралар, милләтебезнең мәдәнияте, гореф-гадәтләре турында тулы мәгълүмат бирәләр. Басманың коммуникатив үзенчәлекләре турында шуны әйтеп була: фин татарларының сөйләше, чыннан да, язмада чагыла. Кайсыбер авазлар язылмый, ә кайсылары, киресенчә, өстәлә. Лексикасы төрки-татар сүзлек составына нигезләнсә дә, телдә алынмалар шактый кулланыла.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Беляев Р.Ф. Yaña Mähallä habärläre. – 2012. – № 1. – 24 б.
2. Беляев Р.Ф. Mähallä habärläre – 2014. – № 1. – 28 б.
3. Беляев Р.Ф. Татарская диаспора Финляндии: вопросы интеграции и сохранения идентичности: дис. … докт. филос. наук. – Хельсинки, 2017. – 310 с.
4. Шлыгина Н.В. Традиционные меньшинства Финляндии: формирование и современный статус // Исследования по прикладной и неотложной этнологии. – М.: ИЭАРАН, 2010. Вып. 221. – 43 с.



**М.А. ХАҖИЕВА,**

*магистрант*

*Казан федераль университеты*


# ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УРТА СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНА ИНТОНАЦИЯНЕ ӨЙРӘТҮ


**Аннотация.** Статья посвящена проблеме изучения просодии родного языка на уроках татарского языка, возникающей в результате взаимодействия фонетических систем родного и неродного языков в речи билингва при изучении родного языка, то есть в ситуации искусственного (аудиторного) многоязычия. Статья включает определение таких понятий, как: фонетика, просодия и просодическая интерференция. Рассматриваются и анализируются причины различий между исходным и интерферированным языком в процессе его овладения.



**Ключевые слова:** Фонетическая система, билингвизм, лингвокогнитивный, просодия, вариантология, парадигматика, лингвокультура, методика преподавания татарского языка.



**Abstract.** The article is devoted to the problem of studying the prosody of the native language in Tatar language lessons, which arises as a result of the interaction of the phonetic systems of the native and non-native languages in the speech of a bilingual when studying the native language, that is, in a situation of artificial (classroom) multilingualism. The article includes a

definition of such concepts as: phonetics, interference and prosodic interference. The reasons for the differences between the original and the interfered language in the process of its acquisition are considered and analyzed.

**Keywords:** Phonetic system, bilingualism, linguocognitive, prosody, variantology, paradigmatics, linguoculture, methods of teaching the Tatar language.

Туган тел дәресләрендә урта сыйныфларда просодия үзенчәлекләрен өйрәтү өчен җайлаштырылган һәм системалаштырылган методик нигезлек булдыру бүгенге көндә зур әһәмияткә ия. Бу мәкаләбезнең актуальлеге булып тора.

Мәкаләбезнең макс*аты* – татар просодиясен мәктәптә укыту өчен методик яктан өйрәтү алымнарын тикшерү.

Куелган максатка ирешү юлында без түбәндәге *методларны* кулландык:

1) теоретик метод (лингвистик, психологик һәм дидактик әдәбиятны өйрәнү);

2) лингвистик анализлау методы (язмача һәм яңгырашлы сөйләмне чагыштыру);

3) социаль-педагогик метод (укучыларның психолингвистик үзенчәлекләрен күздә тотып, уку-укыту эшен алып бару нигезләрен барлау).

Мәкаләдә *төп чыганак* итеп татар телен туган тел буларак өйрәнүче 5 нче сыйныф укучылары өчен Р.Р. Шәмсетдинова, Г.К.Һадиева, Г.В. Һадиева авторлыгында басылган «Татар теле» дәреслеген алдык [3, б. 175]. Мәктәп укучысы интонация үзенчәлекләре белән иң беренче чиратта сәнгатьле уку барышында таныша. Алда әйтеп кителгәнчә, дөрес интонациягә ирешү (шул нисбәттән барлык просодик чараларны камил рәвештә чагылдыру) текстның мәгънәсен тулысынча аңлаудан башка мөмкин була алмый. Психологик яктан уку эшчәнлеге язма сөйләмне – текстны – кабул итү һәм – аңлау өлешләреннән торган бердәм үзара бәйләнешле процесс буларак кабул ителә. Кабул итү – телнең материаль чараларын – фонема, иҗекләр, сүзләр, җөмләләр, интонацияне – хистойгылар ярдәмендәге анализлавы һәм синтезлавы. Аңлау – әлеге чараларның мәгънәви берләшмәсе [2, с. 304].

Шуңа күрә дә дәреслектә беренче чиратта күнегүләр әйтү максаты буенча җөмләләрнең төрләрен билгеләүгә юнәлтелгән. Укучылар нинди төр җөмлә (хикәя, сорау, боерык) нинди максаттан әйтелүен аңлаган чакта гына алдан ук текстны укыганда дөрес интонация сайлый алачак. Мәсәлән, 69 нчы биттәге 158 нче күнегү:

*«Түбәндәге текстны тиешле интонация белән укы. Әйтү максаты буенча җөмләләрнең төрләрен билгелә»:*

*Күктә әйтерсең көмеш кыңгыраулар чылтырый. Ничәү соң алар? Бары бер тургай! Әнә зәңгәр күктә тирбәлә. Ә җыры нинди! Шушы кечкенә кош сихри моңы белән ничек күңелне күтәрә икән? Иртә таңнан көне буе бертуктаусыз очарга да, җырларга да күпме көч кирәктер?! (Фоат Садриевтан).*

*71 нче биттәге 161 нче күнегү. Текстны сәнгатьле итеп укы, исемен аңлат. Әйтү максаты буенча җөмлә төрләрен билгелә. Сүзләргә басымны куеп, үзең теләгән абзацны күчереп яз.*

Мондый төр күнегүләрне башкару нәтиҗәсендә укучыларда интонация төрләре, аларның якынча гына булса да мелодикасы, басымы һәм башка аспектлары турында күзаллау формалаша башлый. Укучылар туган телендә җөмләләрне автоматик рәвештә әйтүдән тыш, инде аларның интонацион үзенчәлекләренә дә игътибар бирә башлый һәм җөмләләрне аңлы рәвештә тавыш ярдәмендә формалаштыра: тавышны күтәрә яки төшерә, көчлерәк яки көчсезрәк, сузып яки кыскарак итеп әйтә, ягъни – интонация белән сөйли, укый башлый.

Дөрес интонациягә өйрәткәндә, кычкырып һәм эчтән уку ысулларына игътибар итү зарури. Артикуляцион күнекмәләр кычкырып уку практикасы вакытында иң актив рәвештә үстерелә. Моны күздә тоткан биремнәр уку техникасын камилләштерү йөзеннән гамәлгә кертелгән:

*69 нчы биттәге 159 нчы күнегү: Текстны рольләргә бүленеп, дөрес интонация белән, орфоэпик кагыйдәләрне истә тотып укы. Җөмләләрне укыганда, тавыш хәрәкәтендәге үзгәрешләргә игътибар ит.*

Кычкырып уку, эчтән укуга караганда, туган яки чит телгә өйрәтүдә зуррак әһәмияткә ия булып тора. Психологлар искәрткәнчә, кычкырып уку өйрәнелгән телнең аваз билгеләрен, хәреф белән аваз арасындагы мөнәсәбәт закончалыкларын үзләштерүдә төп роль уйный. Шулай ук сөйләм эшчәнлегенең әлеге төре җөмләнең элементларын синтагмаларга берләштерергә, аларны ритмик һәм интонацион яктан дөрес формалаштырырга ярдәм итә. Гамәлдәге дәреслектә җөмлә элементларына укучыларның игътибарны юнәлтеп, текстларны укырга өйрәтүгә юнәлтелгән күнегүләр урын алган:

*70 нче биттәге 160 нчы күнегү. Хикәя җөмләләрне сорау һәм боерык җөмләләргә үзгәртеп яз. Сүзләрнең басымнарын куеп, дөрес интонация белән укы.*

Мондый төр кычкырып укуга багышланган күнегүләр үрнәк уку темпына җитешергә, аңлау төгәллегенә ирешергә, алдан фаразлау күнекмәсен үстерергә булыша. Шул сәбәпле, эчтән уку төренә керешкәнче, башлангыч баскыч булып торган кычкырып уку ярдәмендә әзерлек булдырырга тиешле. 5 нче сыйныф дәреслегендә нәкъ менә кычкырып укуга юнәлтелгән күнегүләрнең шактый бу-

луы да әлеге факт белән аңлатыла. Әлеге төр күнегүләрдән соң катлаулырак дәрәҗәгә күчәргә мөмкин – фонетик биремнәр эшләү вакытында телнең төрле интонемаларын тыңлау һәм телдән кабатлау баскычына.Уку техникасының психологик нигезлеген текстның кабул ителеше тәшкил итә. Кабул итүнең нигезе исә күрү сәләте ярдәмендә башкарылган образлы фикерләүгә бәйле. Шул ук вакытта тыңлау һәм моторик күнекмәләрен дә игътибарсыз калдырырга ярамый. Уку күнекмәсенең икенче өлешен методик һәм психологик хезмәтләрдә төп урын алган аңлау компоненты тәшкил итә. Сәнгатьлелек белән бергә, ул уку күнекмәсенең коммуникатив юнәлешен тормышка ашыруга ярдәм итә.

Лингвистик ысулларга килгәндә, сәнгатьле уку күнекмәсен үстерү барышында телнең просодик чараларының дөрес кулланылышы төп роль уйный. Татар теле вәкилләре өчен әлеге мәсьәлә, табигый шартларда үткән сөйләм ситуациясенә бәйле рәвештә үсеш алганга күрә, авырлык тудырмаска мөмкин, ләкин аның теоретик нигезлеген күздә тоту зарури.

Шулай итеп, телнең интонация үзенчәлекләре иң беренче чиратта катлаулы психологик процесс булып торган уку эшчәнлеге барышында үзләштерелә. Шуңа күрә укучының уку техникасын (тышкы аспект) һәм аңлау дәрәҗәсен (эчке аспект) үстерүе сорала. Моннан тыш, дөрес интонацияне үзләштерү барышында, аерым авазлар һәм сүзләр артикуляциясе укучыларның төп игътибарларын биләмәскә тиеш. Әлеге фикер сүзләрнең дөрес әйтелеш кагыйдәләре әһәмиятен кире какмый, бәлки орфоэпик нормаларының интонация темасына кадәрге баскычта төгәл үзләштерелү зарурияттен ассызыклый.

## ӘДӘБИЯТ


1. Байчура У.Ш. Татар теленең кайбер фонетик үзенчәлекләре: эксперименталь-фонетик мәгълүматлар буенча // Татар теле һәм әдәбияты мәсьәләләре. – Казан, 1963. – Б. 127-140.

2. Жинкин Н.И. Речь // Психология / Под ред. А.А. Смирнова, А.Н. Леонтьева, С.Л. Рубинштейна, Б.М. Теплова. – М.: Учпедгиз, 1962. – С. 295-333.

3. Шәмсетдинова Р.Р. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 5 нче с-ф / Р.Р. Шәмсетдинова, Г.К.Һадиева, Г.В. Һадиева. – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2015. – 175 б.

**Л. Р. ХӘЙРУЛЛИНА,**
*магистрант*
*Казан федераль университеты*

# ХХ ЙӨЗ УРТАЛАРЫНДА ДӨНЬЯ КҮРГӘН ХЕЗМӘТЛӘРДӘ ЭНДӘШ СҮЗЛӘР

**Аннотация.** В статье дан краткий обзор истории изучения обращений в татарском языкознании. Также обсуждаются некоторые вопросы речевого этикета, характер общения и намерения говорящего в процессе коммуникации.

**Abstract.** The article gives a brief overview of the history of the study of appeals in Tatar linguistics. Some issues of speech etiquette, the nature of communication and the speaker's intentions in the communication process are also discussed.

**Ключевые слова:** обращения, грамматика, синтаксис, речь, история.

**Keywords:** references, grammar, syntax, speech, history.

Татар телендә эндәш сүзләргә күптән игътибар ителә. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның «Татар нәхүе» хезмәтендә алар җөмләнең иярчен кисәге итеп каралган. Галим үз хезмәтендә аларны эндәш исеме белән атый [2, б. 428]. В.Н.Хангилдин эндәш сүзләрне, җөмлә төзелмәсендә катнашып та, җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләреннән читтә кала торган сүзләр һәм сүз тезмәләре дип бирә [4, б. 497]. Галимнең эндәш сүзләргә билгеләмәсе түбәндәгечә:

«Җөмлә төзелмәсендә эндәш сүзнең функциясе җөмләнең эчтәлеге төбәлгән затны белдерүдән гыйбарәт. Шуңа күрә эндәш сүз, башлыча, исем белән, нигездә, кеше исемнәре белән белдерелә. Бу бик аңлашыла, чөнки сөйләм беренче чиратта кешегә юнәлтелә. Төрле предметларның, шулай ук хайван, кошларның һ. б. исемнәр дә эндәш сүз була алалар». Галим шунда берничә мисал да китерә.

В.Н.Хангилдин телдә, күбесенчә сөйләү телендә, кушаматларның да эндәш сүз булып килүләрен түбәндәге мисал белән дәлилләп бирә: *Акрын, кабак баш, күзләрең чыкканмыни!* (Ш. Камал).

Сирәк очракларда эндәш сүзнең кайбер исем алмашлыклары белән бирелүе дә күрсәтелә: Мәсәлән: *Әй, кем, кара әле син, фатир өчен түләдең бугай.* (К.Нәҗми).

Галим эндәш сүзләргә хас түбәндәге сыйфатларны билгели:

Эндәш сүз билгесез килеш формасында бирелә. Бу яктан аның иягә охшашлыгы зур. Ләкин үзенең функциясе һәм грамматик яки интонацион үзлеге буенча, шулай ук хәбәргә бәйләнә алмавы белән эндәш сүз иядән бөтенләй аерыла.

Эндәш сүзнең үзенә генә хас интонациясе-паузасы бар. Аныңча, эндәш сүз янында еш кына ымлыклар да килә. Алар эндәшкә тойгы төсмере кертергә булышлык итәләр:

*Әй кояш! Арттыр нурыңны, җир йөзен тизрәк эрет... (*М.Гафури); *Әй табагать! Күгең аяз була, йолдызларың дөрләп кабына.* ( С.Хәким).

В.Н.Хангилдин эндәшләрләрнең состав өлешенә дә игътибар итеп, аларның аерым сүзләр белән генә дә, сүз тезмәләре рәвешендә дә килә алуын күрсәтә. Соңга очракта эндәш сүзнең үзенә бәйләнгән иярченнәре белән бергә аерымлануы күрәбез:

*... Аңладым мин, и туган җирем, синең*

*Җанга ягымлы икәндер ялкының да дулкының!* (Г.Тукай);

Галим эндәш сүзләрнең җөмләдә үзара тиңдәш булып килүләрен, мондый очракларда да үз функцияләрен үтәү белән чикләнүләрен күрсәтә:

*Гыйлемша агай, Хәтмулла, Нуретдан,* *килегез алгарак* (Г.Х.Садри); *Җаңел уй, йөз кызарткыч төрле хисләр, сезгә мең ләгънәт! Яшә, тугры караш, төпле гакыл, меңнәр яшә, хезмәт!*

Галим әлеге хезмәттә җөмләдә чын мәгънәсе белән эндәшлек функциясен үти торган сүзләрне генә өйрәнелүен, алардан башка җөмлә составында өстән караганда эндәш сүзгә охшап та, дөресендә, чын эндәш сүз ролен үтәми торган сүзләрнең дә күп булуын искәртә. Мәсәлән: «*Үзең уйлап кара, җүләр, актер Саматов чиратта тора, имеш»* (Ш. Камал) дигән җөмләдәге *„җүләр"* сүзе күбрәк тышкы яктан гына эндәш сүзгә охшый, мәгънә ягыннан исә ул монда җөмләнең эчтәлегенә билгеле бер тойгы төсмере генә бирә ди.

Галим түбәндәге җөмлә төзелмәсендә катнашкан *«ләгънәт»* сүзен дә шундый ук функцияне генә үтәвен әйтә: *Белерме икән, ләгънәт, эх, үзем конюх булсам, рәтен белер идем мин,— диде Кәшшаф (*М.Әмир). Галим мондый төр сүзләрне, мәгънәләре ягыннан эндәш сүз булудан бигрәк, кереш сүзгә якын тора дип күрсәтә. Шунлыктан кайбер грамматикачыларның андый элементларны чын эндәш сүзгә мисал итеп китерүләре белән килешми.

В.Н.Хангилдин фикеренчә, андый сүзләр үзләренең функцияләре һәм интонацияләре белән дә чын эндәш сүзгә туры килеп җитмиләр. Шунлыктан мондый сүзләрне ялган эндәш яки эндәш сыман сүз дип атау дөресрәк булыр дип яза.

Г.Алпаров та «Сайланма хезмәтләр» китабында эндәш һәм кереш сүзләргә, кыскача гына тукталып, болай дип яза:

«Җөмлә эчендә ни берәр кушымча яки ярдәмлек белән, ни бер тәртип белән үзеннән соңгы сүзгә бәйләнмичә, аерымрак бер тавыш белән әйтелгән сүзләр дә

булгаларга мөмкин. Боларның башка сүзләргә һичбер төрле бәйләнеше булмаганга күрә җөмлә кисәге булып саналырга хаклары да юк.

Алар бөтенләй чит, аерым сүзләр һәм аларны ташлаганда да җөмләнең тулылыгына һичбер кимчелек килми. Аларны иярчен кисәк дип йөртү дөрес түгел.

Мондый сүзләрне нинди тавыш белән әйтелүләренә карап: 1) эндәш сүзләр, 2) кереш сүзләр дигән ике төргә бүләргә мөмкин.

Эндәшләр – тавышны күтәреп, бер кешегә я бер әйбергә эндәшеп әйтелгән сүзләр. Мәсәлән: *Яз, газиз углым, кара тактаны сыз акбур белән (ГТукай). Ай! Син мине үзеңә ал. Син юкка кайгырма, дускаем. Мин сине, сөеклем, мәңгегә ташламам»* [1, б. 174].

Тел галиме Х.Р. Курбатов стилистикада эндәш сүзләрне модальлек белдерүнең бер чарасы итеп карый. Аныңча, бу сүзләрнең кулланылыш үзенчәлеге төрле  стильдә төрлечә бирелә. Әйтик, сөйләшү стилендә кереш сүзләр, төрле интонацияләргә бәйле рәвештә, иркәләү яки тиргәү сүзләрен дә, кешеләрнең бер-берсенә булган мөнәсәбәтен дә (монысы кушаматлардан аңлашыла), сөйләүченең культура дәрәҗәсен, холык-фигылен дә күрсәтә [3, б. 123].

Галим һәр милләттә эндәш сүзләр  берникадәр  үзенә  башка булуын да түбәндәгечә аңлатып китә:

«Бездә ирләргә карата *абый, энем, ага, туган;* хатын-кызларга карата *апа, сеңелем, туганым, ханым, туташ* мөрәҗәгатьләре җылы, ягымлы яңгырый. *Абый, апа* дип укытучы кешегә мөрәҗәгать итәләр.

*Ага* сүзе өлкән яшьтәге укытучыга, мәсәлән, профессорга карата әйтелә. *Ханым, туташ* сүзләре нәзакәтле сөйләмдә, югарырак культуралы даирәләрдә кулланыла.

Кешене кушамат белән атау, тиргәү сүзләре күбрәк гади сөйләмгә карый. Мәсәлән:  *Мин көтә торам, кара, озаклама, шайтан, - дип шаярган тавыш белән кычкырып калды» (Ш.Камал);*

Галим иркәләү-ярату сүзләренең эндәш сүз вазыйфасында килүен шулай ук сөйләшү стиленә хас бер үзенчәлек итеп күрсәтә: *И-и җан кисәгем, кайттыңмени? (И.Гази); Булдыңмы әле син, аппагым, былбылым (Г.Камал).*

Х.Курбатов дусларча ягымлы стильгә хас үзенчәлекләрне биргәндә дә аларда эндәш сүзләрнең  кулланылышына игътибар итә:

*Сез, апа кайсы яклардан?; Сеңлем, хакыйкать өчен хәтта нәниләр алдында да гафу үтенү оят түгел (Р.Батулла).* Галим фикеренчә, әлеге

мисалларда урын алган эндәш сүзләр эчке җылылык, чын хөрмәт белән сугарылган. Менә әлеге хезмәттән тагын берничә мисал:

*Бәгърем, балам, ни генә эшлим соң? Әнекәем, бирмәгез аңа! (Г.Ибраһимов); Бәхетле авыз икәнсең, малай! (И.Гази).*

Шулай итеп, татар тел белемендә эндәш сүзләргә күптән игътибар ителсә дә, XX йөз урталарында дөнья күргән хезмәтләрдә аларны аңлау һәм чикләрен билгеләү мәсьәләсендә төрлелек хөкем сөрә. Галимнәр эндәш сүзләрнең модальлек белдерү үзенчәлеген аерып күрсәтсәләр дә, аларның җөмлә кисәгe була алуына төрлечә якын килләләр.

## ӘДӘБИЯТ


1. Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр / Г. Алпаров. – Казан: Мәгариф., 2008. – 286 б.
2. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Том 8. Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910-1930) / Г. Ибраһимов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1987 – 428 б.
3. Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы / Х.Р. Курбатов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1971. – 189 б.
4. Хангилдин В.Н. Татар грамматикасы: Морфология, синтаксис / В.Н. Ханигилдин. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1995. – 640 б.



**А.М. ХӘЛИУЛЛИНА**

*тәрбияче*

*Муниципальное автономное дошкольное образовательное учреждение «Центр развития ребенка – Детский сад № 106» Приволжского района г. Казани*


# В. ХАКОВНЫҢ СТИЛИСТИКА ФӘНЕНӘ КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ


**Аннотация.** В данной статьи рассматриваются работы В.Х. Хакова о татарской стилистике. Исследователь считается одним из основоположников татарской стилистики. В своих работах В.Х. Хаков выделяет общественно-публицистический, научно-популярный литературный, официально-канцелярский и эпистолярный стили.



**Ключевые слова:** стилистика, функциональные стили, общественно-публицистический стиль, научно-популярный литературный стиль, официально-канцелярский стиль, эпистолярный стиль.



**Abstract.** This article discusses the works of V.H. Khakov on the Tatar style. The researcher is considered one of the founders of the Tatar style. In his works, V.H. Khakov distinguishes social-journalistic, popular science literary, official-clerical and epistolary styles.



**Keywords:** stylistics, functional styles, social and journalistic style, popular science literary style, official-clerical style, epistolary style.


Телне тарихи яктан өйрәнмичә торып, халыкның чын, дөрес тарихын белеп булмый. Ә тарихын белмәгән милләт үзен саклау, яшәтү, үстерү юлларын

билгели алмый. Телнең барлыкка килүен һәм формалашуын өйрәнү дә шул телдә сөйләшүче халыкның чын тарихын ачуга кайтып кала.

Тел гыйлеме тарихында шундый кешеләр бар, алар тормышның авырлыгына карамастан, белемгә юл ярып баралар, үзләре артыннан да ияртәләр. Шундый шәхесләр берсе Казан университетының профессоры, Россия Гуманитар фәннәре академиясенең академигы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе В.Х. Хаков була.

Галим В.Х. Хаковның татар стилистикасын өйрәнгән, гомумән, татар стилистиксыа тарихына нигез салган галимнәрнең берсе. Бу өлкәдә аның «Тел һәм стиль мәсьәләләре» (1961), «Татар теле стилистикасына кереш» (1963), «Матур әдәбият тел стиле» (1967), «Стилистика һәм сүз сәнгате» (1979), «Татар әдәби теле. Стилистика» (1999) хезмәтләре язылган.

1961 нче елда галимнең «Тел һәм стиль мәсьәләләре» китабы басылып чыга. И. Абдуллин фикеренчә, биредә В. Хаков «функциональ стильләргә һәм кайбер галимнәрнең фикерләренә туктала. В. Хаков бу мәсьәләгә билгеле бер ачыклык кертә. Шуның белән бергә, автор әдәби стиль (әдәби-сәнгать стиле) белән тел стиле аермасын да күрсәтә. Бу бик кирәк, чөнки матур әдәбият теле белән әдәби телне тиңләштерү һәм шуның нәтиҗәсендә күп кенә ялгышлыкларга төшү телчеләр арасында да күренгәли» [1, б. 105].

Китап берничә бүлектән тора. Беренче бүлектә татар әдәби телендә публицистик стильнең беренче яралгылары, үсү һәм формалашу юллары карала. Шул исәптән галим тарафыннан стильләр турындагы төшенчәгә аңлатма бирелә; татар әдәби телендә стильләрнең өйрәнелү дәрәҗәсе карала; публицистик стиль турында гомуми мәгълүмат тәкъдим ителә, аның стиль булып формалашу тарихы күзәтелә.

Икенче бүлек «XX йөз башында татар әдәби телендә иҗтимагый-политик лексика һәм фразеология» дип атала. Бүлектә әлеге лексика тарихи-лингвистик һәм тематик (семантик) яктан карала. В.Х. Хаков телдәге нейтраль, күчерелмә мәгънәле сүзләргә, алынмаларга игътибар итә.

Өченче бүлектә XX йөз башы публицистикасында кайбер синтаксик үзенчәлекләрне (риторик сорау, риторик өндәү, кабатлау, инверсия, антитеза һ.б.) өйрәнелә.

Дүртенче бүлектә XX йөз башы публицистикасында сатираның тел-стиль чаралары (сүз уйнату, икеләтә мәгънә, оксюморон, пародия, ирония һ.б.) карала.

В. Хаков хезмәтенең төп объекты – публицистика, аның теле һәм стиле. Галим аны «иҗтимагый-политик лексика» дип атый һәм публицистик стильне өйрәнү барышында тарихи-лингвистик классификацияне тикшерүгә зур урын

бирә. Билгеле булганча, публицистика җәмгыятьтә гаять зур роль уйный, тормышның иң актуаль мәсьәләләрен яктырта. Әлеге хезмәт теге яки бу стильнең тарихын өйрәнү стильләрнең үсү һәм формалашу юлларын билгеләргә, стильнең тарихи категория буларак үзенчәлекләрен ачарга ярдәм итә. Борынгы елъязмалар, юлъязмалар, нотыклар, указларны стиль, сәнгать-сурәтләү чаралары куллану ягыннан өйрәнеп, автор публицистик стильнең XX йөз башында түгел, бәлки элегрәк, беренче яралгыларының инде XVI йөздә үк булуларын исбат итә.

1963 нче елда галимнең «Татар теле стилистикасына кереш» хезмәте дөнья күрә. Китапта стильләр турында төшенчә, татар телендә стильләрне өйрәнү тарихына игътибар ителә. Галим иҗтимагый-публицистик стильдә сүзләрнең, төрле тәгъбирләрнең, фразеологик берәмлекләрнең кулланылышын, җөмлә төзелешендәге үзенчәлекләрне, стиль алымнарын, сәнгатьчә тасвирлау, сурәтләү чараларын өйрәнә. В.Хаков иҗтимагый-публицистик стильнең формалашу тарихын һәм формалашу шартларына да туктала. Әлеге монографиядә әдәби тел белән стильләр тарихының тыгыз бәйләнеше исбатлана. Автор һәр стильне татар әдәби теленең тарихи үсеше яссылыгында өйрәнә.

Галим пубицистик стильне генә түгел, матур әдәбияте стильне дә өйрәнә. Аның «Матур әдәбият тел стиле» (1967), «Мәктәптә стилистиканы өйрәнү» (1970) хезмәтләрендә матур әдәбият әсәрләре теленең теоретик һәм методик мәсьәләләре, Г.Тукай, М.Җәлил әсәрләренең теле, стиле карала. Әлеге мәсьәләгә ул бүтән хезмәтләрендә дә әйләнеп кайта. Галим фикеренчә, «матур әдәбият, чынбарлыкның көзгесе буларак, җәмгыять тормышының күп якларын үз эченә ала. Анда халыкның үткәне дә, хәзергесе дә ачык гәүдәләнә. Шунлыктан матур әдәбият стиле тел чараларын сайлап алуда, милли әдәби тел нормаларын эшкәртүдә һәм үстерүдә зур урын тота. Кешенең хисләренә тәэсир итү матур әдәбият стилендә телнең сәнгатьчә сурәтләү алымнарының күп кулланылуы белән аңлатыла. Образлылык телдәге күптөрле үзенчәлекләрне һәм сурәтләү алымнарын куллану нәтиҗәсендә туа. Тел чаралары аша сурәт барлыкка китерү катлаулы мәсьәләләрнең берсе ул. Матур әдәбият әсәрләрендә барлык сүзләр дә сурәтле була алмый. Әмма аларның һәрберсе, сөйләмдә башка сүзләр белән бергә кушылып, образлылык тудыруга ярдәм итә. Кайбер әсәрләрдә кешегә эстетик тәэсир итү, аңарда тирән эчке тойгылар уяту гаять югары була. Бер төркем әсәрләрдә исә публицистик сөйләм үзенчәлекләре шактый урын ала. Әлбәттә, боларның тегесе дә, монысы да яшәргә хаклы. Бу аерымлыклар жанр төрлелеге һәм язучының үзенә хас язу алымнары белән эш итүгә бәйләнгән» [5, б. 219-220].

Шул ук хезмәттә автор «Кайбер тел белгечләре матур әдәбият әсәрләрендәге тел үзенчәлекләрен дә функциональ стильләр рәтендә карый, әмма матур әдәбият әсрләренең телен башка стильләр белән бер рәткә куеп булмый. Ул функциональ сөйләм стильләренә караганда, бик киң һәм үзендә телдәге барлык стильләрнең дә үзенчәлекләрен чагылдыра», – дип аңлата [5, б. 219-220].

1999 нчы елда басылып чыккан «Татар әдәби теле (стилистика)» хезмәтендә стилистика төшенчәсенә түбәндәге билгеләмәне бирә: «стилистика – сүзләрнең мәгънә үзгәрешләре һәм сөйләм төзелеше белән бәйләнешле фән. Ул тел чараларының һәм сәнгатьчә сурәтләү алымнарының бер максатка ярашлы рәвештә кулланылу һәм алардан нәтиҗәле итеп файдалана белү юлларын өйрәнә. Тел фәненең бу тармагы телдәге стильләрне, аларга хас үзенчәлекләрне, сөйләмнең сәнгатьчә чараларын, сүзлек хәзинәсендәге мәгънә үзгәрешләрен, фонетик, морфологик һәм синтаксис категорияләргә караган стиль күренешләрен үз эченә ала. Теге яки бу стильгә карап, сүзләрнең, әйтелмәләрнең, грамматик формаларның мәгънә үзгәлешләре барлыкка килә. Мондый үзгәрешләрнең стилистик категорияләр һәм телнең тарихи үсеше, андагы күренешләрнең эволюциясе белән турыдан-туры бәйле» [5, б. 7].

Хезмәттә В. Хаков грамматик лексика кысаларында бары тик морфологиягә генә караган күренешләрне өйрәнә. Ул морфологик чараларның стилистик үзенчәлекләре кысаларында төрле сүз төркемнәренең (исем, сыйфат, сан) мөмкинлекләрен тикшерә. Аның фикеренчә, «морфологиягә кагылышлы күптөрле стиль үзенчәлекләре сүз төркемнәрендәге категорияләр һәм аларның ясалышы белән бәйләнгән» [5, б. 175]. Әлеге категорияләргә автор килеш, тартымлы исемнәрне, сыйфат һәм сыйфатланмыш бәйләнеше, сыйфат дәрәҗәләре кебек категорияләрне кертә.

Әлеге хезмәттә галим татар әдәби телендә түбәндәге тел (функциональ) стильләрен аерылып чыга:

- иҗтимагый-публицистик тел стиле;
- фәнни-популяр әдәби тел стиле;
- эш кәгазьләре (рәсми-канцелярия) стиле;
- хатлар (эпистоляр) стиль.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: В.В. Хаков татар теле стилистикасы өлкәсендә аеруча зур хезмәтләр язган. Ул функциональ стильләрне тел стильләре дип саный, аларны төрле яктан тикшерә. Галимнең хезмәтләре бүген дә актуальлеген югалтмаган.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Абдуллин И. Файдалы хезмәт // Казан утлары. – 1962. – №5. – Б.105.
2. Хаков В.Х. Матур әдәбият тел стиле. – Казан, 1967. – 53 б.
3. Хаков В.С. Тел һәм стиль мәсьәләләре. – Казан: Каз. ун-ты нәшр., 1961. – 160 б.
4. Хаков В.Х. Татар теле стилистикасына кереш. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1963. – 168 б.
5. Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика) / В.Х. Хаков; фәнни редакторы Х.Р. Курбатов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1999. – 304 б.

**Э.И. ХӘМИДУЛЛИНА,**

*магистрант*

*«Адымнар – Казан» күптелле мәктәбенең туган тел һәм әдәбият укытучысы*

*Казан федераль университеты*

# ПЕДАГОГИКАНЫҢ ЗАМАНЧА АЛЫМНАРЫ: ӘДӘБИЯТ ӨЛКӘСЕНДӘ ПОЭТИК ӘСӘРЛӘРНЕ ӨЙРӘНҮ

**Аннотация:** В статье описывается новые педагогические подходы анализа лирических произведений для школьников. Лирика отличается от других жанров литературы и считается достаточно сложной для школьников. Методы, использованные в методике, вместе педагогическими приемами, открыли художественную природу лирики, предложили новые методы анализа. Методика преподавания литературы в школе предполагает, что в лирике реальность воспроизводится в форме жизни, непосредственных переживаний. Для осознанного и полного восприятия поэзии необходимо обладание некоторыми теоретико-литературными знаниями. Теоретический материал представлен в усложнении и в системе.

**Ключевые слова:** лирика, педагогика, поэзия, анализ, лирический герой, субъективная реальность

**Abstract.** The article describes new pedagogical approaches to the analysis of lyrical works for schoolchildren. Lyrics differ from other genres of literature and are considered quite difficult for schoolchildren. The methods used in the methodology, together with pedagogical techniques, revealed the artistic nature of the lyrics, offered new methods of analysis. The methodology of teaching literature at school assumes that in the lyrics reality is reproduced in the form of life, direct experiences. For a conscious and complete perception of poetry, it is necessary to have some theoretical and literary knowledge. The theoretical material is presented in the complication and in the system.

**Keywords:** lyrics, pedagogy, poetry, analysis, lyrical hero, subjective reality

Лирика эпос һәм драмадан үзенең сәнгати табигате һәм укучыга эмоциональ тәэсир итү характеры белән аерылып тора. Ул укучы белән кешелек кыйммәтләренең нигезләре яки аны җимерүче, юк итүче турында ачыктан-ачык сөйләшә. Мәктәптә әдәбиятны укыту методикасы лирикада чынбарлык тормыш, турыдан-туры кичерешләр формасында кабатлана дип искәртә. Кеше кичерешләре – лирик шигърият объекты (предметы), һәм һәр шигырьдә ул ав-

тор тарафыннан белдерелеп кенә калмыйча, безнең күз алдында барлыкка килә кебек, шул рәвешле сәнгать образы – кичерешкә әверелә. Шигырьнең иң мөһим үзенчәлеге – ритм. Шигырьдә сүзнең ритмиклыгы, күп мәгънәлелеге, аерым шигъри интонация лирикада форма элементлары гына түгел, ә аның тулы эчтәлеген булдыра. Алар барысы да үзара тәэсир итәләр. Шуның нәтиҗәсендә шигырьнең образлы структурасына үтеп кермичә, аның мәгънәсен тулысынча аңлап булмый.

Әдәбиятның һәр төренә хас булган форманың эчтәлеге, кичереш һәм сөйләм бердәмлеге лирикада аеруча ачык күренә. Шуңа күрә аны мәктәптә анализлау бик авыр. Укучылар, иң элек, шигъриятне тыңларга, аның турында фикер йөртергә өйрәнәләр. Шул ук вакытта кешегә авторның шигъри дөньясы ачылсын өчен, аның турында фикер йөрткәнче, авторның шигырьләрен тирәнтен укырга кирәк. Әмма автор һәм укучы хисләренең һәрвакытта да туры килә дигән сүз булыр мөмкин түгел. Чөнки һәркемнең шигъриятне, һәм гомумән сүз сәнгатен, кабул итү үзенчәлеге аның психологиясенә, дөньяны танып-белү дәрәҗәсенә, шәхси тәҗрибәсенә әйләнеп кайта. Һәм гомумән, беркайчан да бер кеше шигърият ачкан эмоциональ халәтләрнең күптөрлелеген узе аша үткәрә, кичерә алмый. Тик укучы лирик әсәрләрдә үзе өчен яңа ачыла торган таныш булмаган психик халәтләргә ышаныч белән карарга күнексә, шигърият башта аның эмоциональ шәхси тәҗрибәсен киңәйтәчәк, ә аннары югары эстетик хисләр дөньясына җәлеп итәчәк. Болар барысы да әхлакый идеаллар булдыруга, рухи яктан үсешенә ярдәм итәчәк. Укучыларга кызгану, шигырьләр укыганда эстетик яктан ләззәтләнү ихтыяҗын ничек тәрбияләргә? Бу сорау әдәбият өлкәсендә лириканы укытканда һәр укытучыда туган төп сорау. Әлбәттә, бу әкренләп ирешелә. Укытучыдан сабырлык һәм рухи такт таләп ителә, Мәктәп укучыларының лириканы өйрәнүне реаль тормышта чагылыш тапкан шигъри активлык, иҗадилык, актив танып белү процессы аша күрсәтү беренче урынга чыгарыла.

Шигъриятне аңлы һәм тулы мәгънәдә кабул итү өчен, кайбер теоретик-әдәби белемнәргә ия булу кирәк. Алар өч төп бүлекне үз эченә алырга тиеш: 1) шигъри сөйләм образлылыгы (һәм гомумән шигъри тел), 2) шигъри синтаксис һәм 3) шигырьләр төзү (шигырьнең ритмик үзенчәлекләре).

Бу белемнәрне үзләштерү һәрвакыт ике юл буенча бара кебек, лирик әсәрләрне укыганда шигъри сөйләмнең образлы мөмкинлекләренә һәм аның интонацион-ритмик аңлаешлылыгына игътибар бирелә. Параллель рәвештә һәр сыйныфта укучыларның аерым күзәтүләре системалаштырыла, аннары шигырь белән бәйле теге яки бу сораулар буенча төшенчәләр гомумиләштерелә һәм

формалаштырыла. Гомумән, теоретик-әдәби белемнәр һәм шигърият турында төшенчәләр системасы 10 сыйныфта, мәктәп әдәбиятын укыту ахырына формалаша һәм билгеле бер төгәллек ала. Лирик герой, шигырь төзелеше системасы һ.б. кебек катлаулы төшенчәләрне артык иртә кертү, укучылар үз җавапларында алар белән эшли белсәләр дә, файда китерми һәм чын мәгънәсендә үзләштерелми. Шигырь турында теоретик белемнәрне үзләштерүне мондый эзлеклелектәге элементар төшенчәләрдән башларга кирәк:

– 5-7 сыйныфлар шигъри сүзнең күп мәгънәлелеге, чагыштыру, шигъриятттә гәүдәләнеш;

– 7-8 сыйныфлар шигъри сөйләм образлылыгы, эпитет, метафора; шигырьнең ике иҗекле үлчәмнәре;

– 9 класс стильнең чагылышы буларак шигъри образлылык, лирикада романтик һәм реалистик стиль турында күзаллау;

– Өлкән сыйныфларда исә шигъри синтаксис, шигъри интонация, шигырьнең өч иҗекле үлчәмнәре; шигырьнең ритмик структурасы, татар шигъриятендә шигырь төзелеше системасы; лирикада автор аңын белдерү формалары (автор образы, лирик герой һ.б.).

Шулай итеп, теоретик материал әкренләп катлаулану һәм системада бирелә. Гадәттә, башта төшенчә эш төшенчәсе буларак, термин буларак кертелә. Аннары ул әкренләп баетыла. Чөнки шигъри сөйләмнең яки шигырь структурасының теләсә нинди элементлары (метафора зурлыгы ритм, шигъри синтаксис элементы буларак кабатлау һ.б.) төрле шагыйрьләрдә индивидуаль. Мәктәп укучыларында конкрет тәэсирләр һәм күзәтүләр күбрәк булган саен, алар өчен инде үзләштерелгән төшенчә тагын да зуррак була. Шуңа күрә, мәсәлән, 5 сыйныфта үзләштерелгән «сынландыру» термины мәктәпне тәмамлаучы тарафыннан тирәнрәк аңланачак. Теоретик белемнәр шигърият турында төшенчәләр бер тапкыр һәм мәңгегә үзләштерелергә мөмкин түгел; алар динамик, аларны яңа әсәрләр белән очрашканда конкретлаштыру укучылардан өстәмә күзәтүләрне, тирәнтен аңлауны, яңа иҗади үзләштерүне таләп итә. Әдәбият укытучысының бурычлары булып шигъри фикер хәрәкәтен күрсәтү, хисләр агымын ачыклау, кәеф үзгәрү сәбәпләрен табу, шигырьләрнең үзәк һәм төп образларын, авторның ассоциацияләр чылбырын ачыклау тора. Кыскача әйткәндә, шигырьне бербөтен динамик система, үзара бәйле итеп күрсәтү. Шуңа өстәп шигырьнең ябык система түгеллеген аңлатырга кирәк, ул авторның бөтен иҗаты, аның дөньяны тоюы, әдәби процесс үсеше белән бәйле булуын да искәртү мөһим.

Лирик әсәр белән танышуның укытучының шигырьне яттан укуы белән башлануы отышлы. Бу уку вакытында бернинди шәрех-комментарийлар ясалмый. Икенче тапкыр уку вакытында бу эшне йөгерек укый торган нәфис сүз осталыгы булган укучыга тапшырырга була, шулай ук аудиоязмадагы укуны тыңлау да максатчан булып тора. Методист-галимнәр кисәтә: шигырьне укучыны бүлдереп, икенче укучыдан дәвам иттерү, сәнгатьле уку күнекмәләре формалашмаган укучылардан укыту кебек эшләр бары тик шигырьгә анализ ясалганнан соң гына тәкъдим ителә ала. Д.Ф. Заһидуллина хезмәтендә шуны-сына игътибар итүнең әһәмияте дә әйтеп кителә: «мәктәп анализында лирик әсәрнең нигезендә яткан кичерешләрнең һәрвакыт лирик геройныкы булуына басым ясала: лирик герой – шагыйрь тудырган, үзенчәлекле хисләргә ия образ. Ләкин ул шагыйрь образына тәңгәл түгел. Бары тик шулай аңлатканда, шушы юнәлешне саклаганда гына лирик әсәрләрне сәнгать төре буларак өйрәтергә мөмкин» [1, б. 105].

Укучылар аңлавы өчен, лирик геройның автордан аерым образ булуы еш кына катлаулы була. А.Б. Есин язганча, «лирик герой еш кына кичереш характерлары, шәхси сыйфатлары ягыннан авторга якын тора, әмма алар арасында аерма принципиаль һәм һәрвакытта да саклана, чөнки һәр аерым әсәрдә шагыйрьнең лирик героенда үз шәхесенең аерым сыйфатларын лирик герой һәм автор арасындагы якынлык бик аз, өлешчә генә яки бөтенләй дә күзәтелмәскә мөмкин» [2, с. 143].

Лирик әсәрләрне өйрәнүдә дәреслектәге сораулар белән эшләү әһәмияткә ия. Алар төрле якны – шигырьдәге хис-кичерешне дә, аның сәбәбен дә, мәгънә ягын да, әдәби эшләнеш үзенчәлекләрен дә, композицион детальләрне дә, тел-сурәтләү чараларының текстагы роленә дә ачыклык кертергә тиеш.

Лирик әсәрне өйрәнүнең йомгаклау баскычында шигырьне шагыйрь иҗатының бер берәмлеге итеп карау эше башкарыла, Д.Ф. Заһидуллина язганча, йомгаклау, нигездә, шигырьдән гомумиләштерү ясау төсен ала. Дәрестәге күзәтүләр бергә тупланып, нәтиҗәләр чыгарыла. Шигырьнең үзенчәлекле яклары билгеләнә, аңа бәя бирелә. Югары сыйныфларда шигырьне язучы иҗатында бер тәлгәш булуы, шул иҗат хакында да сүз алып барыла.

К.В. Миронова, лирик әсәрләрне аңлау һәм анализлау дәвамында өч этапны аерып күрсәтә: синкретик; аналитик; синтетик.

Болардан синкретик этапта шигырьне уку / тыңлау вакытында хасил булган хис-кичерешләр тасвирламасы белән эш алып барыла. Аналитик этапта әсәрне анализлау түбәндәге тәртиптә оештырыла:

1) «лирик сюжетны тасвирлау. Ул түбәндәгеләрне эченә ала: а) эксплицит эчтәлекнең (сүз белән турыдан-туры тасвирланган эчтәлек) ачкыч элементларын барлау; б) лирик геройның кичерешләрен ачыклау.

2) композицияне тасвирлау;

3) образлы телне тасвирлау. Ул үз чиратында түбәндәге эшләрне башкаруны күзаллый: а) шигъри контекстта сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау; б) сәнгатьчә сурәтләү чараларын барлау һәм аларның шигырьдәге рольне ачыклау» [3]. Синтетик этапта укучылар шигырьнең интерпретациясен башкаралар, үз позицияләрен нигезлиләр.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: мәктәптә әдәбият дәресләрендә башкарыла торган иң катлаулы эшләр рәтендә лирик әсәрләрне анализлауны атыйлар. Лирика эпос белән драмага каршы куела, ул объектив түгел, ә субъектив чынбарлыкны тасвирлый. Шуңа мәктәптә лирик герой образы, аның кичерешләренә аңлау-аңлатуга игътибар бирелергә тиеш. Лирик әсәрләрне өйрәнү берничә этаптан тора. Әсәр белән танышу алдыннан оештырыла торга нкереш баскычта биографик мәгълүмат карала, музыка һ.б. ярдәмендә махсус эмоциональ атмосфера тудырыла. Дәрес шигырьне уку, андагы хисләрне анализлау белән дәвам иттерелә, йомгаклау баскычында шигырь – шагыйрь иҗатының бер өлеше буларак гомумиләштереп тикшерелә.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н. Әдәбият дәресләрендә шәхескә бәйле универсаль уку гамәлләрен формалаштыру // Фәнни Татарстан. – 2019. – № 4. – Б. 101 – 108 б.
2. Есин А.Б. Принципы и приемы анализа литературного произведения. – М.: Флинта: Наука, 2011. – 248 б.
3. Миронова К.В. Психодидактические основы становления у подростков способности к пониманию лирической поэзии // Перспективы науки и образования. – URL: https://cyberleninka.ru/article/n/psihodidakticheskie-osnovy-stanovleniya-u-podrostkov-sposobnosti-k-ponimaniyu-liricheskoy-poezii/viewer” (мөрәҗәгать итү вакыты: 7.09.2023)

**А.Ф. ХАММАТОВА**

*магистрант*

*Казан (Идел буе) федераль университеты*

## ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ӘМИРХАН ЕНИКИ ИҖАТ ЛАБОРАТОРИЯСЕН ӨЙРӘНҮ ДӘРЕСЛӘРЕН ОЕШТЫРУ

**Аннотация.** В данной статье рассмотрены проблемы изучения творческой лаборатории на уроках татарской литературы в школе. Данная методологическая тема изучается на

примере творческой лаборатории классика татарской литературы – Амирхана Еники. В эпоху глобализации все большую значимость приобретают цифровые и инновационные технологии, с помощью которых можно организовать изучение творческой лаборатории писателя, тем самым усовершенствовав современный урок татарской литературы и повысить его эффективность.

**Ключевые слова:** Амирхан Еники, творческая лаборатория, татарская литература, методика преподавания татарской литературы, инновациионные технологии, цифровые технологии.

**Abstract.** This article discusses the problems of studying a creative laboratory in Tatar literature lessons at school. This methodological topic is studied using the example of the creative laboratory of the classic of Tatar literature - Amirkhan Eniki. In the era of globalization, digital and innovative technologies are becoming increasingly important, with the help of which it is possible to organize the study of a writer's creative laboratory, thereby improving the modern lesson of Tatar literature and increasing its effectiveness.

**Keywords:** Amirkhan Eniki, creative laboratory, Tatar literature, methods of teaching Tatar literature, innovative technologies, digital technologies.

Биографиянең төп функциясе – укучыларның теманы өйрәнүнең барлык дәресләрендә язучының шәхесе белән таныштыру. Төп игътибар иҗатчы шәхесенең ничек формалашуына, кулъязмаларны ничек һәм ни өчен кабат-кабат язганлыгын, нинди зур белем, түземлек, ышану, әхлакый һәм физик көченең киеренкелегенә ия булганлыгын, сәнгать әсәрендә аның шәхси эчке дөньясы, карашлары ачылганлыгын тануга юнәлтелергә тиеш. Мәктәп балаларын өйрәнелә торган әсәрнең эчтәлеге турында гына түгел, ә аның авторы турында да уйларга өйрәтү мөһим: ни өчен ул кеше буларак кызык? Укучыларын нәрсәгә өйрәтә ала? Аның әсәрләре кешеләрдә нинди хисләр уята? Урта сыйныф укучылары уйларының хәрәкәте гел әсәрдән авторга, аннан әсәргә юнәлтелергә тиеш.

Биографияне өйрәнгәндә концентрация принцибын куллану укыту процессында системалылыкны һәм өзлексезлекне тәэмин итә, һәм мәктәп укучыларының әдәби үсешенә уңай йогынты ясый. Концентризм принцибын куллану укучыларга авторның чынбарлыкка булган бәясен билгеләргә, язучының дөньяга карашын, әсәрнең эмоциональ һәм уйдырма катламнарын, аның социаль мотивларын һәм иҗат психологиясен аңларга ярдәм итә [1, с. 212-213].

Язучының биографиясен һәм әсәрен өйрәнүдә дәресләр системасын төзегән чактадәвамчанлык прицибын куллану кирәк. Бу принципны куллану укучыларга белемнәрен гомумиләштерү өчен кирәкле материал тупларга, башкарылган эшкә иҗади караш үстерергә ярдәм итә, текстка бәйсез күзәтү һәм кайбер темаларга һәм биремнәргә күзәтүләрне синтезлаумөмкинлеге бирә.

Биографиянең тәрбияви йогынтысы аның эмоциональ презентациясе ярдәмендә көчәйтелә, бу – язучы шәхесен аның иҗаты белән бердәмлектә кабул итәргә ярдәм итә. Язучы шәхесенең рухи төзелешен, характеристикаларын һәм төрле тормыш ситуацияләрендә чагылыш тапкан материалларның аның язучы булу процессында катнашуы, эмпирик яктан расланган чорны аңларга мөмкинлек бирүче фактлар, язучының иҗади индивидуальлегенең оригинальлеге – өйрәнелгән әсәрнең сәнгать үзенчәлекләрен тирәнтен аңларга ярдәм итәчәк.

Аерым бер татар язучыларының биографиясен өйрәткән чакта аларны башка милләт иҗатчыларының биографиясе белән янәшә куеп, чагыштырып яки аларның дустанә мөнәсәбәтләреннән чыгып, бу дуслыкның аерым бер язучы иҗатына ни рәвешле йогынты ясавы өчен өйрәнү файдалы. Рус, башкорт, казах һ.б. милләт язучылары белән татар язучыларының шәхси һәм иҗади элемтәләрен, әдәби мөнәсәбәтләрне өйрәнү нәтиҗәсендә, укучылар әдәби процессның гомуми үрнәкләрен, бу милләт язучылары арасындагы үзара бәйләнешнең килеп чыгышын аңлыячак, әдәби әсәрне тирәнрәк һәм аңлы рәвештә үзләштерәчәк дип исәплибез. Мәсәлән. Ә. Еники иҗат лабораториясен өйрәткән чакта язучыга “Әйтелмәгән васыять” әсәренең сюжетын башкорт шагыйре Баязит Бикбай сөйләгәнлеге хакында әйтеп китү кирәк. Моннан тыш, укытучы гомумән, тумышы белән Башкортостаннан булган язучыга якташларының, туган ягының йогынтысы турында җирле тел белеме алымын кулланып, Ә.Еникинең аерым бер әсәрләрен өйрәтергә мөмкин. Мәсәлән, «Җиз кыңгырау», «Курай» әсәрләрендә язучының башкорт йолалары белән катнаш җирле татар халкының милли мәдәнияте сурәтләнә: беренчесендә – туй йоласы, икенчесендә – татар-башкорт музыкаль инструментының уникальлеге.

Бу урында язучының киләсе хикәясе – «Курай» әсәре турында әйтеп китү кирәк. Хикәяне язарга шулай ук язучының Башкортостанда туып-үсүе нык йогынты ясагандыр дип фаразлыйбыз. Әсәр легендадан башланып китә. Авторга әлеге легенданы икенче башкорт язучысы Сәгыйть Агиш сөйләгән була. Әлеге легенданың әсәргә кертелеше очраклы гына түгел, чөнки аның үз әһәмиятле функциясе бар: беренчедән, ул хикәягә пролог буларак кабул ителсә, икенчедән әлеге курай дип аталган серле вә сихри музыкаль коралның барлыкка килүе турында халыкта яшәп килгән авыз иҗаты үрнәге дә булып тора. Курай кайдан һәм кайчан, кем тарафыннан ясалганы билгесез, әлбәттә, әмма халык аны әнә ничек итеп үзенчә юраган. Гомумән, Ә.Еники әсәрләрендә музыка образы язучының әсәрләрендә әдәби сурәтлелекне ныграк ачу функциясен үти, хәтта төп сюжетны бәйләп торучы, үзәк образ дәрәҗәсенә күтәрелә («Курай»да – ку-

рай үзе, «Кем җырлады?»да – Таһирәнең җыры, «Матурлык»та – Бәдретдиннең скрипкәсе, монда шулай ук «Җиз кыңгырау» хикәясендәге кыңгырау чыңын да кертеп карарга мөмкиндер).

Әдәби әсәрне өйрәнгәндә, укучыларны язучыларның иҗат лабораториясе белән таныштыру кирәкле эш, әмма бу үз максаты булырга тиеш түгел. Хәзерге мәктәпнең иң мөһим бурычы – укучыларны фән нигезләре белән тәэмин итү генә түгел, ә аларны үз эшчәнлеген оештыра алырга әзер булган үзаллы шәхесләр тәрбияләү. Бөек татар язучыларының тормышы һәм иҗаты мәктәп укучылары арасында эшне хөрмәт итү һәм эшчәнлек оештырырга өйрәтү өчен зур потенциалга ия. Күренекле сүз осталары ничек эшләгәннәр, язу процессында нинди шикләр һәм газаплар кичергәннәр? Язучының биографиясен һәм иҗади юлын өйрәнгәндә, укучылар әсәр иҗат итүгә күпме көч салынганы турында бик сирәк уйлыйлар. Нәтиҗәдә, классик әсәр, аны язган шәхес билгесез кала, һәм әсәр үзе тулысынча аңлашылмый [2, с. 18].

Сәнгать әсәрен өйрәнү башында, укучыларны язучының иҗат лабораториясе белән таныштыру өчен бүлеп бирелергә тиешле урын һәм вакыт билгеләнә, моны ничек эшләргә, аларны психология белән ничек кызыксындырырга икәнлеге уйланыла, иҗади процессны комплекслы өйрәнү аларда күзәтүләргә һәм мөстәкыйль тикшеренүләргә теләк уятырга мөмкин.

Укытучыга семинар дәресләрне кызыклы һәм эффектив итеп үткәрүдә стандарт булмаган уку формаларын куллану булышырга мөмкин:

– Сәяхәт дәресләр. Мондый дәресләр бөек язучы яшәгән һәм иҗат иткән чорга «сәяхәт кылырга» мөмкинлек бирә. Моның өчен язучыны эшләргә дәртләндергән, ул яшәгән, яраткан урыннарына, музеена барырга мөмкин.

– Рольле уеннар – теге яки бу язучының иҗат лабораториясенә бәйле уен технологиясен кулланып, оештырылган дәрес.

– Әкият дәрес.

– Дәрес-спектакль – язучы тормышыннан бер эпизодны сәхнәләштерү.

– Зирәклек дәресе, ачылыш дәресе.

– Дәрес – «телемост».

– Интервью.

Әдәби белемнең төрле дәрәҗәләрендә язучының иҗат лабораториясен өйрәнү проблемасына уңай чишелеш – укытуда *концентризм принцибын* кулланып ирешелә, димәк, урта сыйныфларда өйрәнелгән материалның бер өлеше өлкән сыйныфларда кабатлана, ләкин төрле тирәнлектә тәкъдим ителә: «Концентрик белем бирүнең башлангыч этабы предметларны һәм күренешләрне сизү, мәгълүмат һәм фактлар туплау белән аерылып тора. Киләсе этапларда ул

көннән-көн системалаша һәм урта белемнең югары этабында ул җитди теоретик гомумиләштерү характерына ия».

Материалның концентрик төзелеше аның киләсе этапта катлаулы формада кабатлануын аңлата. Практика шуны күрсәтә: укыту материалы күләмен укучылар аңлый алмаганда, кирәкле тулылык белән ачып булмый торган очракларда мондый принципны куллану кирәк һәм бу очракларда ул үз-үзен. Шул ук вакытта, әдәбиятның теләсә нинди бүлеген өйрәтүдә катлаулы материал әкренләп, укучыларның психик үсеш дәрәҗәсенә туры китерелеп арттырыла. Киләсе классларда мәктәп укучыларының игътибары элек билгеле булмаган биографик фактларга һәм язучының шәхес сыйфатларына юнәлтелә. Элегерәк өйрәнелгән материал яңа белемнәрне үзләштерүдә таяныч була. Әдәби белемнең алдагы этапларында билгеле мәгълүматлар укучылар тарафыннан яңадан бәяләнә һәм югары дәрәҗәдә карала.

Шулай итеп, язучының иҗат лабораториясенә караган яңа материалның класстан-класска туплануы алдагы классларда шул ук фактларга кабат-кабат кайту аркасында язучы белән кабат танышу хисен йомшарта.

Югарыда әйтелгәннәргә нигезләнеп, укытучы язучының иҗат лабораториясен өйрәнү максатыннан оештырган эш мәктәп укучыларын мөстәкыйль нәтиҗәләргә китерә, сәнгать әсәрендә автор, аның шәхесе белән бәйле булган вакыйгаларны һәм персонажларны таныргa өйрәтә. Монографик теманы мондый өйрәнү укучыларның теоретик һәм әдәби белемнәрен баетачак, сәнгать иҗатының үзенчәлекләрен аңлауны тирәнәйтәчәк, эмоцияләрен активлаштырачак. Биографияне иҗат белән берлектә өйрәнү урта мәктәп укучыларына тормыш тәҗрибәсен, язучының нәрсә күргәнен һәм кичергәнен, ул катнашкан вакыйгаларны, кешеләр, аларның язмышлары, психологиясе, тәртибе, җәлеп иткән чараларын күрсәтергә мөмкинлек бирә. Болар барысы да язучының иҗади идеяләре һәм гомумиләштерү чыганагына хезмәт итә, аның иҗаты үскән туфрак булып тора.

Иҗат белән биографияне бәйләп өйрәнү, өйрәнелгән әсәрне, язучының сәнгатьчә индивидуальлеген тирәнрәк һәм тулырак аңлау өчен алыштыргысыз шарт булырга тиеш.

Димәк, монографик темада язучының иҗат лабораториясен өйрәнүнең төп бурычы – күренекле татар язучыларының иҗади эшчәнлеген яктырту һәм ул чорның социаль үсеше белән бәйле дөнья карашы эволюциясен тәэмин итә.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Бурсов Б.И. Писатель как творческая индивидуальность // Проблемы социалистического реализма. М.: Советский писатель, 1961. – С. 212-213.

2. Глебова Л.В. Изучение творческой лаборатории писателя как стимул литературного развития старшеклассников: Автореф. дис. канд. пед. наук Л., 1990. – 22 с.

**Ф.Ф. ХАРИСОВ,**
*педагогика фәннәре докторы, профессор*
*Казан федераль университеты*

## ЯҢАРТЫЛГАН СТАНДАРТ – ЗАМАН ТАЛӘБЕ

**Аннотация**. Федеральные образовательные стандарты позволяют учащимся получать знания на равных уровнях и открывают пути их развития, поскольку предъявляются одинаковые требования к содержанию и структуре учебных программ, условиям их реализации и результатам освоения. Поэтому требования стандарта обязательны к исполнению руководителями образования, учителями, различными работниками, учащимися, родителями, участвующими в образовании.

**Ключевые слова**: стандарт, программа, руководство, цель, задачи.

**Abstract**. Federal educational standards allow students to acquire knowledge at equal levels and open up ways for their development, since the same requirements are imposed on the content and structure of curricula, the conditions for their implementation and the results of mastering. Therefore, the requirements of the standard are mandatory for the heads of education, teachers, various employees, students, parents involved in education.

**Keywords**: standard, program, management, purpose, tasks.

Федераль дәүләт гомуми белем бирү стандарты (ФДГББС, стандарт) – дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары тарафыннан белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен мәҗбүри булган таләпләр җыелмасы. Барлык белем бирү программалары, дәреслекләр, уку-укыту кулланмалары һәм укыту процессында кирәк булган башка хезмәтләр Стандарт нигезендә төзелә. Алар укучыларга бертигез дәрәҗәдә белем алу мөмкинлеген тудыра һәм аны үстерү юлларын ача, чөнки уку программаларының эчтәлегенә һәм төзелешенә, аларны гамәлгә ашыру шартларына һәм үзләштерү нәтиҗәләренә бердәй таләпләр куела. Шуңа күрә стандарт таләпләрен белем бирүдә катнашучы мәгариф җитәкчеләре, укытучылар, төрле хезмәткәрләр, укучылар, әти-әниләрнең үтәве мәҗбүри.

Яңа стандарт белем бирү оешмалары алдына укучыларны мораль-әхлакый һәм мәдәни яктан белемле итү, иҗади һәм тикшеренү-проект эшләре, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру кебек таләпләр куя.

Татар теленә Стандарт нигезендә өйрәтүнең *максаты* түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

❖ белем бирүнең сыйфатын күтәрү;

- ❖ барлык балаларга да тигез күләмдә белем бирүне гарантияләү;
- ❖ тел, сөйләм, иҗтимагый-мәдәни, уку-танып белү компетенцияләрен үстерү;
- ❖ укучы шәхесен үстерү;
- ❖ универсаль уку гамәлләрен булдыру һәм камилләштерү.

Россиядә түбәндәге белем бирү стандартлары гамәлгә кертелде:

1. Башлангыч гомуми белем бирүнең яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандарты – 2021 (1–4 нче сыйныфлар);
2. Төп гомуми белем бирүнең яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандарты – 2021 (5–9 нчы сыйныфлар);
3. Урта гомуми белем бирүнең яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандарты – 2022 (10–11 нче сыйныфлар);
4. Сәламәтлекләре чикләнгән укучылар өчен башлангыч гомуми белем бирү стандарты – 2021.

ФДГББСның яңартылган таләпләре башлангыч һәм төп гомуми белем бирү оешмаларына 2021 нче елның 1 нче сентябреннән гамәлгә керде.

Икенче һәм өченче буын стандартлар арасында тәңгәллекләр дә бар: белем бирүнең нигезен шулай ук системалы-эшчәнлекле юнәлеш тәшкил итә; программаларны төзү һәм тормышка ашыруның методологиясе үзгәрми; программаның кабул ителгән төзелеше һәм вариативлыкны тәэмин итү алымнары саклана; программаларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләренә таләпләр үзгәрми, предмет, метапредмет һәм шәхескә юнәлтелгән төгәллекләр генә кертелә.

Яңартылган стандартларның кайбер үзенчәлекләре түбәндәгеләр:

- ❖ стандартлар «Россия Федерациясенең Мәгариф турында» гы Федераль законы белән тәңгәлләштерелгән;
- ❖ программаларны тормышка ашыру конкретлаштырылган;
- ❖ программаларны гамәлгә ашыру срокларында вариативлык каралган;
- ❖ укучыга инициативасын тормышка ашыру өчен, тиешле шартлар булдыру каралган.

Стандартның урта гомуми белем бирү юнәлешендәге үзгәрешләре 2022 нче елның 23 сентябреннән үз көченә керде. Алар нигездә белем бирү программасын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләренә – предмет, метапредмет һәм шәхескә караган нәтиҗәләренә кагыла, программаның уку планында һәм уку йөкләмәсендә дә үзгәрешләр бар.

Билгеле булганча, беренче буын стандарт 2004 нче елда гамәлгә кертелгән иде. Ул «Дәүләт белем бирү стандартлары» дип атала. Аның беренче редакциясен, укыту ысулларын куллану осталыгына әһәмият бирмичә, белем

бирүгә зур игътибар ителүе өчен тәнкыйтьлиләр, укучы «белем алганда» яхшы нәтиҗә бирә дип саныйлар.

Икенче буын стандарт башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында 2009 нчы, төп гомуми белем бирү оешмаларында 2010 нчы, ә урта гомуми белем бирү оешмаларында 2012 нче елдан башлап гамәлгә ашырылды. Стандартларда төп игътибар универсаль уку гамәлләренең (осталыкларының) нәтиҗәсенә һәм үсешенә бирелә.

Иске стандарт «Нәрсәгә өйрәтергә?» – дигән сорауга җавап бирсә, яңасы түбәндәгеләрне өсти: «Нәрсәгә өйрәтергә?» «Өйрәнгәннәр тормышта ничек ярдәм итәчәк?».

Өченче буын стандарт икенче буынның яңартылган варианты дип санала. Анда кайбер юнәлешләрнең мәҗбүри булмавы тәгаенләнә, ә башкаларына төгәллек кертелә. Моннан тыш кайберләре мәктәпләрдә сынала, ә аңа кадәр бер ишеләре турында киң җәмәгатьчелек һәм ата-аналар оешмалары белән фикер алышына. Шуңа күрә бу стандарт әллә ни көтелмәгән яңалыклар алып килмәсә дә, кайбер аермалыкларны билгеләргә мөмкин:

1. Стандартның яңа редакциясендәге төп аерма – һәрбер куелган таләп белән гамәлнең ачык һәм төгәлрәк формалаштырылуында.

2. Вариативлык. Белем бирү оешмалары аерым уку фәннәрен тирәнтен өйрәнүне күздә тоткан индивидуаль уку планнарын һәм программаларын төзү, аларны гамәлгә ашыру мөмкинлеген ала.

3. Элек патриотик тәрбиягә караган өлеше дә булырга тиеш дип язылса, хәзер аның аерым үзенчәлекләре барлыкка килә.

4. Предмет нәтиҗәләре төгәлрәк билгеләнгән. Хәзер укучының нәрсә белергә һәм нәрсәләрне аңларга тиешлеге төгәлрәк аңлатыла.

5. Стандартта «Функциональ грамоталылык» дигән яңа төшенчә кертелә. Функциональ грамоталылык төп гомуми белем бирү сыйфатының дәүләт гарантияләре эчендә карала.

6. Бу документ функциональ грамоталылыкны формалаштырылган предмет, метапредмет һәм универсаль эшчәнлек ысуллары нигезендә уку мәсьәләләрен һәм тормыш ситуацияләрен хәл итү сәләте буларак билгели. Башкача әйткәндә, укучылар өйрәнгән фәннәрнең һөнәр сайларга һәм тормышта үз урыннарын табарга ярдәм итәчәген аңларга тиеш.

7. Дәрестә укучылар эшчәнлегенең гомуми күләме үзгәрә, «уку модуле» төшенчәсе кертелә. Бу үзгәрешләр белем бирү оешмасының уку планын, уку предметлары буенча эш программаларын, дәрестән тыш эшчәнлек программаларын яңадан карап чыгуны таләп итә. Хәзер өстәмә норматив документлар

нигезендә, ана телен өйрәтү әти-әниләрнең (законлы вәкилләрнең) гаризалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

ФДГББС туган тел (татар теле) предметына түбәндәге таләпләрне куя:

❖ сөйләм эшчәнлеген (ишетеп аңлау, уку, сөйләү һәм язу) төрле мәдәният вәкилләре белән үзара аралашырга ярдәм итәрдәй итеп камилләштерү;

❖ белем алганда һәм аны камилләштергәндә, шәхеснең акыл һәм иҗади сәләтләрен үстерүдә туган теленең әһәмиятен аңлау;

❖ туган телнең аралашу-эстетик мөмкинлекләрен киңрәк файдалану;

❖ туган тел турындагы фәнни белемнәрне киңәйтү һәм системалаштыру; төрле ярус берәмлекләренең үзара бәйләнешен аңлау; лингвистиканың төп төшенчәләрен, туган телнең төп берәмлекләрен һәм грамматик категорияләрен үзләштерү. Лингвистик төшенчәләрне белү арадаш һәм дәүләт йомгаклау аттестациясенә чыгарылмый;

❖ сүзгә фонетик, морфемик, сүз төзелеше, морфологик, сүзтезмә һәм җөмләгә синтаксик анализ ясау күнекмәләрен формалаштыру;

❖ ситуациягә һәм аралашу стиленә туры килгән сүз байлыгын үстерү, фикер һәм хисләрне туган телдә ирекле белдерү өчен кулланыла торган грамматик чараларны киңәйтү;

❖ туган тел лексикасының һәм фразеологиясенең төп стилистик мөмкинлекләрен, нормаларын (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик, пунктуацион), сөйләм әдәбе нормаларын үзләштерү; аларны сөйләмдә куллануны камилләштерү;

❖ тел культурасы өчен җаваплылык формалаштыру;

❖ балаларда тирә-якны танып белүгә кызыксыну уяту.

Дәрес планлаштыруның максаты – укучыларны төрле эшчәнлеккә өйрәтү. Стандарт буенча яңа дәрестә түбәндәге этаплар билгеләнә: белем һәм осталыкны үстерү, проблема кую; гипотезаларны билгеләү, куелган проблеманы хәл итү өчен, төрле чыганаклардан кирәкле мәгълүмат җыю, беренчел белемне ныгыту, алган белемне проект төзегәндә куллану.

Татар теле дәресләрендә укучыларда түбәндәге компетенцияләрне булдыру күзаллана:

❖ *лингвистик* (укучыларның татар теленнән тиешле белемгә ия булуы);

❖ *аралашу* (укыганны һәм башкалар сөйләгәнне ишетеп аңлау, татар әдәби теле нормаларына ия булу);

❖ *этнокультура* өлкәсенә караган (милли-мәдәни мираска караган рухи байлыкларны белү, халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныш булу һ. б.).

Заманча дәреснең эчтәлеге түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

*Тел белеменә һәм аралашуга караган ягы:*

❖ тел бүлекләре буенча белем бирү;

❖ сөйләмнең аралашуга караган ягына әһәмият бирү (аралашу өлкәсе, темасы, аралашу ситуациясе);

❖ сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча алган белемне камилләштерү;

❖ иҗтимагый-мәдәни аспект.

*Психологик-педагогик ягы:*

❖ сөйләм-фикерләү схемасын гамәлгә ашыру;

❖ кызыксыну уяту.

*Методик ягы:*

❖ укыту принципларын, метод һәм алымнарын куллану;

❖ заманча укыту технологияләренә игътибарны көчәйтү.

Шулай итеп, хәзерге стандартта икенче буын стандарттагы укыту нәтиҗәләре саклanса да, аңа бераз төгәллекләр дә кертелгән:

❖ *предмет нәтиҗәләре* (татар теленнән программада каралган белем, осталык һәм күнекмәләргә ия булу);

❖ *шәхескә юнәлтелгән нәтиҗәләр* (укучының даими рәвештә белемен тулыландыруы, аны үзлектән камилләшерергә әзер булуы һ. б.);

❖ *метапредмет нәтиҗәләре* (белем алу нигезен тәшкил иткән төп компетенцияләргә ия булуы, предметара төшенчәләрне үзләштерүе.

Укытучының төп бурычы – *Нәрсәне һәм ничек итеп укытырга?* дигән сорауга җавап бирү. Димәк, хәзерге заман таләпләренә җавап бирә торган дәрес түбәндәге шартларны үтәргә тиеш:

❖ системалы-эшчәнлекле юнәлешне гамәлгә ашыру;

❖ укучыларның белем дәрәҗәләрен истә тотып, программа нигезендә һәм дәреснең максатыннан чыгып, иң кулай эчтәлекне билгеләү;

❖ укытучы белән укучыларның эшчәнлеген тема, максат һәм бурычларны төгәл һәм аңлаешлы итеп формалаштырудан башлау;

❖ тиешле нәтиҗә бирә торган метод, алым һәм чараларны сайлау, аларны дәрестә эшнең нәтиҗәсенә уңай йогынты ясарлык итеп файдалану;

❖ заманча технологияләрне кулланып, белем бирү;

❖ төрле эш формаларын дөрес һәм төгәл бәйләп алып бару, укучыларга танып белү активлыгын тәэмин итәрлек мөстәкыйльлек бирү;

❖ проблемалы һәм эзләнү ситуацияләрен оештыру, укучыларның уку эшчәнлеген активлаштыру;

❖ дәреснең проблемалы һәм үстерелешле булуы: укытучының укучылар белән иркен һәм актив хезмәттәшлек итүе һ.б.

Дәресне модельләштергәндә, түбәндәгеләр истә тотылырга тиеш:

❖ телгә караган билгеләр (фонетика, лексика, грамматика, орфография);

❖ сөйләмдәге билгеләр (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу);

❖ дидактик билгеләр (кереш, аңлату, ныгыту, сөйләм күнегүләре, аралашу практикасы, тикшерү);

❖ методик билгеләр (принциплар, методлар, алымнар, яңа технологияләр);

❖ дәрес төзелешенә караган билгеләр (этапларының эзлеклелеге);

❖ тәрбия һәм белем бирүгә караган билгеләр.

Яңартылган стандарт таләпләре нигезендә уздырылган дәрескә хас сыйфатлар:

❖ куелган максатка туры килә;

❖ шәхескә юнәлтелгән була;

❖ дәресләр аралашуга корыла;

❖ сабырлык, мәхәббәт хисе уята, укучының хәленә керү, аңа теләктәшлек күрсәтү кебек сыйфатлар тәрбияләнә;

❖ комплекслылык (сөйләм эшчәнлеге төрләре һәм тел аспектлары);

❖ хәтер, сөйләм, игътибар, фикерләү һәм ишетү сәләтен үстерә;

❖ заманча технологияләргә нигезләнә;

❖ проблемалылык (фикер алыша торган проблеманы ачыклау);

❖ логикага туры килә (дәрес өлешләренең үзара бәйләнгән булуы).

Шулай итеп, заман таләпләренә җавап бирә торган дәрес түбәндәге очракларда нәтиҗәле дип санала:

❖ максатны билгеләгәндә, укучы актив булса;

❖ дәрестә укучыларның активлыгын һәм кызыксынуын көчәйтә торган төрле формалар, методлар, алымнар һәм чаралар кулланылса;

❖ барлык укучыларның да материалны аңлы рәвештә үзләштерүләренә ирешелсә;

❖ укучыларга аерым якын килеп, белем бирелсә;

❖ репродуктив һәм проблемалы укыту формаларын кулланылса;

❖ һәр укучыны бәяләп, кечкенә уңышларын да хупланса.

Стандарт һәм заман таләпләренә җавап биргән дәреснең кайбер уңай якларын да ассызыклыйк:

❖ системалы-эшчәнлекле юнәлеш буенча белем бирүнең сыйфатка сизелерлек йогынты ясавы;

❖ дәрес бурычларын төрле яклап планлаштыру;
❖ дәрес эчтәлегенә иҗади характердагы биремнәрне өстәү;
❖ укучыларның дөньяга карашын булдыру һәм киңәйтү;
❖ белем бирүнең гамәли эшкә юнәлтелгән булуы;
❖ сәламәтлекне саклау һәм үстерү технологияләрен даими куллану;
❖ укучыларга аерым якын килү (мәсәлән, өй эшен биргәндә) һ. б.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Обновленные стандарты начального общего образования 2021 https://www.garant.ru/products/ipo/prime/doc/400807193/?ysclid=ll2n1gdic9620109373

2. Обновленные стандарты общего образования 2021 https://infourok.ru/prezentaciya-federalnyj-gosudarstvennyj-obrazovatelnyj-standart-osnovnogo-obshego-obrazovaniya-ot-31-05-2021g-izmeneniya-i-popra-5441360.html?ysclid=ll2n5dj6kb65683734

3. Обновленные стандарты среднего общего образования https://www.garant.ru/products/ipo/prime/doc/405172211/?ysclid=ll2n9ep4gh712678558

**Г.Ф. ХӘСБИУЛЛИНА**

*магистрант*

*Казан федераль университеты*

# БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФЛАРДА МӨСТӘКЫЙЛЬ СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕН МӘГЪЛҮМАТИ-АРАЛАШУ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ЯРДӘМЕНДӘ УКЫТУ

**Аннотация.** Знакомство с самостоятельными частями речи на уроках татарского языка происходит в начальных классах. В статье рассматириваются возможности обучения самостоятельным частям речи в начальных классах с помощью информационно-коммуникационных технологий. В использовании языкового материала учитывается и то, что учащиеся могут воспитываться в билингвальной или полилингвальной среде.

**Ключевые слова:** начальная школа, татарский язык, информационно-коммуникационные технологии.

**Abstract.** Acquaintance with independent parts of speech in Tatar language lessons occurs in primary school. In our scientific work, we will focus on identifying the possibilities of teaching independent parts of speech in primary school with the help of information and communication technologies. Also in our work we took into account the fact that students can be brought up in a bilingual or multilingual environment.

**Keywords:** primary school, Tatar language, of information and communication technologies.

Татар теле дәресләрендә мөстәкыйль сүз төркемнәре белән танышу башлангыч сыйныфта башлана. Фәнни эшебездә башлангыч сыйныфларда сүз төркемнәрен мәгълүмати-аралашу технологияләр ярдәмендә укыту мөмкинлекләрен ачыклауга тукталабыз. Шулай ук укучыларның билингваль яки полилингваль мохиттә тәрбияләнүен исәпкә алабыз.

Хезмәтебездә мисал итеп «Сәлам» уку-методик комплектындагы темалар бирелешен кулланабыз. Әлеге УМКның Интернетта үзенең тулы сәхифәсе бар, шуңа күрә мәктәпләрдә мәгълүмати-аралашу технологияләрне куллану өчен уңай шартлар тудырылган очракта, «Сәлам» сәхифәсен дәрес барышында файдаланырга мөмкин. «Сәлам» укыту-методик комплектының онлайн сәхифәсен мәгълүмати-аралашу технологияләр ярдәмендә укыту өчен күп төрле материал тупланган. Сайтта «Уеннар», «Рәсемнәр», «Җыр», «Дәреслек», «Эш дәфтәре» бүлекләре бар. Мәсәлән, беренче сыйныф дәреслегендә тәкъдим ителгән «Сәлам», «Мәктәп», «Саннар», «Төсләр», «Гаилә», «Шөгыльләр», «Уенчыклар», «Вакыт», «Шәһәр / авыл», «Ашамлыклар» бүлекләрендә укучылар аерым бер темага караган исемнәр, сыйфатлар, саннар, фигыльләр, алмашлыклар һәм рәвешләрдән төзелгән сүзләр белән таныша. Балалар әлеге сүз төркемнәрен, аларның җөмләдә кулланышын сорау һәм җавапларга нигезләнеп үзләштерә башлый. Икенче, өченче, дүртенче сыйныфларда яңа темалар, шул исәптән яңа лексик берәмлекләр өстәлә, шул ук вакытта алданрак өйрәнелгән материаллар да ныгытыла.

Күнегүләрнең күбесе яңа сүзләр һәм фразаларның әйтелешен тыңлаудан башлана. Мәсәлән, «тыңла һәм кабатла», «тыңла һәм рәсемне тап», «тыңла һәм дәвам ит», «тыңла һәм уйна», «тыңла һәм истә калдыр», «тыңла һәм Артур урынына җавап бир», «тыңла һәм дөрес варианты тап». Шул исәптән, махсус җайланмалар аша укучыларны аудиоматериаллар белән таныштыру да кирәк.

Югарыда санап кителгән темаларны өйрәнгәндә, аралашу-мәгълүмати технологияләрдән башкача да куллану мөмкин.

«Quizlet» онлайн-сервисында белемнәрне карточкалар ярдәмендә ныгытып була. Аеруча, карточкаларга тәрҗемәне яки аңлатманы сүзләр белән генә түгел, төрле рәсемнәр белән бирү уңышлы дип саныйбыз, чөнки болай эшләгәндә, укучыда ассоциацияләр барлыкка килә, шул рәвешле мәгълүмат яхшырак истә кала.

«LearningApps.org» сайтында күп төрле онлайн уеннар ясау мөмкинлеге бар. Мәсәлән, монда үзеңнең материалыңны әзерләү өчен «парын тап», «классификация», «дөрес җавапны сайлап алулы викторина», «буш урыннарны тутыр», «кроссворд» кебек бүлекләр бар. Уеннарны укучыларны чиратлап эк-

ран янына чыгарып уйнатып була. «LearningApps.org» сайтында биремнәрне «Аудио/видео контент» бүлегендә дә әзерләргә шартлар бар. Монда сан сүз төркеменә аудио һәм видео материаллар урнаштырып, шулар буенча сораулар куярга мөмкин.

Укучыларның билингваль яки полилингваль мохиттә тәрбияләнүен исәпкә алып, хәзерге вакытта халыкара тел буларак исәпләнгән инглиз телен укыту методларын да үзләштерү бик мөһим. Инглиз теле дәреслекләрен дә анализлап, кызыклы һәм файдалы күнегүләрне татар теле дәресләренә дә яраклаштырырга була.

Билингваль һәм полилингваль уку-укыту процессы, ягъни икетеллелек яки күптеллелек ул – ике яки аннан да күбрәк телне укыту чарасы буларак куллану. ЮНЕСКО аңлатмасында «күптелле уку-укыту» термины ким дигәндә өч тел куллану дигәнне аңлата: туган телне, региональ яки милли телне һәм халыкара телне.

2019 елдан Татарстан Республикасында полилингваль мәктәпләр булдыру буенча уникаль проект эшләп килә. Татарстандагы полилингваль мәктәпләр максат итеп рус, татар һәм инглиз теледә белем бирүне куя. Полилингваль укыту берничә телдә укытуны һәм балаларны өйрәнелгән тел аша Россиянең күпмилләтле халкының мәдәни байлыгы белән таныштырудын гыйбарәт. «Адымнар» полилингваль комплексларының беренчеләре Татарстанда 2020 елның 1 сентябрендә ачылды. Берничә ел элек Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында билингваль уку-укыту өчен белгечләр әзерләү башланды, хәзерге вакытта полилингваль комплексларда укыта алырлык белгечләребез бар.

Инглиз теле дәреслекләрендә татар телендәгечә фонетика, морфология, лексикология, синтаксис кебек аерым ачык бүленешләр күренми. Яңа сүзләр һәм грамматик конструкцияләр сөйләм үсешен үстерү белән бер рәттән махсус тема эчендә карала.

Чит телне укытуның башлангыч этабында төп игътибар фонетикага һәм грамматика нигезләренә юнәлдерелгән. Куелган фонетик базадан башка лексикага интенсив өйрәтү нәтиҗәле түгел, чөнки дөрес булмаган сөйләм ныгытыла, бу исә сөйләм үсешендә тискәре чагылыш таба, һәм башка сөйләм осталыгын аудированиене озак вакыт дәвамында үстерергә ирек бирми. Грамматикадан башка сүзлекне теоретик яктан тулыландыру мөмкин булса да, сүзгә чыгуны, ягъни телне гамәли белүне тәэмин итми, чөнки коммуникациянең тулы берәмлеге аерым сүз түгел, ә тулы гыйбарә. Икенче яктан, фонетик һәм грамматик уку материалы лексик берәмлекләрсез төзелә алмый. Фонетик кереш курста

лексик дәрәҗә җәлеп ителгән (сүз ритмикасы, интонация), ә грамматика турында сөйләгәндә, без сүзнең төрләндерелә торган грамматик формасын күз алдында тотабыз. Лексик берәмлекләр гади фонетик һәм грамматик күнекмәләр формалаштыру өчен материал буларак, шулай ук гади коммуникатив ихтыяҗларны тәэмин итү өчен кирәк. Шуңа да башлангыч этапта укучының сүз байлыгы минималь һәм төгәл тематикалы була, башка сүзләр белән яраша һәм еш кулланыла торган сүзләрдән тора [Киберленинка: https://cyberleninka.ru/article/n/sistema-formalizovannyh-kriteriev-otsenki-shkolnogo-uchebnika].

Татар телен чит тел буларак өйрәткәндә дә, инглиз телен укытканда да программага кертелгән темалар, дәреслекләрдә бирелгән лексик база охшаш. Мәктәптә укыту процессында башлангыч сыйныфларда укучыларның яхшы дәрәҗәдә инглиз теле белән таныш булулары күзәтелә. Мәсәлән, укучылар белән татар теле дәресендә саннарны яки төсләрне өйрәнгәндә, алар кайвакыт җавапларын инглиз телен катыштырып бирә. Укучылар үзләре моны икесе дә тел дәресе булуы, шуңа кайвакыт ике тел төшенчәләренең буталуы белән аңлата, шулай да бу алар тарафыннан махсус та эшләнә, алар татар теле дәресендә шаярып, инглиз телен дә белгәннәрен күрсәтәләр. Шуны исәпкә алып, укучыларга кайбер төшенчәләрнең тәрҗемәсен татарчадан русчага гына түгел, ә инглизчәгә дә бирү мөмкин. Мәсәлән, саннарны, төсләрне, кайбер фигыльләрне, исәнләшү, саубуллашу һәм хәл сорашу фразаларын, гаилә әгъзалары, уку әсбаплары атамаларын өч телдә карап була. Беренче этап: «Quizlet» сайтындагы мөмкинлекләрдән файдаланып, карточкаларда сүзләрне тәрҗемә аша түгел, ә ассоциатив рәсемнәр ярдәмендә күрсәтү. Куллану өчен карточкалар югарыда искә алынган «Quizlet», шулай ук «Vocapp» сайтларында эшләнә ала яки шунда ук әзер материал табарга да була. Рәсемле әзер карточкалар «Сәлам» уку-укыту әсбабының онлайн сайтында да тәкъдим ителә. Икенче этап: сүзләрнең русчага тәрҗемәсен бирү. Өченче этап: укучыларның шул ук сүзләрнең инглизчә тәрҗемәсен белү дәрәҗәсен тикшерү. Әгәр укучылар өйрәнелә торган сүзләрнең атамаларын инде инглизчә белә икән, укытучы лексик берәмлекләрне инглизчә әйтеп, татарчага тәрҗемәсен сорый ала. Шулай ук «Quizlet» һәм «LearningApps.org» кебек сайтларда ике телле сораштырулар үткәрергә була. Мәсәлән, 4нче сыйныфта укучылар гаилә әгъзаларын искә төшерә, әлеге темага караган яңа сүзләрне өйрәнә һәм гаиләдәге кешеләрне, туганнарын сыйфатлар ярдәмендә тасвирларга өйрәнә. 4нче сыйныфта укучылар әти, әни, әби, бабай, апа, абый, туганнан туган кебек төшенчәләрне инглизчә дә

белә, шуңа күрә, мәсәлән, дәрес башында сүзләрне искә төшереп алыр өчен, укучыларга ике телдәге карточкалар тәкъдим итәргә мөмкин.

Илебездә мәктәпләрдә укучыларга иң еш чит тел буларак укытыла торган тел – инглиз теле. Шуңа да татар теле дәресләрендә инглиз теле дәресләрендә гамәлгә ашырылган тәҗрибәне үзләштерергә мөмкин. Инглиз теле дәреслекләрендәге күнегүләрне татар теле дәресләренә яраклаштырып, информацион-коммуникатив технологияләр ярдәмендә укучыларга тәкъдим итәргә була. Тел өйрәнүнең информацион-коммуникатив ресурслары да хәзергә күбесенчә инглиз телен өйрәтүдә кулланыла. Без ул ресурсларны татар теле дәресләрендә кулланыла алырлык материаллар белән баета алабыз.

## ӘДӘБИЯТ


1. Киберленинка. Система формализованных критериев оценки школьного учебника – URL: https://cyberleninka.ru/article/n/sistema-formalizovannyh-kriteriev-otsenki-shkolnogo-uchebnika (Мөрәҗәгать итү датасы: 15.10.2023).
2. Киберленинка. Особенности обучения лексическому компоненту речи на различных этапах (на материале английского языка) – URL: https://cyberleninka.ru/article/n/osobennosti-obucheniya-leksicheskomu-komponentu-rechi-na-razlichnyh-etapah-na-materiale-angliyskogo-yazyka (Мөрәҗәгать итү датасы: 15.10.2023).
3. УМК «Сәлам!» // URL: http://selam.tatar
4. Харисов Ф.Ф. Татар теле: яңача укыту юнәлешләре. – Казан, 2015. – 53 б.



**И.М. ХИСМӘТУЛЛИНА**

*студент*

*Казан федераль университеты*


# ОРЕНБУРГ ТАТАР-КАЗАК ГАСКӘРИЛӘРЕНЕҢ ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ ГРАММАТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР


**Аннотация.** Эта статья посвящена исследованию грамматических особенностей языка татарских казаков Оренбургского казачества конца XIX – начала XX веков. Источником являются фольклорные тексты и дневниковые записи татар-казаков. В статье кратко изложены история Оренбургсого казачества. Особое внимание в статье акцентируется на своображие употребления глаголовв разных текстах.



**Ключевые слова**: нагайбеки, татары, казачество, история татар, формы глаголов.



**Abstract.**This article is devoted to the grammatical features of the language of Nagaibeks and Muslim Tatars in the Orenburg Cossacks at the end of the 19th – beginning of the 20th centuries. Language materials are analyzed on the basis of articles and diaries that were written over the centuries. The article attaches particular importance to the peculiarities of verb forms and tenses.



**Keywords**: Nagaybeks, Tatars, Cossacks, history of the Tatars, verb forms.

Оренбург казак гаскариләренең килеп чыгышы турындагы мәсьәләгә карата әлегәчә фәнни тирәлектә бәхәсләр тудыра. Казак тарихын өйрәнүчеләрнең аерым бер өлеше (М.Хорошхин) 1755 елны Оренбург казак гаскәренең башлангыч этабы дип саный [5, с. 37].

Башка тарихчылар XVIII гасырда ук әйткән П.И. Рычковның фикеренә кушылалар: «Оренбург казак гаскәрләренең нигезенә И. Кирилов сала. Ул үзенең өендә чыгышлары буенча рус һәм чит төбәк кешеләрен җыя. Шул рәвешле ул күпчелек качак булган ирләрне аучы буларак туплый». Бу фикергә Н.Чернавский, Ф.М.Стариков, В.Н.Витевский һ.б. кушыла.

1740 елларда ук Оренбург линиясенә татарларны да күчерү башланган. 1744 елда татарлар Сеитово (Каргалы) бистәсенә нигез сала (176 гаилә, меңгә якын кеше). Соңыннан Сәет бистәсендә яшәүчеләр тулы составта Оренбург казак гаскәренә күчерелә. Татарларның булуы Борская, Мочинская, Озерная, Красногорск ныгытмаларында билгеләп үтелә [4, б. 20].

Оренбург өлкәсендәге татар-казакларның тарихын өйрәнгәндә, беренче чиратта игътибарны Оренбург экспедициясе (1734-1737 еллар) һәм Оренбург комиссиясенең (1937-1744 еллар) күренекле эшлеклесе П.И. Рычковның хезмәтләрендә тукталырга кирәк. Ул Көньяк Урал халыкларының хуҗалык рәвеше һәм социаль үсеше турында хәбәр итә, беренче булып татар казаклары турында телгә ала һәм төбәктә рус хакимияте формалашуы турында яза.

Ф.М. Стариков фикерләре дә аерым игътибарга лаек. Ф.М. Стариков фәнни хезмәтләрендә мөселман-казаклар һәм нагайбәкләр турында этнографик мәгълүматларны хәбәр итә. Галим нагайбәкләрнең килеп чыгышын, нагайбәкләр арасында сакланган риваятьләргә нигезләнеп, Арча төбәге татарлары белән бәйли. Оренбург губернасы тарихы буенча күп кенә хезмәтләр калдырган В.Н. Витевский нагайбәкләр белән махсус кызыксына. Аның хезмәтләрендә Оренбург казак гаскәрләренең килеп чыгышы һәм Көньяк Уралда ныгытмаларның төзелеше карала. В.Н. Витевский халык арасында яшәп килгән риваятьләргә һәм Фершампенуаз авылы (Чиләбе өлкәсе) урядникгы С.И.Никитинда булган документларга таянып, нагайбәк халкын Явыз Иван вакытында ук үзләре теләп чукынган һәм Нагайбәк авылы тирәсенә күчереп утыртылган Арча татарлары дип саный [2, б..264-267].

Оренбург казаклары арасында татарларның рекордлы саны 1902 елда теркәлгән һәм 9,54% тәшкил иткән, бу 11900 нагайбак кешесе һәм 27300 мөселман казагы (барлыгы 39200 кеше).

Оренбург казаклары арасында төрле милләтләр булган. Күпчелеген татарлар тәшкил иткән. Алар арасында 2 конфессия вәкиле булуы язма

чыганаклардан ачык билгеләнә. Эшебездә христиан динендәге нагайбәкләрнең тел үзенчәлекләре В.Н.Витевский язмаларына нигезләнеп, мөселман казакларының тел үзенчәлекләре исә Ибраһим Мәхмүтовның көндәлек дәфтәрләренә нигезләнеп тикшерелде.

В.Н.Витевскийның «Сказки, загадки и песни нагайбаков Верхнеуральского уезда Оренбургской губернии»дип аталган язмалары 2 өлештән тора. Беренче өлештә автор рус телендә нагайбәк халкының килеп чыгышын, аларның татар халкына якын булуларын, гореф-гадәтләрен билгели [2, б.262-268]. Күзәтүнең икенче өлешендә халык авыз иҗаты үрнәкләрен жанр ягыннан бүлә. Беренче җырлар бирелә һәм алар тематик яктан дини, көнкүреш, мәхәббәт, хор белән башкарылучы төрләрдән тора һәм туй, яуга бару, тарихи җырлар, әкиятләр бирелә.

Безнең кулга казак гаскәрие Ибраһим Мәхтүтовның 1819-1915 елларны эченә алган көндәлек материаллары керде. Әлеге көндәлек тарихчы Р.Р. Аминов һәм А.М. Гайнутдинов тарафыннан табылган һәм аерым чыганак итеп нәшер ителгән [1]. Көндәлектә шул чор татар-мөселман казак гаскәриләренең яшәеше, көнкүреше китерелә һәм анда да җырлар, шигырьләр, догалар урын алган. Көндәлекнең эчтәлеге И.Мәхмүтовның динле, киңкырлы һәм күп өлкәдә белемле булуын күрсәтә.

Чыгышта ике истәлектә дә зур урын алган фигыль төрләренә тукталабыз. Ике авторга да графикага бәйле күзәтү ясаганда, орфографиягә бәйле ике чыганак та төрле графикада кулланылган.

В.Н. Витевскийның тексты инкыйлабка кадәрге кирилл орфографиясендә бирелгән, өстәмә **Ӧ, Ӓ, Ӱ** хәрефләре өстәлгән, аерым очракларда **[Ә]** авазын белдерү өчен **Я** хәрефе кулланылган: *меҥнярь-меңнәр, биргянь-биргән, ӧстялгя-өстәлгә.* Ибраһим Мәһмүтовның көндәлеге гарәп шрифты белән язылган.

Хикәя фигыльләргә күзәтү түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкинлек бирә. Ике истәлектә дә хәзерге заман хикәя фигыльләр кулланылган. Хәзерге заман күрсәткечләре -а/-ә/-ый/-и зат белән төрләнгәндә хәзерге татар әдәби телендәгечә: *алмыйымъ* (хәз. алмыйм) [В: 271], *белмейбезь* (хәз. белмибез) [В: 268], *кайыра* (хәз. каера) [В: 268], *қарыймын (*хәз: карыйм*)* [М: 26а], *күрәсүн* (хәз. күрәсең) [М: 26а], *утенәмен (хәз. үтенәм)* [М: 27б], *уйлаймын* (хәз. уйлыйм) [М: 28а].

Үткән заманның *-ды/-ган* формаларына тукталабыз. Грамматик яктан формаларның кулланылышында үзенчәлек юк: *башладыларъ* (хәз. башладылар) [В: 278], *кордымъ* (хәз. кордым) [В: 268], *булмаганъ* (хәз. булмаган) [В: 277]; *салганнаръ* (хәз. салганнар) [В: 278]; *уйылганъ* (хәз. уелган) [В: 272]. Фәкать

И. Мәхмүтов көндәлекләрендә иске татар әдәби телдә язу традициясен саклавы билгеләнде. Бу, бигрәк тә, III заттагы *-дур/-дүр;-ду* кушымчасының иренләшкән вариантын куллануда күренә: *үрмәдүм* (хәз. үрмәдем) [М: 26а], *сағындум* (хәз. сагындым) [М: 26а], *қалдуғыз* (хәз. калдыгыз) [М: 27б].

Ике язмада да киләчәк заманның *-ыр/-ер* формасы гына бирелгән: *ачылыръ* (хәз. ачылыр) [В: 273]., *басылыръ* (хәз. басылыр) [В: 273]. И.Мәхмүтов исә көндәлектә киләчәк заман кушымчалары борынгы иренләшкән вариантын саклап яза: *қайтурбыз* (хәз. кайтырбыз) [М: 26а], *керүр*(хәз. керер) [М: 26б].

Теләк фигыль формалары аналитик кушымчалар ярдәмендә ясала *(-ыр иде/-ер иде)*. Әмма В.Н.Витевскийда ул кушылган һәм *ачаръйемь* (хәз. ачар идем) [В: 270]; *сяўäрьйемь* (хәз. сөяр идем*)* [В: 270]; *кюрешерьйемь* (хәз. күрешер идем) [В: 275]. Мәхмүтов көндәлегендә исә ярдәмче фигыльләр саклана һәм традицион язылышка өстенлек бирелгән: *қайтур идук* (хәз. кайтыр идек) [М: 26 б].

В.Н.Витевский язмаларында затланышсыз фигыль формаларыннан I зат теләк фигыль өстенлек итә: *алыйыкъ* (хәз. алыйк) [В: 273], *жыгылыйыкъ* (егылыйк) [В: 269]; *асырамыйыкъ* (хәз. асрамыйк) [В: 278]. Ибраһим Мәхмүтов материалында теләк фигыль борынгы әдәби тел традицияләрен саклап, **-гыл/-гел, -ың/-ең, -гай/-гәй** кушымчалары белән бирелә: *бәхил булың* (хәз. бәхил бул) [М: 27б], *сау булыңыз* (хәз. сау булыгыз) [В: 28а]. Көндәлектә боерык фигыльнең хәзерге татар телендә дә актив формасы кулланыла: *қылсын инде* (хәз. кылсын инде) [М: 28а], *сәламәт булсын* (хәз. сәламәт булсын) [М: 28а].

Ике язма истәлектә дә *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыль формаларында сүз ахырында һәрвакытта да яңгырау **[б]** авазының язылышы үзенчәлеге күзәтелә. ***Суйырылыбъ*** *ўскянь талларъ жукъ* [В: 275]; *Кязя тякясе белянь сарыкъ тякясень* ***чыгарыбъ*** *жибярделярь* [В: 278]; *Алты атъ* ***жигебь*** *сабанъ сöрдемь* [В:268]; *Сöткеняйень* ***сауыбъ*** *шикярь итъ* [В: 269]; *Äле жöрейбезь бергя-бергя,* ***Айырылыбъ*** *китсякъ шулъ жаманъ* [В: 270], Мәхмүтовта хәл фигыль формасында шулай ук иске татар теленең традициясе саклана: *торуб* (хәз. торып) [М: 26б], *алуб* (хәз. алып) [М: 26б], *салуб* (хәз. салып) [М:26б], *менүб* (хәз. менеп) [М: 26а].

XIX – XX гасыр истәлекләрен чагыштыру фигыль формаларын тикшерү түбәндәге нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирде. Ике язмада фигыль формаларын куллануда бертөрлелек күзәтелә. Без тикшергән затланышлы фигыльләрдә кулланылыш формаларының һәм мәгънә ягыннан сакланышы охшаш. Алар хәзерге татар әдәби теленнән аерылмый. Әмма орфографиядә ике истәлек арасында үзенчәлекләр күзәтелде. Бу, бигрәк тә. казак гаскәрие Ибраһим Мәхмүтов

көндәлекләрендә иске татар әдәби теленә хас традицияләрнең саклап язуында күренде. В.Н.Витевскийның кириллицига нигезләнгән язмасында исә, сөйләм теленә хас үзенчәлекләргә нигезләнүе күзәтелә.

## ӘДӘБИЯТ


1. Аминов Р.Р., Гайнутдинов А.М. Дневник татарина-казака Ибрагима Махмутова. – Казань: Грумант, 2021. – 260 с.

2. Витевский В.Н. Сказки, загадки и песни нагайбаков Верхнеуральского уезда Оренбургской Губернии // Труды IV Археологического Съезда в России, бывшего в Казани с 31 июля по 18 августа 1877 года. – Т. II. – Казань: Типография Императорского университета, 1891 – 652 с.

3. Җәләй Л. Татар диалектологиясе:югары уку йортлары һәм педагогия училищелары студентлары өчен дәреслек. – Казан, 1947. – 137 б.

4. Кортунов А.И. Численность и национальный состав Оренбургского казачьего войска в XVIII - XIX вв. – Оренбург, 2004. – 32с.

5. Хорошхин М.П. Казачьи войска: опыт военно-статистическаго описания / сост. Ген. штаба полк. Хорошхин. – Санкт-Петербург: Тип. А.С. Суворина, 1881. – 311с.



**З.Р. ХУҖИНА**

*магистрант*

*Казан федераль университеты*


# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ИННОВАЦИОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНУ


**Аннотация.** В статье приведены инновационные методы использования технологий на уроках татарской литературы. Особое внимание уделяется на интерактивное оборудование, на мультимидейный проектор. Так же описываются результаты, возможные получить при использовании инновационных технологий на уроках татарской литературы.



**Ключевые слова:** инновационные технологии, источники информации, интерактивная доска, мультимедийный проект, Интернет-ресурс, воспитательная цель, образовательная деятельность.



**Abstract.** The article presents innovative methods of using technologies in the lessons of Tatar literature. Special attention is paid to interactive equipment, a multi-idea projector. It also describes the results that can be obtained by using innovative technologies in the lessons of Tatar literature.



**Keywords:** innovative technologies, information sources, interactive whiteboard, multimedia project, Internet resource, educational goal, educational activity.


«...Заман һәм мәдәният алга үскәнчә һәм, икенче төрле итеп әйткәндә, ихтыяҗ һәм мәҗбүрилек кебек нәрсәләр мәҗбүр иткәнчә, укыту рәвешләре төрләләнер, монда исә акыл ияләре берләшәләрдер», – дип язып калдырган

күренекле мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддин. Дөрестән дә, техника зур тизлек белән үсеш алган инновацияләр чорында мәгариф системасы да читтә калмады. Заманча техника белән җиһазландырылган мәктәпләр, укытуда яңа методик алымнар, технологияләр кулланыла; укучыларның белемнәрен тиз генә тикшерергә мөмкинлек бирә торган күнегүләр һәм мәсьәләләр файдаланыла. Шул рәвешле, белем бирүдә инновацион юнәлешне үстерү – төп бурычларның берсенә әверелде һәм нәтиҗәле чара булып өлгерде. Чөнки инновацион технологияләр балада укуга карата кызыксыну уята, материалны тирәнрәк үзләштерүгә нигез булып тора, укучыларның иҗади сәләтен үстерү мөмкинлеген бирә. Кыскасы, күздә тотылган технологияләр укучының белем алу эшчәнлеген активлаштыруда зур роль уйный.

Заман таләпләре белән бергә атлап үскән укучы балаларны кызыксындыру өчен мәгълүмати белем чыганакларын куллану – укытучы алдында торган мөһим таләпләрнең берсе. Шул рәвешле мәктәпләр интерактив такталар, мультимедиа проектлары белән җиһазлана, дәресләрдә компьютерлар кулланыла.

Татар әдәбияты дәресләрендә инновацион технологияләр куллану укытучыга берникадәр ярдәмгә килсә, укучыларда телгә һәм фәнгә карата мәхәббәт уятуда зур роль уйный. Дәресләрдә интерактив тактага мөрәҗәгать итү нәтиҗәсендә дәрес тагын да мавыктыргыч һәм нәтиҗәле була. Язучылар, шагыйрьләр биографиясен үткәндә, алар турындагы мәгълүматны слайдлар ярдәмендә күрсәтеп бару – һәр балага күрсәтмә материалның ачык булуына китерә, нәтиҗәдә укучы авторның туган-үлгән елын, фотосын һ.б.ларны истә калдыра. Шулай ук, мөстәкыйль рәвештә фотосурәтләр, төрле схемалар, рәсемнәр белән прензентацияләр әзерләп, инновацион технологияләр белән эшләргә өйрәнәләр, шул ук вакытта, биремне матур һәм камил итеп башкарырыга тырышалар.

Татар халкының йола, гореф-гадәтләрен, халык авыз иҗатын үткәндә дә презентация ясау, слайдлар куллану урынлы. Слайдларга фотолар кую нәтиҗәсендә, укучылар йолаларның үткәрелү рәвешен күреп истә калдыра, онытылып барганнары белән таныша; табышмаклар чишә, мәкальләр укый. Шулай ук, коммуникатив һәм тәрбияви максатларны күздә тотып, кызыклы этнографик-тарихи темаларны яктыртып, слайдлар ярдәмендә укучыларга үз халкының үткәне турында күпмедер күләмдә мәгълүмат биреп, аларда татар тарихын өйрәнүгә мотивация булдырырга мөмкин. Ягъни, татар милли бизәкләре, татар халкының киенү үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре, аш-су осталыгы, кулдан эшләнгән эш кораллары турында мәгълүмат бирү, укучыларда үз халкының гореф-гадәтләренә, этнографик үзенчәлекләренә ихтирам-хөрмәт уяту, горурлык

хисе тәрбияләү булган дәресләр комплекслы тәкъдим итеп, укучыларыбызда үз халкы мәдәнияте турында тулы күзаллау булдырырга мөмкин.

Әдәбият дәресләрендә үтелгән темадан соң тестлар чишү өчен дә презентация кулланырга мөмкин. Әлеге очракта теманы үзләштерү дәрәҗәсе тикшерелә, белемнәр бәяләнелә, ялгышлары ачыклана, анализлана, төзәтү юллары тәкъдим ителә.

Слайдлар ярдәмендә кроссворд, ребуслар чишәргә дә мөмкин. Әлеге алым пассив укучыларда да кызыксыну уятмый калмый.

Интернет ресурларын кулланып, интерактив экраннардан видеороликлар, татарча мульфильмнар күрсәтү – тагын бер нәтиҗәле һәм кызыклы алым. Язучылар тормышы һәм иҗаты, өйрәнелгән әсәр турында әйтелгән фикерләр, спектакльләр, татар халкының йола барышы, музейлар һ.б. турында мәгълүмат табып карарга мөмкин. Шулай ук, татармультфильм туплаган хезмәтләр дә әдәбият дәресләрендә урынлы кулланыла. Г. Тукай экиятләренә төшерелгән мельтфильмнар, һичшиксез, тема өйрәнелгәндә бер генә укучының да игътибарын яуламый калмый.

Дәресләрдә аудиоязма тыңлау да үз нәтиҗәсен бирә. Мәсәлән, шигырь өйрәнгәндә, сәнгатьле укылган язма; әсәр укыганда – өзек, халык иҗатын өйрәнгәндә – мәсәлән, каз өмәсе, Сабантуй һ.б. турында тыңларга мөмкин.

Интернет чикләренең җаена төшенгән укытучы һәм укучылар дистанцион уздырылган конференция, конкурс, олимпиада, викториналарда да ирекле катнаша ала.

Шулай итеп, информацион технологияләр ярдәмендә татар әдәбияты дәресләрендә үтелә торган темадан чыгып, күрсәтмә материаллар һәм укыту ресурсларын бик күп табарга һәм аларны нәтиҗәле итеп файдаланырга мөмкин. Бу алым укучыларның белем сыйфатын үстерергә ярдәм итә. Интерактив такта укытучыга укучылар белән бергәләп эшләргә зур мөмкинлекләр тудыра. Дәресләрдә заманча технологияләр куллану килүе хәтта иң проблемалы укучыларга да укуга карата карашларын үзгәртергә этәргеч ясый: укучы активлаша һәм иҗади фикер йөртә башлый. Кыскасы, интерактив такта укучыларда эшләү активлыгын гына арттырып калмый, ә яңа материалны һәр укучыга җиңел, аңлаешлы итеп җиткерергә дә ярдәм итә.Ә Интернет исә укучыга һәм укытучыга кирәкле мәгълүматны җир шарының төрле ноктасыннан эзләп табу шартларын тудыра.

Дәресләрдә заманча технологияләрне куллану барышында түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин: укучыларның сүзлек запасы байый, сөйләм теле камилләшә; татар мәдәнияте, сәнгате, әдәбияты турында күзаллаулар үсә һәм

киңәя, иҗади эшләр башкарырга теләк булдырыла, уку эшчәнлеген баета, укучыларның иҗади эшчәнлеге арта.

Шулай итеп, белем бирүдә заманча технологияләрне куллану ул – әхлаклы кеше тәрбияләү, педагогик технологияләр булдыруда фәннең роле арту, өйрәнгәнне тормышта куллана белү һәм башкалар.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Информационные и коммуникационные технологии в образовании // И.В. Роберт, С.В. Панюкова, А.А. Кузнецов, А.Ю. Кравцова; под ред. И.В.Роберт. – М.: Дрофа, 2013. – 374 с.

2. Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик технологияләр. – Алабуга: АДПУ нәшр., 2010. – 139 б.

3. Харисов Ф. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр. – Казан, 2010. – 234 б.

4. Татар телен һәм әдәбиятын укытуда яңа технологияләр / төз. Р.З.Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗәнова. – Яр Чаллы, 2011. – 69 б.

**Р.И. ХӨСНЕТДИНОВА**

*магистр*

*Казан федераль университеты*

## ТАТАР ТЕЛЕН УКЫТУДА СПОРТ ЛЕКСИКАСЫН КУЛЛАНУ

**Аннотация.** Данная статья посвящена изучению методики формирования лексических навыков на основе модульной организации учебного процесса на занятиях татарского языка.

**Ключевые слова**: спортивные термины, модульное обучение

**Abstract.** This article is devoted to the study of the methodology for the formation of lexical skills based on the modular organization of the educational process in the Tatar language classes.

**Keywords:** sports terms, modular training.

Спорт лексикасын үзләштерүгә кешеләрнең киң даирәсе мохтаҗ: спортчылар, тренерлар, спорт вакыйгаларын оештыручылар, комментаторлар һәм спорт хакимнәре. Спорт терминнары спорт тапшыруларында, шулай ук газета һәм журналларда кулланыла. Алар еш кына матур әдәбиятта очрый, аларны белү теләсә кайсы белемле кешегә кирәк. Белем бирү сыйфатын күтәрү һәм укучыларның татар телен өйрәнүдә мотивациясен арттыру өчен модульләп укуны иң яхшы метод дип саныйбыз.

Укучыларны әзерләү өчен, компетенциягә нигезләнгән – модульле уку түбәндәге сәбәпләр буенча иң уңышлы:

1. Компетентлы-модульле уку конструкцияләүне күздә тота, уку материалы һәм укытуның төрле рәвешләрен интеграцияләү укыту процессының индивидуаль траекторияләрен һәм нәтиҗәлелеген төзергә мөмкинлек бирә.

Мондый интерпретациядә спорт лексикасын өйрәтү буенча нәкъ менә модульле уку методик яктан кулай булып тора.

2. Шулай ук бер-берсе белән үзара бәйләнештәге һәм методик бөтенне тәшкил итүче эчтәлекле, процессуаль һәм технологик аспектларны үз эченә ала [1, с. 12].

Модульнең максаты – спорт темасына караган сүзләрнең лексик кыры, сөйләм формулалары һәм клише рәвешендә кертү нигезендә коммуникатив компетенцияне үстерүдән гыйбарәт [2, с. 43]. Лингводидактлар һәм методистлар модульле укуның түбәндәге принципларын күрсәтәләр: 1) Модульлек; 2) Динамиклык; 3) Системалылык; 4) Предметара элемтәләрне киңәйтү.

Коммуникатив компетенция белем, рецептив һәм продуктив белем җыелмасын тәшкил итә, аларны формалаштыру күнегүләр нигезендә башкарыла. Бүген белем, алардан файдалануның билгеле бер күнекмәләре һәм күнекмәләре булмаган хәлдә, белем бирү проблемасын һәм киләчәк һөнәри эшчәнлектә укучыны әзерләү проблемасын хәл итә алмыйлар. Димәк, белем бирүнең максаты белем һәм күнекмәләр генә түгел, бәлки шәхеснең билгеле бер сыйфатларына әверелә. Ягъни, укучылар кешеләр белән эшләүдәге тупланган белемнәрне һәм күнекмәләрне профессиональ һәм иҗади бурычларны хәл итү процессында нәтиҗәле файдалана белергә, шулай ук үз эшчәнлегенең мөмкин булган нәтиҗәләрен эшкәртүгә әзер булырга тиеш.

Модульле укыту – ул шәхси-юнәлешле педагогик процессны гамәлгә ашыру юлларының берсе. Ул уку материалын үзара бәйләнгән аерым элементларга бүлүдән гыйбарәт, аларның һәркайсы махсус эшләнгән һәм тиешенчә рәсмиләштерелгән уку темасыннан гыйбарәт.

Белем бирү эчтәлеге турында теоретик нигезләмәләрне бәян итү барышында без, модуль эчтәлеге билгеле бер мәгълүмат банкын барлыкка китерүче тематиканы, текстларны һәм ситуацияне үз эченә ала, дип билгеләп үтәбез. Модульгә керә торган мәгълүмат төгәл структуралы һәм бердәм бөтенлектә төрле катлаулылыкта һәм тирәнлектә булырга мөмкин [3, с.12].

Модульнең процессуаль аспекты – ул төркем эчендә укучыларның бер-берсе белән һәм алар алдында куелган бурычларны хәл итү процессында укытучы белән үзара хезмәттәшлеге. Телгә өйрәтү эчтәлегенең процессуаль аспекты, беренче чиратта, сөйләм күнекмәләрен һәм сөйләм күнекмәләрен үз эченә ала. Модульнең технологик өлеше биремнәр һәм күнегүләр ярдәмендә компетенцияләр формалаштыруга юнәлдерелгән мәгълүмати-коммуникация һәм педагогик технологияләрне файдалануны күздә тота [4, с. 15].

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: кешенең сөйләме никадәр бай булса, аның фикерләве дә төгәлрәк була. Шуңа күрә, без татар телен өйрәнүгә кызыксынуны арттыру өчен, белем бирүнең заманча һәм нәтиҗәле технологияләре нигезендә сыйфатлы дәресләр булдыруга мохтаҗ.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Баева Г.И. Формирование теоретических основ профессиональной компетентности будущего педагога. – Пермь, 2007. – 131 с.

2. Молдатыев Е.А. К проблематике спортивной терминологии // Актуальные проблемы лексикологии: тезисы докладов лингвистической конференции. – Новосибирск: НГУ, 1969. – 201 с.

3. Гез Н.И. Развитие коммуникативной компетенции в ситуациях ролевого обучения // Тезисы доклада на Всесоюзной научной конференции «Коммуникативные единицы языка». – М., 2004. – 24 с.

4. Бим И.Л. Методика обучения иностранным языкам как наука и проблемы школьного учебника. – М., 1977. – 288 с.



**Л. Р. ШАРАПОВА,**

*ученица 9 класса*

*Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение «Средняя общеобразовательная школа № 22 – Центр образования» г. Казани*

**З. Р. ШИГАПОВА,**

*ученица 9 класса*

*Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение «Средняя общеобразовательная школа № 22 – Центр образования» г. Казани*

**А.Р. НИГМЕТЗЯНОВА,**

*учитель*

*Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение «Средняя общеобразовательная школа № 22 – Центр образования» г. Казани*

**Н.И. РОДИОНОВА,**

*учитель английского и французского языков*

*Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение «Средняя общеобразовательная школа № 22 – Центр образования» г. Казани*


## ЛЕКСИКОГРАФИРОВАНИЕ ИНТЕРЪЕКТИВИЗМОВ В ДВУЯЗЫЧНЫХ СЛОВАРЯХ (НА БАЗЕ ТАТАРСКОГО И АНГЛИЙСКОГО ЯЗЫКОВ)


**Аннотация.** Язык является важной частью человека и его жизни, которая сопровождается эмоциями, волеизъявлениями. Лексикографическое представление интеръекционных

единиц татарского и английского языков, как и во всех других языках, базируется на словарях. Обращаясь к переводным словарям, остро встаёт вопрос адекватного и правильного перевода с одного языка на другой. При переводе интеръекционных единиц следует понимать оригинал текста в полной мере, чтобы избежать семантической ошибки и неправильности при передачи эмоциональной окраски междометий, т.к. в двуязычных словарях даются несколько вариантов перевода с различными оттенками эмоциональности. Поэтому следует проанализировать речевую ситуацию и выбрать наиболее подходящий эквивалент.

**Ключевые слова:** словарь, междометие, контекст, лексический, эмоциональный, речевая ситауция.

**Abstract**. Language is an important part of a person and his life, which is accompanied by emotions and expressions of will. The lexicographic representation of interjectional units of the Tatar and English languages, as in all other languages, is based on dictionaries. Turning to translation dictionaries, the question of adequate and correct translation from one language to another becomes acute. When translating interjectional units, you should fully understand the original text in order to avoid semantic errors and incorrectness in conveying the emotional connotation of interjections, because Bilingual dictionaries provide several translation options with different shades of emotionality. Therefore, you should analyze the speech situation and choose the most suitable equivalent.

**Keywords**: dictionary, interjection, context, lexical, emotional, speech situation.

Двуязычные словари дают пользователю возможность не только приобщиться к культуре другого языка, страны, но и освоить лексику, грамматику изучаемого языка. Они помогают исследовать язык, однако следует помнить, что могут быть лексические несоответствия между оригиналом и переводом, это может объясняться использованием слова в определенной речевой ситуации или лексическим содержанием самого слова. Этот процесс наблюдается с междометиями как в татарском, так и в английском языках.

Зачастую, в двуязычных словарях даются несколько вариантов перевода. Например: а межд. 1. Выражает неожиданную догадку, удивление; 2. Выражает радость или злорадство; 3. выражает разочарование. 1. А! Нияз абзый, әйдә уз. – А! Дядя Нияз, давай проходи. 2. А, эләктеңме?! – А, попался?! 3. Кайтырмын мин киткән идең, А… киткән идең. (Һ. Такташ). – Уходя, сказала, что вернешься, А… ушла (Х. Такташ); wow 1. межд.; разг. 1) вау!, круто!, здорово! (выражает удивление и восторг) 2) шотл. боже мой!, какое горе!, ой! (выражает отвращение, удивление, горе, соболезнование) [http://www.lingvo-online.ru/ru].

Значения междометий могут иметь различную эмоциональную окраску, поэтому следует обращать внимание на речевую ситуацию, в которой интеръективизм употребляется, особенно при переводе с одного языка на другой, чтоб не допустить лексической ошибки. Следует использовать несколько словарей разных авторов, чтобы сделать корректный перевод. При неправильном пони-

мании контекста, перевод может быть искажен, поэтому следует изучить все семантические эквиваленты. Например, в татарском языке интеръективизм «ух» может описывать боль, испуг, ломоту, нытье, стоны, жалость, обиду, неудовлетворение, сомнение, удивление, гордость, хвалу, восторг. Следует правильно выбрать эквивалент при переводе в зависимости от контекста: а, эх, ого, эх, о, вау, ох, ура, уф, э, эй, их, и.

Например, в «Татарско-русском полном учебном словаре» (2006) междометие «ай-вай» трактуется следующим образом: ай-вай 1. межд. Ой-ой, ай. Һәрвакыт ай-вай килеп булмый инде. – Каждый раз не следует разводить охи-ахи.

Анализируя данный интеръективизм, следует отметить, что не дано описание эмоций и волеизъявлений, при которых он употребляется, представлен лишь перевод. При этом следует учитывать, что перевод может использоваться при положительном или отрицательном контексте, в зависимости от речевой ситуации. Далее приводится один пример. Не представлены графически видоизмененные междометия, как это сделано в Толковом словаре татарского языке. Например: ай – аай, ау – аууу, баһ – бах, валлай – валлаһ, валлаһи, вәс – вәс-вәс, ихаха – ихахай, ихи-хи – ихи-хи-хи, көш – көш-көш и т.д.

В другом «Татарско-русском словаре» междометие «ай-вай» трактуется следующим образом: ай-вай 1. межд. см. ай-яй.

*ай-яй, ай-йәй, айәй межд.*

1. выраж. ощущение боли, чувство испуга, страха и т.п. ой, ай, ох, о, о-о, у, у-у; ~, кулымны пешердем! Ой, руку обжег! Ой, обжегся!

2. Выраж. предостережение, предупреждение об опасности и т.п. ой, ой-ой, ой-ой-ой, ох; ай-яй, егыласың бит! Ой, упадешь! 3. Выраж. неодобрение, недоверие, удивление и т.п. однако, ну и ну; бишәр сумнан сатасызмы җимешне? Ай-яй! По пять рублей, что ли, продаете фрукты? Однако (ну и ну)!

3. Чаще ай-ай-ай выраж. упрек и т.п. ну и; ох и; ой (ай, ай-ай); у, уу; бәләкәй чагында еладың да инде, ай-яй ну и плакса же ты был в младенчестве; ой какой ты был плакса, когда был маленьким;

4. Выраж. восхищение, одобрение, восторг, радостное удивление и т.п. ай, ая-ай, ой, ойой; ох, эх, ну и ну; ай да ну; котылды бит, ай-яй! Спассятаки! Ну и ну! Спасся все-таки! Ай да ну! Эшлисе эш әле ай-яй! Работы еще предстоит – ой-ой (ох как много)!

5. Выраж. сомнение, неуверенность и т.п. ой (ой-ой, ох) ли; вряд (навряд, едва) ли; айяй түзә алырсыз микән? Ой, утерпите ли? Вряд ли выдержите!

Анализируя данный словарь, видно, что представлены шесть более подробных описаний эмоций, при которых употребляется это междометие. К

каждому переводу эмоционального оттенка показан пример, дающий ясное понятие, при каких ситуациях интеръективизм употребляется.

Однако, как в одном, так и в другом словаре нет описания графических и фонетических особенностей интеръекционных единиц. Хотя при переводе даны несколько вариантов написания междометий. Например: ой, ой-ой.

Известно, что эмоциональная окраска интеръекционных единиц в большинстве случаях зависит от мимики, жестов, интонации. В данных словарях нет информации о таких особенностях употребления междометий.

В татарском и английском языках, как упоминалось выше, есть особая категория междометий, которая связана с божественной и мифической тематикой. Например, в Большом англо-русском словаре (под ред. И.Р. Гальперина) можно обнаружить следующий интеръективизм:

God 3. В грам. знач. междометия боже!, господи!, боже мой! (выражает удивление, радость, страх, гнев и т.п.)… by God! Ей-богу!; oh/ my, good, great, dear/ God! Боже мой!, боже милостивый! (выражает гнев, удивление и т.п.); For God’s sake! Ради бога!; God forbid! Избави бог!; God bless me! God bless my soul! Господи помилуй! (выражает удивление, страх и т.п.)… in God’s name! во имя всего святого! (выражает досаду, гнев и т.п.); ye ~s (and little fishes)! Вот так так! Боже правый! (выражает удивление); “Ye ~s, Milly cried, don’t tell me he’s going to fire Jim!” «Боже правый, - вскрикнула Милли, - неужели он уволит Джима!»

В Татарско-русском полном учебном словаре (под ред. Р.А. Сабирова) дано междометие «Алла»: Алла сущ рел 1. Аллах, Бог, всевышний; божество // божий, господний 2. межд. боже, боже мой

Если в словаре английского языка есть примеры, то в татарском словаре их нет, так же, как и особенности употребления и образования. Даны лишь описания эмоций. Поэтому при переводе стоит обращаться к большим словарям с максимальным количеством слов.

Следующая группа интеръекционных единиц, связанные с этикетом, приветствием, прощанием, представленные в толковых словарях исследуемых языков, даны так же без описания особенностей. Например: hi int 1. = hey 1); 2. амер. разг. привет!, алло!; ~, Jiggs здорово, Джиггс! [БАРС 1979]; исәнме(сез) межд здравствуй(те) [ТРПУС 2006].

Лексикографическое изображение является сложным по описанию аспектом языка, который требует изучения всего языка, его структуру. Отметим, что в словарях невозможно описать интеръективизмы общепринятым способом, т.к. следует знать интонации, жесты, мимику, графические и фонетические особенности при употреблении междометий.

Таким образом, лексикографирование интеръекционных единиц в двуязычных словарях исследуемых языков показало, что следует более полно изучить максимальное количество словарей для правильного и корректного перевода, не теряя национального колорита при передаче информации.

## ЛИТЕРАТУРА


1. Вандриес Ж. Язык. Лингвистическое введение в историю. – М.: 1937. – 410 с.
2. Кодухов В.И. Семантическая переходность как лингвистическое понятие // Семантика переходности. – Л.: Учпедгиз, 1977. – С. 5-16.
3. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.



**З.З. ЯРУЛЛИНА,**

*туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Черки-Килдураз урта гомуми белем бирү мәктәбе*

**А.А. ЯРУЛЛИН,**

*студент*
*А. Н. Туполев исемендәге Казан милли*
*тикшеренү техник университеты – КАИ*


# КҮРЕНЕКЛЕ ГАЛИМ-ТЮРКОЛОГ ВАХИТ ХӨҖҖӘТ УЛЫ ХАКОВ: «ТУГАН ЯК ҺӘМ ТУГАН ТЕЛ ХИСЕ»


**Аннотация**. Мы искренне гордимся Вахитом Хаковым – опытным педагогом, филологом-тюркологом, доктором филологических наук, Казанским государственным университетом, заслуженным деятелем науки Республики Татарстан, ветераном Великой Отечественной войны. В наших сердцах он всегда будет хранителем родного языка, нашим уважаемым наставником.



**Ключевые слова**: Хаков, история татарского языка, родной край.



**Abstract**. We are sincerely proud of Vakhit Khakov – an experienced teacher, philologist-Turkologist, Doctor of Philology, Kazan State University, Honored Scientist of the Republic of Tatarstan, veteran of the Great Patriotic War. In our hearts, he will always be the guardian of our native language, our respected mentor.



**Keywords**: Khakov, history of the Tatar language, native land


Һәркемнең үзенә якын һәм кадерле туган ягы бар. Минем дә туган авылым бик матур урында урнашкан .Ул үзенең челтерәп аккан чишмәләре, калын, шомлы һәм серле урманнары, гореф-гадәтле, эшчән, акыллы кешеләре белән атаклы.

Моннан күп еллар элек, бөек Иделгә барып кушыла торган Зөя буена Ураз бабай килеп йорт салган, җирләрен эшкәрткән. Ару – талуны белмәүче Ураз бабай шушы урынга нигез салган йортны Ураз килде дип атаганнар. Тора

– бара бу җирләрне Килдураз дип йөртә башлаганнар. Авыл үскән, зурайган, көннән көн матурайган. Тирә – якта даны арткан. Килдураз белән чиктәш авыллар: Өчмунча, Күзби, Бәбки, Үгез куагы, Кабалан халкы элек – электән дус, тату яшәгән. Балалары Килдураз мәктәбендә белем алганнар. Бу хәзер дә шулай дәвам итә. Хәзерге вакытта авылларны «Коммуна» кумәк хуҗалыгы берләштерә. Бу авыллардан күп кенә күренекле һәмданлыклы кешеләр чыккан: Ренат Харис, Шәриф Хөсәинов, Марс Әхмәтов, Шамил Нигъмәтуллин, Вахит Хаков, Җәләлетдинов Рәшит, Әюпов Ренат, Скиргайло Тамара һ.б., шулардан иң өлкәне – Вахит Хаков.

Күренекле тел галиме, укытучы – педагог, Вахит Хөҗҗәт улы Хаков 1926 нчы елның 16 нчы августында Татарстанның матур урынында урнашкан Буа районының Күзби авылында дөньяга килә. Аның әтисе – Хөҗҗәтелислам акыллы, тырыш кеше, бөтен гомерен балалар укытуга багышлый. Педагог әтисенә ияреп, малай да китап яратып үсә. Башлангыч белемне ул Күзби авылында мөгаллимлек иткән әтисеннән ала. Бу мәктәпне «5»ле билгеләренә генә тәмамлап, ул укуын Килдураз мәктәбендә дәвам итә, 8 нче классны бетергәч, Бөек Ватан сугышы башлана. Кечкенәдән укытучы булырга хыялланган малай чак кына еламый кала. «Ничек кенә авыр булмасын, укый күр, улым», – дигән әтисенең сүзләре колагында яңгырый.

1943 елда 17 яше тулмаган Вахитны армиягә алалар. Җиде ел хәрби хезмәттә булып, яраланып, сугышчан медальләр, Верховный Командующийның рәхмәт кәгазьләре белән бүләкләнеп, 1949 елда яшь солдат тыныч хезмәткә исән-имин әйләнеп кайта.

Туган якларына әйләнеп кайткач, ул төрле мәктәпләрдә балалар укыта, үз белемен күтәрү өстендә эшли. Тәтеш педагогия училищесын «бик яхшы» билгеләренә тәмамлый. Егет укуын дәвам итү өчен Казан дәүләт университына укырга керә, аны кызыл дипломга бетерә. Аспирантураны тәмамлап «Татар әдәби теленең барлыкка килүе, үсеше һәм аның стильләре» дигән докторлык диссертациясе яклап,филология фәннәре докторы дигән югары гыйльми дәрәҗә ала. Тагын өч елдан аңа профессор исеме бирелә. Менә нинди тырыш, үҗәт булган безнең якташыбыз.

Вахит ага, чыннан да, әтисенә биргән сүзендә тора. Зур уңышларга ирешә, тел галиме дәрәҗәсенә күтәрелә. Ул 40 ел дәвамында студентларга белем бирә, шәхеснең шәкертләре бөтен дөньяга таралган, алар арасыннан фән докторлары, фән кандидатлары, эшмәкәрләр үсеп чыккан. Әлбәттә, һәрбер галимне аның фәнни хезмәтләре бизи. Вахит ага Хаков, фән кысаларында гына бикләнеп калмыйча, гомере буе татар халкының язмышын кайгыртып яшәде.

Ул 40 елдан артык Татарстан радиосында «Тел күрке – сүз» тапшыруларының оештыручысы һәм алып баручысы булды, берничә буын бу тапшыруларны тыңлап, тәрбияләнеп үсте. Вахит Хөҗҗәт улы берничә яклау Советының хөрмәтле әгъзасы булып торды, төрле югары уку йортларына методик яктан зур ярдәм күрсәтте.

Галимнең 30га якын монографиясе, дәреслекләре, уку-укыту әсбаплары 500дән артык фәнни һәм фәнни методик хезмәтләре басыла. Әле шулар янына төрле китапларда, җыентыкларда, шул җөмләдән чит ил басмаларында мәсәлән, Төркиядә дөнья күргән 350гә якын фәнни мәкаләләрне өстәргә кирәк.

Вахит Хаковның фәнни эшчәнлегенә бәя биргәндә бер моментны аеруча басым ясап күрсәтеп үтәргә кирәк: ул безнең тел белеменең катлаулы һәм аз өйрәнелгән өлкәсен күтәреп алып китте. Аның төп фәнни юнәлеше – төрки һәм әдәби телләре тарихы, андагы стилисик категорияләрнең үсеше, татар язма истәлекләренең теле. Татар галименең исеме һәм хезмәтләре Татарстанда һәм Русиядә генә түгел, төрки дөньяда да бик яхшы билгеле. Ул Мәскәү, Алма-ата, Ташкент, Ашхабад, Нальчик шәһәрләрендәге тюркологлар белән тыгыз иҗади элемтәдә тора, тәҗрибә уртаклаша, төрки телләр буенча конференцияләрдә катнаша.

Милләт язмышы, халык мәнфәгате турындагы уйлар китергәндер егетне бу юлга, эшлекле, булдыклы ир – егет гомерен татар телен өйрәнүгә, аны баетуга, пропагандалауга багышлый. «Мәктәптә, югары уку йортларында тел укытуны ничек тә саклап калырга, газиз туган телебезне өйдә генә сөйләшергә ярый торган тел итеп калдырмаска! Дәрәҗәсен төшермәскә!», – ди галим. Халык туган телдән бизмәсен, сөйләшү – аралашуда, язуда күбрәк куллансын, матурлыгын, ләззәтен тойсын дип тырышты Вахит ага. Тел бит ул бер-берең белән аралашу коралы гына түгел, ул – фикерләү чарасы да. Тел кешенең фикерләвен, дөньяны танып белүен дә үстерә. Без, татар теле укытучылары, телебезнең зур галиме язып калдырган хезмәтләрен, дәреслекләрен һәм укытучылар өчен методик ярдәмлекләрен кулланып, эш итәргә тиеш һәм шулай эшлибез дә. Туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, аны күз карасы кебек саклау – үз анаңны, иленне хөрмәтләү дигән сүз.

«Тел дигән дәрья бар, дәрья төбендә мәрҗән бар» – дип, халкыбыз телнең иксез-чиксезлеген һәм тирәнлеген, тел байлыгының мәрҗәннәрдәй серле һәм могҗизалы булуын әйтергә теләгәндер. Димәк, тел – ул кешенең, шәхеснең беренче күрсәткече, хәтта акыл мөмкинлекләренең күрсәткече. «Тел – белемнең ачкычы, акылның баскычы», – диләр бит.

Вахит Хаков тәҗрибәле педагог, филолог-тюрколог, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Бөек Ватан сугышы ветераны белән чын йөрәктән горурланабыз, чөнки ул безнең горурлыгыбыз. Безнең күңелләрдә ул һәрвакыт олы җанлы, сабыр, тирән белемле туган тел сагында торучы, хөрмәтле остазыбыз булып сакланыр.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Әһлиуллин М. Зөя буе – туган җирем. – Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 2005. – 314 б.
2. Буа ягым – тау ягым. – Казан: Тат. кит. нәшр, 2000. – 447 с.
3. Хаков В.Х. Туган як һәм туган тел хисе. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2007. – 220 б.

## СОДЕРЖАНИЕ

## ВОСПОМИНАНИЯ О ПРОФЕССОРЕ В.Х. ХАКОВЕ

*Кузьмина Х.Х.* Вклад заслуженного профессора Казанского университета В.Х. Хакова в изучение развития татарского литературного языка.............. 3
*Әхмәтвалиева Л.В.* Безнең әти «аяклы энциклопедия» иде.......................... 6
*Хакова Х.Ф.* Искә алу, юксыну........................................................................ 8

## МАТЕРИАЛЫ КОНФЕРЕНЦИИ «ХАКОВСКИЕ ЧТЕНИЯ - 2023»

*Алитурлиева А.С., Айсултан С.Б.* Размышления обучающейся молодежи о социальной ответственности: анализ фокус-групп....................................... 10
*Алшейхо Г.* Türk ve Rus atasözlerinin genel nitelik ve özellikleri bakımından karşılaştırılması.......................................................................................... 14
*Ахметова Л.Р.* Редкие женские антропонимы в современном антропонимиконе г. Казань............................................................................................ 17
*Бадрутдинов Н.С.* Татар әдәбияты дәресләрендә предметара бәйләнешләр принцибын куллану проблемасы................................................................. 21
*Байлауов Р.Е., Книсарина М.М.* Феномен «благополучия» глазами обучающегося.......................................................................................... 24
*Болгарова А.Р.* Эффективность применения мультимедийных технологий в современном образовании........................................................................ 29
*Васикова А.И., Сәгъдиева Р.К.* Күрсәтмәлелек ярдәмендә укучыларның сөйләм күнекмәләрен формалаштыру......................................................... 32
*Габбасова Г.Ш., Рахимзянова Л.Ш.* Башлангыч сыйныфларның рус төркемнәрендә татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проектлар методын кулану………………………………………………………………… 35
*Галимбикова И.И.* Использование игровых технологий в начальной школе 38
*Гатиятова А.Р.* Ландыш Әбүдәрованың «Газап» хикәясендә сурәтләнгән дөнья............................................................................................................ 42
*Гыйләҗетдинова Э.И.* Туган тел дәресләрендә коммуникатив компетенция формалаштыру чарасы буларак кече төркемнәрдә эш......................... 44
*Гобәйдуллина Л.Ф.* Интернетта мәгълүмат бирү формасы.......................... 47
*Губайдуллина А.Р.* Особенности языка сэяхет-наме и путевых очерков Фатиха Карими.................................................................................................. 51
*Жандарбекова Д. Д.* Условность в терминологии и терминотворчестве....... 54

*Зайнуллина Р.Р., Зайнуллина Л.Ф., Солнцева С.С.* Литературный перевод стихотворений татарского поэта Мусы Джалиля на русский и английский языки........................................................................................................ 60
*Ибраева Л.Р.* Татар телендә һөнәр атамалары............................................... 64
*Книсарина М.М., Казиев К.О., Жумалиева Г.С.* Методические особенности повышения социальной ответственности....................................................... 66
*Курбанова А.Р.* Методика интеграции аутентичного материала в системе средств обучения иностранным языкам......................................................... 72
*Минмуллина С.Ф.* Технологии и методы обучения татарской литературе в современных условиях......................................................................... 76
*Миннегалиева Л.И., Хуснутдинов Д.Х.* Народные сказки Поволжья (на примере татарских и чувашских сказок)...................................................... 79
*Мөэминова Г.Ф.* «Ватаным Татарстан» газетасы язмалары башисемнәренең функциональ классификациясе............................................ 81
*Набиуллина А.И.* Хәзерге татар яшьләре дискурсында алынмалар кулланылышы........................................................................................ 84
*Рахимов Э.А.* Потенциальные возможности использования сети интернет и мультимедийных технологий при обучении иностранному языку в общеобразовательных учреждениях Республики Татарстан......................... 88
*Рахматуллина А.А., Һадиева Г.К.* Балалар сөйләменә фоносемантик анализ (Гөлинә Шәйхи шигыре мисалында) .................................................... 91
*Сабанина С.П.* Поликультурное образование: диалог культур и билингвальное обучение....................................................................................... 94
*Сагдиева Р.К., Асхадуллина Г.Г.* Туган тел (татар теле) дәреслекләрендә “Татар дөньясы” темасының яктыртылышы................................................ 98
*Садриева И.Р.* Тел материалын үзләштерүдә электрон чаралар куллану….. 101
*Салаватуллина А.И.* Хәзерге татар һәм башкорт матбугатында рус-европа алынмалары........................................................................................ 106
*Сафин А.Г.* Проблемы и перспективы преподавания предмета «Основы безопасности жизнедеятельности» в общеобразовательных учреждениях с родным языком обучения............................................................................ 109
*Сибгатуллина Д.Н.* Туган тел дәресләрендә укучыларны язма сөйләмгә өйрәтүдә эш төрләре............................................................................ 111
*Сыздыкбаева А.Дж., Книсарина М.М, Байкулова А.М.* Воспитание социальной ответственности и его влияние на студентов различных университетских курсов............................................................................ 114
*Умутбаева Л.Р.* Повышение мотивации к изучению иностранных языков

посредством проектной технологии........................................................... 120
*Фаттахова З.Ф.* Хәзерге татар орфоэпиясенә һәм орфографиясенә рус-европа алынмаларының йогынтысы........................................................... 123
*Фатыхова А.Л.* Хәзерге татар телендә «баш» соматик компоненты булган фразеологизмнар кулланылышы........................................................... 125
*Фәхртдинова Р.Н.* «Yaña Mähällä Habärläre» журналының лексикасы: мишәр диалекты үзенчәлекләре һәм төрек теле алынмалары........................ 129
*Хаҗиева М. А.* Туган тел дәресләрендә урта сыйныф укучыларына интонацияне өйрәтү........................................................... 132
*Хәйруллина Л.Р.* XX йөз урталарында дөнья күргән хезмәтләрдә эндәш сүзләр........................................................... 136
*Хәлиуллина А.М.* В.Хаковның стилистика фәненә керткән өлеше................. 139
*Хәмидуллина Э.И.* Педагогиканың заманча алымнары: әдәбият өлкәсендә поэтик әсәрләрне өйрәнү........................................................... 143
*Хамматова А.Ф.* Әдәбият дәресләрендә Әмирхан Еники иҗат лабораториясен өйрәнү дәресләрен оештыру........................................................... 147
*Харисов Ф.Ф.* Яңартылган стандарт – заман таләбе...................................... 152
*Хәсбиуллина Г.Ф.* Башлангыч сыйныфларда мөстәкыйль сүз төркемнәрен мәгълүмати-аралашу технологияләр ярдәмендә укыту................................. 158
*Хисматуллина И.М.* Оренбург татар-казак гаскәриләренең язма истәлекләрендә грамматик үзенчәлекләр........................................................... 162
*Хуҗина З.Р.* Татар әдәбияты дәресләрендә инновацион технологияләр куллану ........................................................... 166
*Хөснетдинова Р.И.* Татар телен укытканда спорт лексикасын куллану........ 169
*Шарапова Л.Р., Шигапова З.Р., Нигметзянова А.Р., Родионова Н.И.* Лексикографирование интеръективизмов в двуязычных словарях (на базе татарского и английского языков)........................................................... 171
*Яруллина З.З., Яруллин А.А.* Күренекле галим-тюрколог Вахит Хөҗҗәт улы Хаков: «Туган як һәм туган тел хисе»........................................................... 175

*Электронное научное издание*
*сетевого распространения*

**ХАКОВСКИЕ ЧТЕНИЯ – 2023**

**Материалы Международной научно-практической конференции молодых ученых, посвященной памяти заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова**

---

**ХАКОВ УКУЛАРЫ – 2023**

**Яшь галимнәрнең Казан университеты атказанган профессоры Вахит Хөҗҗәт улы Хаков истәлегенә багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары**

Подписано к использованию 03.11.2023
Гарнитура «Times New Roman»
Заказ № 7/11 от 01.11.2023

Издательство Казанского университета

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37
тел. (843) 206-52-14 (1704), 206-52-14 (1705)